ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 1 (337)
ГЫЙНВАР 2020

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

БАКЫЙ УРМАНЧЕ: ШӘХЕС ЯЗМЫШЫ – РЕСПУБЛИКА ТАРИХЫ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Илшат Фәйзрахманов, Луиза Янсуар
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: РСФСРның халык рәссамы Бакый Урманченың автопортреты. «Бакый Урманче» китабыннан алынды

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
1150 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-99
Басарга кул куелды: 27.01.2020
Басмадан чыкты: 31.01.2020

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга. Гомуми тираж: 3500 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

АЙ ВАКЫЙГАСЫ

НЬЮ-ЙОРК, МАНХЭТТЕН. «ҮЗГӘРЕШ ЖИЛЕ»

Гыйнвар аенда татар музыкасы, бөтен чикләрне узып, интернациональгә әверелде. «Үзгәреш жиле» ярдәм итте. Нью-Йоркка барып җиткән фестиваль Карнеги-холлны шыплап тутырган тамашачыларның алкышларына күмелде.

Тамашачылар фестиваль концертын Татарстанның барлык төсләрен, чалымнарын үзенә җыйган этник балкыш, искиткеч шоу дип атадылар. Россия арфачысы Александр Болдачев бу күренешне татар милли музыкасы өчен киң күләмле ыргылыш дип атады. Популяр җырларның һәм джазның, классик башкарылыш һәм рэпның үзара берләшүе, аның әйтүенчә, гармонияле һәм талантлы картина тудырды: «Бүгенге көндә татар милли музыкасы, үзгәреш кичереп, шул ук вакытта дәүләтнең һәм талантлы музыкант Вадим Эйленкригның (фестивальнең музыкаль җитәкчесе. – Ред.) ярдәменә таянып, көчле сәхнәләштерелүгә ирешге, һәм хәзер аны кыю рәвештә дөньяның башка мәйданчыкларында да күрсәтергә мөмкин». Ә фестивальнең генераль продюсеры Рәүфәл Мөхәммәтҗанов Нью-Йорктагы чыгыш – әлегә дебют кына, ә артистлар үзләренең осталыгын һәм талантын бөтен дөнья буенча башка шәһәрләрдә һәм илләрдә дә күрсәтергә әзер, дип вәгъдә итте.

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **933 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ



Бакый Урманче. «Кышкы нурлар». «Бакый Урманче» китабыннан алынды.

ГЫЙНВАР

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Чүп яндыру заводы: ике як фикере
Төзелеш яклылар һәм аңа каршылар нәрсә турында бәхәсләшә

10. Иң матур авыл чыршысы
Авылларда бәйрәмне ничек каршыладылар

16. 100 яшьлек басма тарихыннан
«Татарстан» – озак яшәү серләре

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

24. Кайсы районда яшәү яхшырак
Сораштырулар нәрсә күрсәтте

30. «Кояшлы Ык»
Мөслимдә киләчәкне ничек төзиләр

36. «Кояшкай» – бәхетле балачак иле
Сабыйлар кайда үзләрен өйдәгедәй хис итәләр

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

42. XIX гасыр хәзинәсе
Шандор-тауда нәрсәләр яшеренгән

46. Агач археологиясе музее
Урта гасырга сәяхәт

50. Шәхес мөнәсәбәтләре химиясе
Академик Арбузовларның шәхси тормышы турында

54. Бакый Урманче:
Сыннарга җан өруче

58. Тарих сәхифәләре
Идел буе кораб урманнары турында

66. Мәхмүт Гәрәев истәлегенә
Бер татар ничек итеп йөз мең сугышчыны алыштыра

70. Китаплар дөньясы
Александр Девятаевның китап киштәсе

84. Татар авыллары
Түбән Майна: тарихлы халык

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

13.01

Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Дәүләт Советы Рәисе, – Россия матбугаты көне уңаеннан ММЧ вәкилләре белән очрашуда милли проектларның әһәмияте турында:

– Совет заманында да, советлардан соңгы чорда да бөтен илне, аның территорияләрен, һәр авылны тәртипкә китерүгә юнәлтелгән проектлар булмады. Бу максатларга бик зур финанслар каралган, Татарстан 53 млрд сумны үзләштерәчәк. Халыкның тормышын яхшырту өчен без файдаланырга тиешле менә дигән мөмкинлек.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

15.01

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты, – Мәскәүдә, РФ Министрлар Кабинеты отставкага киткәннән соң журналистларга биргән интервьюсында:

– Мин хөкүмәтнең эшеннән бик канәгать, аларга карата бернинди дәгъвам да юк. Минем үземә карата дәгъваларым бар. Без үзебез эшләп җиткермибез. Безнең барыбызның да үз өстенлекләребез һәм кимчелекләребез бар. Министрлар Кабинетының яңа составына килгәндә, ил җитәкчелеге кемне билгели, без шулар белән эшлибез.

Фото ТР Президенты сайтыннан

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

17.01

Лариса Никишина, Нью-Йоркта яшәүче музыкант, – Нью-Йорктагы Carnegie Hall сәхнәсендә куелган «Үзгәреш җиле» татар җыры фестиваленнән соң:

– Әлеге күренешне Татарстанның барлык төбәкләренең этник балкышы дип атарга мөмкин булыр иде, мондый хәлне Carnegie Hallның моңа кадәр күргәне булмагандыр. Ул, музыка һәм аранжировкадан башлап, костюмнар, биюләр, тавышларга кадәр искиткеч шоу булды. Иң гаҗәпләндергәне шул: сәхнәдән шулкадәр затлы тавышлар яңгырады, шундый табигый тавышлы җырчылар чыгыш ясады, тик ни өчен без аларны башка концертларда, Россия телевидениесе аша күрмибез соң, ник безгә дистә еллар буена бер үк артистларны күрсәтәләр?

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Казанлыларга чүп-чарны **КАЯ** куярга

Иң матур авыл чыршысы **КАЙДА**

Йөз яшьлек журналның **НИНДИ** чорлары булган

ЧҮП ЯНДЫРУ ЗАВОДЫ: 3 КИСКЕН СОРАУ

Татарстан башкаласы илебездә каты коммуналь калдыклардан күмеп кую ысулы белән арынуны туктаткан беренче шәһәр булырга тиеш – Казанда заманча дөнья технологияләре нигезендә төзелгән чүп-чар яндыру заводын (ЧЯЗ) эшләтеп җибәрергә планлаштыралар. Бу дәүләт заказына конкурсны «РТ-Инвест» компаниясе – «Ростех» дәүләт корпорациясе карамагындагы предприятие отты. Осиново бистәсеннән ерак түгел төзелеш урыны да билгеләнгән. Әмма Казан һәм Яшел Үзән районында яшәүчеләр арасында проектка кискен каршы килүчеләр дә табылды, алар «Казанда һәм Татарстанда ЧЯЗ – юк!» дигән иҗтимагый хәрәкәткә берләштеләр.

Кызганыч, узган өч ел эчендә бәхәсләшүче яклар нәтиҗәле әңгәмә кора алмадылар. «Татарстан» журналы бу мәсьәләдә аларга ярдәм итәргә карар кылды. Без «Казанда һәм Татарстанда ЧЯЗ – юк!» иҗтимагый хәрәкәте активистларына мөрәҗәгать итеп, аларның «РТ-Инвест» компаниясенә юнәлтелгән иң кискен сорауларын җиткерергә, ә инвесторга исә бу сорауларга җавап бирергә тәкъдим ясадык.

Булачак заводның макеты «РТ-Инвест» компаниясенең матбугат хезмәтеннән алынды

Фото «Казань без свалки» сайтыннан алынды. Самосырово чүплеге рекультивацияләү старты

Елена Бикташева,
экоактивист, иҗтимагый хәрәкәт юристы:

1 – Ни өчен компания завод проектын җәмәгать экспертизасына тәкъдим итми? Проект юк икән, заводның экологик яктан чисталыгы турында лаф орулар реклама гына булып тора. Проект документларын инде бер елдан артык алырга тырышып йөргән «ПРИНЦИПЪ» иҗтимагый оешмасы судка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булды һәм аның дәгъвасы канәгатьләндерелде. Әмма АГК-2 суд карарына мөмкин булган барлык инстанцияләрдә дә шикаять белдерде. Соңгы кассация инстанциясе карарны үз көчендә калдырды һәм АГК-2 тарафыннан проект документациясенең бирелергә тиешлеген раслады. Суд карары 2019 елның 2 сентябрендә үз көченә керде, әмма әлегә кадәр үтәлмәгән.

Елена Ямщикова,
АКГ-1нең («РТ-Инвест» структурасындагы Альтернатив генерацияләүче компания) экология буенча директоры:

– Россиянең баш дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алганчы, Татарстандагы завод проекты ике тапкыр җәмәгать тикшерүе узды. Заводның экологик параметрлары буенча документлар тиешле рөхсәте, нигезе булган теләсә кайсы иҗтимагый оешма соравы буенча бирелә. Барлык экспертизалар да проект документларының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә РФ законнары белән билгеләнгән экологик таләпләргә туры килгәнлеге турында нәтиҗә чыгарды.

Бу мәсьәләдә сүз әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясау турында мәгълүматлардан тыш, технологик схемалардан, чит ил партнерларыбызның уникаль җиһазлары, аларның составы турындагы тасвирламалардан торган документларның тулы пакетын соратып алу турында да бара. Без бу мәгълүматны коммерция сере дип саныйбыз һәм үз фикеребезне судта якларга мәҗбүрбез. Без мәгълүматларның өченче затлар тарафыннан үз максатларында файдаланылуына юл куймаска тиеш, чөнки бу интеллектуаль милек, безнең аны якларга хокукыбыз бар. Шуңа күрә АГК-1 һәм АГК-2, документларның тулы пакетын бирү таләбе белән мөрәҗәгать иткәндә, конфиденциальлек турында килешүгә имза куюны сорый.

Елена Бикташева,
экоактивист, иҗтимагый хәрәкәт юристы:

– «ПРИНЦИПЪ» иҗтимагый оешмасына АГК-2 ягыннан конфиденциальлек турындагы килешүгә кул куярга кирәклеге хакында тәкъдим килмәде. Моннан тыш, суд әлеге таләпнең законсыз булуын ачыклады. Документлар нинди дә булса шартларсыз гына бирелергә тиеш. Өстәвенә, сәламәтлеккә зыян китерү мөмкинлеге белән бәйле мәгълүмат коммерция сере була алмый.

Елена Ямщикова,
АКГ-1нең («РТ-Инвест» структурасындагы Альтернатив генерацияләүче компания) экология буенча директоры:

– АГК-2 бары закон кысаларында гына эш йөртә. Без техник документлар коммерция сере булып тора, дигән фикер турында бәхәсләшмибез. Нәкъ менә шул сәбәпле, без барлык суд инстанцияләрен узабыз да инде. Төрле дәрәҗәдәге судлардан үткәннән соң, документлар, һичшиксез, законда каралган барлык вакыт таләпләрен үтәп, тиешле дәгъвачыларга бирелә. Шул исәптән Татарстанда да. Хәзерге вакытта документларны тапшыру өчен әзерлек процессы бара.

Елена Бикташева,
экоактивист, иҗтимагый хәрәкәт юристы:

2 – Төрле интервьюларында «РТ-Инвест» генераль директоры Андрей Шипелов, завод торбасыннан чиста пар чыгачак, дип берничә тапкыр белдерде. Тик ни өчен фикер алышу өчен халыкка чыгарылган, әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү проектында (ОВОС проекты) башка күренеш тасвирланган соң: һавага 1, 2 классы 670 тонна зарарлы матдә, шул исәптән терекөмеш, авыр металлар, диоксиннар, фураннар, азот белән кислород кушылмалары һәм углекислый газ чыгарылачак?

Елена Ямщикова,
АКГ-1ның («РТ-Инвест» структурасындагы Альтернатив генерацияләүче компания) экология буенча директоры:

– Безнең «Калдыклардан энергия» дип исемләнгән заводларыбызның экологиягә тискәре йогынты ясавы, атмосферага составында 1 һәм 2 классы зарарлы матдәләре булган калдыклар чыгаруы мөмкин түгел! Шуны аңларга кирәк: һәр сәнәгать предприятиесе әйләнә-тирә мохиткә билгеле бер йогынты ясый. Монда атмосферага чыгарылган матдәләрнең составы, аларның су объектларына агызылуы, концентрациясе һәм күләме мөһим. Безнең заводларда барлык зарарлы матдәләрнең чыгышын, аларның таралышын бәйсез онлайн-мониторинг системасы контрольдә тотачак. Рөхсәт ителгән чик күрсәткечләрдән теләсә нинди тайпылыш җиһазларны туктатуга сигнал булып торачак. Бу предприятиенең эш схемасында каралган. Болардан кала, гражданнарның иминлеге өчен, алар таләбе буенча, без әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясау буенча теләсә нинди лаборатор тикшеренүләр үткәрергә әзер. Теләсә кайсы лабораториядә.

Моннан тыш, предприятиеләрнең төзелеш мәйданчыгы янында үзара урнашу схемасын караганда, Осиново бистәсендә заманча газ чистарту системасы булган, калдыкларны энергиягә әйләндереп утильләштерү эшен күздә тоткан завод әйләнә-тирә мохиткә иң аз, янәшәдәге җитештерү предприятиеләре белән чагыштырганда, берничә тапкыр кимрәк йогынты ясаячак.

«Калдыклардан энергия» заводыннан ел дәвамында 670 тонна зарарлы матдә чыгарылачак дигәндә, җитештерү тармагы өчен кабул ителгән исәпләүләрдә зарарлы матдәләр бүлеп чыгару һәм таратуның мөмкин булган иң зур күрсәткечләре күздә тотыла. Чынлыкта исә алар тагын да азрак булачак. Әгәр саннарны хәзерге вакытта гамәлдә булган шундый ук Европа заводлары белән чагыштырып карасак, шул ук «Казан Оргсинтез» һәм ТЭЦлардан чыгарылган зарарлы матдәләр уннарча мең тоннага җитә, ә төгәлрәк әйткәндә, елына – 37 мең тоннага якын!

Калдыкларны яндырып утильләштерү заводының һаваны пычратуга керткән өлеше 2 проценттан да кимрәк. Зарарлы матдәләр арасында диоксиннар 0,047 граммнан да артык түгел. Бер елга! Искә төшереп үтик: республика экология министры Александр Шадриков үзенең чыгышында әйтеп үткәнчә, янып яткан бер чүплек берьюлы 100 грамм диоксин бүлеп чыгарырга сәләтле – калдыкларны термик эшкәртү өчен төзелгән заманча завод бу кадәр диоксин бүлеп чыгарсын өчен, 2 мең ел эшләргә тиеш... Самосыроводагы чүплек бер атна янганда, Казан халкы инде күпме зарарлы матдә сулаганын санап карагыз әле.

ИНВЕСТОР БЕЛЕШМӘСЕ

Россиядә калдыкларны энергиягә әйләндереп утильләштерү буенча заводлар төзү проектының партнеры булып торган Hitachi Zosen Inova Япония-Швейцария консорциумы каты көнкүреш калдыкларын экологик яктан куркынычсыз ысул белән юк итү юнәлешендә дөньяның иң алдынгы ширкәтләреннән санала. Без кешеләрнең сәламәтлеген куркыныч астына куярга теләмибез, шуңа күрә дөнья тәҗрибәсен җентекләп өйрәндек һәм гарантияләнгән куркынычсыз технологияләргә өстенлек бирдек. Дөньяның алдынгы дәүләтләре шундый ук фикердә: хәзерге көндә Hitachi Zosen Inova компаниясе Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Франция, Төркия һәм башка илләрдә бездәгедәй проектларны гамәлгә ашыра. Компания бөтен дөнья буенча 500 дән артык завод төзегән, өстәвенә, «РТ-Инвест» консорциумнан өр-яңа җиһазлар сатып ала, алар предприятиенең әйләнә-тирә мохит өчен куркынычсызлыгын тәэмин итәчәк.

Декабрь башында Европа берлегендә «Калдыклардан энергия» заводларын төзү өчен иң яхшы кулай технологияләрнең (BAT) яңа стандартлары кабул ителде. Калдыкларны эшкәртү өлкәсендә төп басма саналган Waste Management World, Европа берлегенең рәсми журналы мәгълүматларына нигезләнеп, бүген Европа илләрендә рәшәткәле яндыру технологиясен куллануны күздә тоткан 32 «Калдыклардан энергия» заводы төзелеп килгәнлеген, шулай ук 30–40 ел элек төзелгән иске предприятиеләрне яңарту эше алып барылганын раслый. Франциядән тыш, заводларны Швеция, Польша, Германия һәм Литвада төзиләр. Бөекбританиядә иң соңгы завод 2019 елның декабрендә файдалануга тапшырылган.

«РТ-Инвест» компаниясенең Россиядәге барлык заводлары да Европа стандартларына туры киләчәк.

«Бүген дөньяда, термик эшкәртүдән тыш, чүплекләрне тулысынча юк итүгә алмаш юк. Әмма дә ләкин бу тармакта, шул исәптән Россия өчен дә, калдыкларны сортларга аеру һәм икенчел чималга эшкәртү төп өстенлек булып кала. Аннары гына, икенчел чимал алу өчен файдаланып булмый торган калдыкларны эшкәртеп, энергиягә әйләндерү мәсьәләсе карала. Бүген чит илнең өр-яңа технологияләре һәм чистарту системалары әйләнә-тирә мохиткә тәэсирне иң аз дәрәҗәгә төшерергә мөмкинлек бирә. Бу очракта теләсә кайсы сәнәгать предприятиесе күз уңында тотыла – балалар уенчыклары җитештерү фабрикасы булсынмы ул, калдыкларны энергиягә әйләндереп утильләштерү заводымы», – диде МДУ профессоры, Россия Табигый фәннәр академиясе вице-президенты, химик куркынычсызлык проблемалары буенча БМО белгече, «Химия һәм әйләнә-тирә мохит» Европа комитеты әгъзасы Валерий Петросян.

Заводлар – чүп-чар белән эш итү системасының бер кисәге, мәҗбүри сортировкадан соң төгәлләү этабы гына ул. «РТ-Инвест» мәсьәләне комплексы хәл итә: калдыкларны аерым җыю һәм алып чыгу гамәлгә кертелә, калдыкларны сортларга аеру буенча заманча комплекслар төзелә, аларның беренчесе 2019 елның көзендә Коломна янында ачылды. Бу эш Казанда да алып барыла.

Елена Бикташева,
ээкоактивист, иҗтимагый хәрәкәт юристы:

– Без ЧЯЗдан бүленеп чыккан авыр металлар, терекөмеш һәм диоксиннар зыян китерә алмаячак, дигән сүзләр белән килешмибез. ЧЯЗ – шул ук чүплек ул, бары күктә генә. Чынлыкта тискәре йогынты шактый күбрәк булачак, инвестор ОВОС проектында шартлы рәвештә зарарсыз саналган CO2 турында искә алмаган. Завод бик зур күләмдә һава кислородын яндырачак. Билгеле булганча, диоксиннарның куркынычсыз концентрациясе юк. Бары тик алар бөтенләй булмаганда гына тормыш өчен куркыныч янамый. Диоксиннарның зыянын күп тапкырлар көчәйтүче катализатор ролен шул ук авыр металлар һәм «Казан Оргсинтез» ГАҖ бүлеп чыгарган зарарлы матдәләр башкарырга мөмкин. Халык күп яши торган «Салават күпере» микрорайоны, Осиново бистәсе, Мәскәү районы өчен ике предприятиенең зыяны, алар бүлеп чыгарган зарарлы матдәләрнең кумулятив тәэсире турында алдан әйтеп булмый. Шуңа күрә без ЧЯЗ бүлеп чыгарачак зарарлы матдәләрнең ролен барлык предприятиеләр атмосферага бүлеп чыгарган калдыкларның гомуми күләмендәге бик кечкенә өлеше (2 процент) белән бәйләп, киметеп карау дөрес түгел, дип саныйбыз. ЧЯЗ турында технологик күзлектән тәнкыйть белән җентекләбрәк Сосновцев, Мазурин, Плужникова мәкаләләрендә, шулай ук «Активатика» интернет порталының ЧЯЗ темасы буенча язмаларында танышырга мөмкин.

Елена Ямщикова,
АКГ-1ның («РТ-Инвест» структурасындагы Альтернатив генерацияләүче компания) экология буенча директоры:

– Кызганыч, гамәлдәге предприятиеләр атмосфераны пычрату чыганаклары булып тора, шул исәптән алар һавага авыр металлар да бүлеп чыгара. Калдыкларны энергиягә әйләндереп утильләштерү заводы полигоннар һәм аларның тискәре йогынтысына бәйле проблеманы хәл итәргә тиеш. Ә андый полигоннар югары технологияле заводка караганда күпкә зарарлырак. Шунысы мөһим: диоксиннар чүп яндырганда гына бүленеп чыкмый. Алар, әйтик, хәтта без шашлык кыздырганда да барлыкка килә. Көнкүрештә һәм табигатьтә диоксиннар синтезын табу өчен ерак китәргә кирәкми. Температура 1200 градустан югарырак булганда, диоксиннарның молекуляр структурасы юк ителә, завод технологиясе әнә шуны күздә тота да. Чүплекләр проблемасын хәл итәр өчен, бөтен цивилизацияле дөнья бүген шундый ук заводлар төзи. Калдыкларны югары температура белән утильләштерү – экологик яктан куркынычсыз һәм дөрес ысул – әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган барлык чүплекләрне ябу мөмкинлеге ул. Өр-яңа технологияләрне тәнкыйтьләп, сез алмашка нәрсә тәкъдим итә аласыз? Полигоннарны калдырыргамы? Без чүп-чарны аерым җыю системасын кертәбез, аны сортларга аеру комплекслары төзибез һәм цикллы икътисад принципларына таянабыз. Заводка бары тик эшкәртүгә яраксыз калдыклар гына киләчәк. Завод төзелеше мәйданчыгы республика хакимияте белән килештерелде. Инвестор өчен инженерлык челтәрләренә тоташу һәм энергиягә әйләндереп утильләштерүгә бәйле «койрык»ларны китерү логистикасы мөһим иде.

Җирле халык безнең мәгълүмат үзәгендә барлык мәгълүматларны ала алачак. Ул күчмә булачак һәм мөрәҗәгать нигезендә халык өчен уңайлы вакытта һәм җайлы урынга чыгачак.

– ТР экология министры Александр Шадриков үзенең чыгышында әйтеп үткәнчә, янып яткан бер чүплек берьюлы 100 грамм диоксин бүлеп чыгарырга сәләтле – калдыкларны термик эшкәртү өчен төзелгән заманча завод бу кадәр диоксин бүлеп чыгарсын өчен, 2 мең ел эшләргә тиеш... Самосыроводагы чүплек бер атна янганда, Казан халкы инде күпме зарарлы матдә сулаганын санап карагыз әле, – дип мөрәҗәгать итә завод төзелешенә каршы чыкканнарга Елена Ямщикова.

Фото «Казань без свалки» сайтыннан алынды. Самосырово чүплеген рекультивацияләү старты

Елена Бикташева,
экоактивист, иҗтимагый хәрәкәт юристы:

З – Төтен газларын һавада асылынып торчак вак дисперсияле тузан кисәкчекләреннән (һавада эленеп торырга сәләтле PM 10, PM 2,5 үлчәмендәге) нәтиҗәле чистарту ничек тәэмин ителәчәк?

Елена Ямщикова,
АКГ-1ның («РТ-Инвест» структурасындагы Альтернатив генерацияләүче компания) экология буенча директоры:

– Проектта төтен газларын чистартуның өч баскычтан гыйбарәт югары нәтиҗәле системасын куллану концепциясе кабул ителде, әлеге системаны проектлау һәм җитештерү проектның техник партнеры – Hitachi Zosen Inova (HZI) компаниясе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Басым ясап китик, чистарту баскычлары саны калдык газларны аруландыруның нәтиҗәлелегенә кимүне белдерми. Чит ил партнерыбыз белән контрактта теркәлгән гарантияле нәтиҗә мөһим. Баскыч биш басмалы да, өч басмалы да булырга мөмкин. Газларны чистарту белән дә шулай. Нәтиҗә барыбер бертөрле булачак – сез кирәкле биеклеккә менәсез яки кирәкле чисталык дәрәҗәсенә ирешәсез. Һавага чыгарыла торган газлы һава катнашмасын тузаннан тиешенчә арындыру өчен, компания җиңсәле фильтр кулланачак. Әлеге фильтр каты тузан кисәкчекләрен, шулай ук газ чистартуның әүвәлге этапларында ярдәмгә кертелгән өстәмә матдә калдыкларын аерып, тотып калдырырга мөмкинлек бирә. Мондый алым каты тузан кисәкчекләреннән арындыру чаралары исемлегенә кертелгән, әлеге чаралар «Калдыкларны термик ысул белән зарарсызландыру (калдыкларны яндыру)» ИТС 09-2015нең иң яхшы технологияләре буенча мәгълүмати-техник белешмәдә күрсәтелгән.

Чүп-чарны аерып җыю пунктлары Казанда ят күренеш түгел. Шундыйларның берсе башкаланың Гаврилов урамында пәйда булды.

Фото: Эскәр Сабиров

Елена Бикташева,
экоактивист, иҗтимагый хәрәкәт юристы:

– Еврокомиссия 2017 елның 26 гыйнварында кабул ителгән «Циклы икътисадта калдыклардан алынган энергиянең роле» коммюникесенда чүп яндыру мәсьәләсенә үз карашын билгеләде. Документ нигезендә, Европада ЧЯЗ төзү эше хупланмый, андый төзелеш банклар тарафыннан финансланмаска, аңа өстәмә салымнар билгеләнергә тиеш, ә иң яхшысы, Европа илендә акрынлап иске заводларны ябып, яңа ЧЯЗларга мораторий режимы гамәлдә булу. ЧЯЗ урынына Еврокомиссия калдыкларны эшкәртү («калдыклардан энергия» ысулын исәпкә алмыйча, 75 процентка кадәр) буенча катгый максатчан таләпләр кертә, шулай ук органик калдыкларны анаэроблар таркату өчен предприятиеләр төзергә тәкъдим итә. Хәзерге вакытта HZI, нигездә, Европада «калдыклардан энергия» урынына (өченче дөнья илләре моннан чыгарма) аларны анаэроб әчетү, черетү буенча фабрикалар төзүгә күчте. ЧЯЗга альтернатива сыйфатында без Европадагы яңа тенденцияләрне өйрәнергә тәкъдим итәбез. Бу чүп-чарны яндыруны түгел, аның барлыкка килүен киметүне, калдыкларны тирән эшкәртүне,аерып җыюны күз уңында тота. ЧЯЗны чүплекләргә алмаш сыйфатында тәкъдим итү дөрес түгел, дип саныйбыз, чөнки бөтен дөньяда бары эшкәртелми торган «койрыклар» гына яндырыла. Казандагы ЧЯЗда «койрык»ларны яндыру турында сүз бармый, чөнки башкала чүп-чарының 94 процентына кадәрен (ТР калдыклар белән эш итүнең территориаль схемасыннан алынган мәгълүматлар) яндыру планлаштырыла. ЧЯЗны төзегәч, Казан аңа бәйле булачак, чөнки икътисадый яктан заводны чимал белән «туендырып тору» зарур, эшкәртү турында бернинди сүз дә бармаячак. Югарыда аталган территориаль схема нигезендә, ел саен калдыклар күләменең күбәю дәрәҗәсе 3 процентттан артмый. Ягъни 550 мең тонна чүп яндыруга исәпләнгән завод Казанга кирәкми. Татарстанның башка районнарыннан калдыклар яңа муниципальара полигоннарга озатылачак (аларны Алексеевск, Арча, Югары Ослан, Алабуга, Лениногорск районнарында төзү планлаштырыла). Казан ЧЯЗ мәсьәләсендә Швеция сценарием кабатламасын иде. Ул илдә әллә ничә ЧЯЗ төзиләр дә, озак сроклы контрактлар кушканча, аларны тәэмин итеп торырга тиеш булалар. Соңыннан Швеция, чүпне аерым җыю тәртибен кертеп, эшкәртү буенча югары максатчан күрсәткечләргә ирешә һәм яндырыр өчен чимал да калмады. Хәзер калдыкларны сатып алырга туры килә. Моннан тыш, рәшәткәле технология искергән дип санала, бу хакта Россиянең атказанган экологы, профессор, БМО белгече, РФ Президенты каршындагы Кеше хокукларын яклау советы әгъзасы Андрей Пешков та искә алды.

Дөнья практикасында теге яки бу «Калдыклардан энергия» заводларының экологик яктан куркынычсызлыгы турында уйдырмаларны ачып салу белән бәйле низаглар даими чыгып тора. Лондон мэры күптән түгел Riverside заводын иске һәм атмосфераны пычрата торган предприятие дип атады. АКШтагы ЧЯЗ белән бәйле җәнҗалларны мисал итеп китерергә мөмкин, нәтиҗәдә, соңгы 20 елда анда бер завод та төзелмәгән. Голландиядә 2011 елда төзелгән Reststoffen Energie Centrale чүп яндыру заводы белән бәйле җәнҗалны да искә алыйк. Табигатьне саклау юнәлешендәге максатларга ирешә алмау турында Еврокомиссия кисәткәннән соң, Европа берлеге банкы Белградта төзелә торган ЧЯЗ өчен финанслауны туктатты.

Елена Ямщикова,
АКГ-1нең («РТ-Инвест» структурасындагы Альтернатив генерацияләүче компания) экология буенча директоры:

– Коммюнике дөрес тәрҗемә ителмәгән, эчтәлеге тиешенчә ачып бирелмәгән. Европа берлеге «Калдыклардан энергия» заводларын төзүне дәвам итә. Бүген 30 дан артык завод төзелә. Британиянең Riverside заводы әлегә үзгәртеп кору стадиясендә. Моннан тыш, HZI заказы буенча безнең заводлар өчен дә җиһазлар җитештерә торган «Атомэнергомаш» предприятиесе Riverside өчен казаннар әзерләүгә заказ алган. Чүп яндыру заводлары кирәк булган урыннарда аларны төзиләр, алар искергән җирләрдә, үзгәртәләр, яңарталар. Россиядә без иң заманча заводлар төзибез, моны Hitachi белгечләре дә раслаячак. Шуңа күрә «Калдыклардан энергия» технологияләре искерде һәм экологик вазгыятькә тискәре йогынты ясый, дип белдерү чынбарлыкны чагылдырмый.

Анаэроб таркату җайланмалары исә алга таба биогаз җитештерү өчен органик чимал булуны күздә тота. Бу технология «койрыклар»дан котылуга алмаш түгел. Кабатлап үтәм, безнең заводларга чүп-чар бары тик сәнәгый нигездә сортларга аерылып, алардан барлык файдалы фракцияләрне алгач кына киләчәк. Комплексларыбызда органикадан компост җитештерәбез, шуңа күрә «койрыклар»да органик катнашмаларның калган өлеше бик аз. Билгеле бер технологиягә өстенлек биреп, беренче чиратта, без аның нәтиҗәлелеге һәм экологик куркынычсызлыгы принципларына таяндык.

«Казанда һәм Татарстанда ЧЯЗ – юк!» дигән иҗтимагый хәрәкәт активистлары: «ЧЯЗга альтернатива сыйфатында без Европадагы яңа тенденцияләрне өйрәнергә тәкъдим итәбез. Ә бу чүп-чарны яндыруны түгел, аның барлыкка килүен киметүне, калдыкларны тирән эшкәртүне, аерып җыюны күз уңында тота!»

ИҢ МАТУР ЯҢА ЕЛ ЧЫРШЫСЫ **КАЙСЫ АВЫЛДА?**

Гыйнвар ае дәвамында Татарстан авыллары һәм калаларында, балалар һәм олыларның кәефләрен күтәреп, Яңа ел чыршылары балкып утырды. Чыршылар берсеннән-берсе матур, берсеннән-берсе затлыдыр кебек тоелды. «Татарстан» да иң үзенчәлекле чыршыны эзләп, республикабыз районнарына юл тотты.

Фотолар проектта катнашкан авыл җирлекләре башлыкларыннан алынды.

КҮМӘК КӨЧ ТАУ КҮЧЕРӘ
НОВОТРОИЦК, ТУКАЙ РАЙОНЫ

Новотроицк авылында Яңа елны бик зурлап каршы алганнар. Унике чакрым ераклыктагы Чаллы шәһәрен санамаганда, якынтирәдәге бистә, авыллар арасында иң зур Яңа ел мәйданы монда булган.

2017 елда Новотроицк авылында дәүләт акчасына ял паркы эшләп куйганнар. Уен мәйданчыгы ясаганнар, тренажерлар урнаштырганнар. Хәтта 25 метр биеклектәге чыршы да алганнар. Чыршыга эләр өчен уенчыклар турында да онытмаганнар. Менә өч елдан бирле авыл халкы әнә шул гүзәллеккә карап соклана.

– Чыршыны гыйнвар азагында, хасиятләп җыеп, элеккеге авыл җирлеге идарәсе бинасына алып куябыз, – диде җирле җитәкчеләр.

Тагын шуны әйтергә кирәк: быел район Яңа ел бәйрәме Новотроицк авылында узган. Шуңа күрә яңа ял паркын районның төрле оешмалары килеп бизәгән. Күмәк көч тау күчерә, диләр. Яңа елга паркның әле болай затлы итеп бизәлгәне юк иде, ди халык.



АЛАРНЫ ҖЫЛЫ КЫШ КУРКЫТМЫЙ
СОСНА, БАЛТАЧ РАЙОНЫ

Кар яуганын көтеп арыгач, Сосна авылы халкы Яңа елга гомер иткән нигезләрен кар сыннарыннан башка бизәргә булган.

Быел исә сосналылар авылны ясалма сыннар белән бизәргә уйлаганнар. Кайбер капка төпләрендә агачтан эшләнгән хайван сыннары да пәйда булган.

Мәдәният йорты, фельдшер-акушерлык пункты кебек халык күп йөри торган социаль объектларны каршыларында басып торган Кыш бабай, Кар кызы, җәнлек сыннары бизи. Авыл җирлеге идарәсе аларны махсус сатып алган.

– Хәзер кышка ышаныч юк, – ди сосналылар. – Кардан, боздан ясалган сыннар ике көн эчендә эреп бетәргә мөмкин. Ә менә ясалма сыннар юкка чыкмый. Хасиятләп җыеп куйсаң, киләсе елга да ярый.

Менә шулай җаен тапкан Сосна авылында яшәүчеләр. Аларны хәзер җылы кыш куркытмый!

«60–70 ТОННА БОЗ КИТТЕ!»
БАЛАНДЫШ, ТЕЛӘЧЕ РАЙОНЫ

Баландыш авылында икенче ел рәттән Яңа елны зурлап, урамнарны бизәп каршы алалар. Баландышлылар быел гади кар сыннары ясау белән генә чикләнмәгәннәр, ә авыл үзәгендә боз шәһәре дә төзегәннәр.

– Дүрт ир-ат бер атна эчендә менә шушындый гүзәллекне тудырды, – дип сөйләде безгә Баландыш авыл җирлеге башлыгы Рөстәм Мөхәммәтшин. – Шәһәрне ясар өчен плотинадан җиде «КАМАЗ» – 60-70 тонна боз гына кисеп алып кайттык. Моны эшләүче егетләргә зур рәхмәт, бик тырыштылар.

Тырышлык бушка китмәгән, әлеге гүзәллекне күрергә Баландышка бөтен тирә-яктан җыелганнар. Яңа ел ялларында урам тулы халык булган: җырлаганнар да, биегәннәр дә. Кыскасы, баландышлылар шәһәр халкыннан ким.яп итмәгән.



ЯҢА ЕЛГА УРАМНАРНЫ БИЗӘҮ – ТРАДИЦИЯ

ОЛЫ АЧАСЫР, ЯШЕЛ ҮЗӘН РАЙОНЫ

Олы Ачасыр авылы халкы ел саен капка төпләрен төрле сыннар белән бизи. Бу инде традициягә әйләнгән. Быел да халык бу эшне яратып башкарган. Узган еллардан аермалы буларак, ачасырлылар Яңа елны Үзәк паркта каршылаган. Биредә зур чыршы куйганнар. Паркның тирә-юнен утлар, сыннар белән бизәгәннәр. Күңел ачу өчен бик матур урын барлыкка килгән.

Сүз уңаеннан, Үзәк паркны 2018 елда яңадан эшләгәннәр. Авыл урамнарын төзекләндерү программасында катнашып, Олы Ачасыр авылы 1 миллион сумлык грантка ия булган. Кайчандыр куе агачлар үскән бу урында бүген парк – ел әйләнәсе яктылык, балалар, олылар җыелып күңел ача.

КЫШКЫ САБАНТУЙ
МУЛМӘ, БИЕКТАУ РАЙОНЫ

Мулмә авылында чын мәгънәсендә Кышкы Сабантуй уздырганнар. «Мондый могҗизаны күргән юк иде әле», – дип, соклануларын яшермәде авыл кешеләре. Чыршы бәйрәме ачылышына район җитәкчелеге дә, тирә-як авыллардан да килгәннәр. Боз сарае, балалар өчен шугалак дисеңме, төрле сыннар – барысы да кышкы әкият илен хәтерләтә.

– Атна-ун көн эчендә үзебезнең Красная елгасыннан боз кисеп алып, боз сарае, шугалак ясадылар. 27 декабрьдә бик зурлап чыршы бәйрәмен ачу тантанасын оештырдык, Казаннан артистлар да килде, – диделәр Мулмә авыл җирлегендә.

Беренче коймак төерле була, дисәләр дә, мулмәлеләр төерне сизмәгәннәр. Бик матур, күңелле бәйрәм килеп чыккан.

ҮЗЕБЕЗ ӨЧЕН ЭШЛИБЕЗ

КИЧКЕТАҢ, ӘГЕРҖЕ РАЙОНЫ

Яңа елга авыл урамнарын бизәү буенча алар берничә ел инде районда беренчелекне бирми икән. Сүз Әгерҗе районының Кичкетаң авылы турында бара. Быел да бу авыл районның Яңа елга бизәлгән иң матур авылы исеменә лаек булган. Кар явып кинәндермәсә дә, авыл халкы әллә нинди биек сыннар ясап куйган.

– Ел саен хуҗалыклар арасында «Иң матур капка төбе» дигән конкурс игълан итә идек, – диде Кичкетаң авылы җирлеге башлыгы Зөлфәт Нуриев. – Быел конкурс игълан итмәдек. Шулай да халык узган елгыга караганда сыннарны күбрәк ясады. Бу тагын бер кат халыкның эчкерсезлеген күрсәтә – конкурс өчен түгел, үзебез өчен эшлибез. т

– «Татарстан»ның 100 еллык юбилеен без инде киләсе гасырда бәйрәм итәрбез, дип уйлыйм. Ул заман нинди булыр – без белмибез. Ләкин кешеләр барыбер яшәячәк, төзиячәк, эшләячәк һәм иҗат итәчәк. Әлбәттә, журналлар һәм газеталар да чыгачак. Һәм алар арасында безнең яраткан басмабыз – «Татарстан» журналы да булачак, – дип яза журналның 75 еллыгына багышланган мәкаләсендә Асия Махнина.

9 «ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ГОМЕРЕ. БЕРЕНЧЕ ГАСЫР

2020 елда «Татарстан» журналына нәкъ 100 яшь тула! Бер гасыр дәвамында ул республика тормышы белән янәшә атлый, татарстанлылар белән бергә иңне-иңгә куеп эшли, һәр санында үз геройлары белән йөзгә-йөз очраша... Барлык мөһим вакыйгалар үзәгендә кайный, алар турында сөйли, хатирәләрне барлый, язучы-шагыйрь-журналистларның, иң беренче чиратта – укучыларының дустына әверелә. ТР Милли китапханәсенең периодик басмалар бүлегендә журналның соңгы (ә бәлки – беренче) йөз елында басылган һәр саны диярлек саклана. Вакыт галиҗәнаплары саргайткан басма битләрендә язылган, басылган һәм мәңгеләштерелгән төрледән-төрле мәгълүмат, оригиналь хикәяләр һәм уникаль тарихлар барысы да бәһасез кыйммәткә ия.

100 ел яшәү дәверендә замана җилләре тәэсирендә журнал тугыз мәртәбә исемен алыштыра. Бигрәк тә давыллы 1920 нче елларда исем алыштыру белән мавыкканнар, кайчак басма елына икешәр мәртәбә дә атамасын үзгәрткән...

Фото: Алёна Кутыркина

1920

Туганда – 1920 елның 1 декабрендә – журнал **«Вестник областкома РКП ТССР»** дигән исем ала. Беренче сан ТАССР төзелү турында Декрет имзаланганнан соң ярты ел узгач «туа», тиражы 3000 данә була һәм ул яшь республиканың яңа теоретик, сәяси басмасына нигез сала. Аның беренче мөхәррире һәм иң күп язучы журналисты партия өлкә комитетының беренче секретаре Александр Таняев була. Сәяси басмаларга хас булганча, ул партия эшчәнлеген, пролетариат тормышын яктырта, төрле циркулярлар һәм инструкцияләрне бастыра, агитация һәм пропаганда белән шөгыльләнә. Күпләгән тарихи-партия хезмәтләре авторы 1937 елда кулга алына һәм 19 ел ГУЛАГта утырганнан соң гына ирекккә чыга.

ВЕСТНИК
Татарского областного комитета Российск. коммунистич. партии (большевиков)
Двухнедельный орган
№ 1 (15) Среда, 1-го декабря 1920 г. № 1 (15)
На переломе.

1921

Бер яшендә, 1921 елның сентябреннән, журнал **«Спутник агитатора»** дип атала башлый. Ул яңа икътисадый сәясәт (НЭП) сорауларын, «яңа курс»ның төп бурычларын яктырта. «В партколлегии КПК» рубрикасында 1921 ел укучыларына, ә бүген инде 2020 елгыларга да, кадрларны чистарту турында коры фактлар тәкъдим итә: «Партиядән чыгарылалар: Суслов С.Д. – татар-башкорт мәктәбенең география укытучысы, Колчак һәм Аненков контрразведкасының элеккеге тикшерүчесе Доболасов белән элемтәсе өчен; Питковская Б.Н. – троцкист Крамов белән элемтәсе өчен; Волосов А.И. – авыл хуҗалыгы институты директоры, кондратьевчылар һәм чаянлылар белән дуслыгы һәм троцкист М. Корбутны (соңрак репрессияләнгән) яклаганы өчен…» Коры фактлар артында – йөзләгән фамилия, йөзләгән язмыш… Журналның әлеге саннарына карата һәрвакыт аерым игътибар күзәтелә, кешеләр бу саннарда респрессияләнгән туганнары турында мәгълүмат эзли.

«Спутник агитатора» исеме астында журнал дүрт сан чыгара!

1921

Дүрт саннан соң журналның исемен тагын үзгәртәләр. 1921 елның ноябреннән соң ул **«Коммунистический путь»** дип атала башлый, РКП (б) өлкә комитетының һәм Татреспублика Главполитпросветының басма органына әверелә. 26 сан чыгарыла, тираж төрле елларда төрлечә була – 1200 данәдән 2000 гә кадәр. «Үзенең беренче адымнарыннан ук журнал партия ягыннан игътибар һәм кайгыртучанлык тоя, – дип сөйләде безгә **ТР Милли китапханәсенең периодик басмалар бүлеге мөдире Асия Махнина.** – Аның эше белән шәхсән Владимир Ленин үзе кызыксына, юлбашчының Кремльдәге китапханәсендә журналның 1922 елда чыккан 10 нчы саны саклана». Марксизм-ленинизмга, партия эшчәнлегенә кагылышлы сораулардан тыш, журнал киң иҗтимагый мәсьәләләрне дә күтәрә башлый: дингә каршы көрәш, яшьләр һәм хатын-кызларның революцион хәрәкәте, профсоюзлар эше, Бөтенроссия ҮБК закон проектлары, районнар тормышы, партия укулары, пролетар мәдәният, яңа суд сәясәте, иминият системасын үстерү, коммунистик этика, милли мәсьәләләр, әдәби очерклар, тәнкыйть, геосәяси күзәтүләр… 1922 елда журналда беренче мәртәбә реклама урын ала. 1923 елда беренче тапкыр журналга язылу түләүлегә әйләнә: 1 айга – 6 сум.


Пролетарии всех стран, соединяйтесь!
КОММУНИСТИЧЕСКИЙ ПУТЬ
Орган областного комитета РКП (б) Татарской организации.
№ 1 Январь 1925 г. (30)
Содержание:
Стр.
1. Морозов. К X областной партийной конференции 3
2. Н. дачин. ОКК—РКИ к партийной конференции 5
3. Павлова. Задачи парторганизации по работе среди крестьянок и работниц 8
4. Павлов. Очередные задачи татарской организации РЛКСМ 12
5. Работа Областного Комитета РКП (б): отчет X-й областной конференции за май—декабрь 1924 г. 15
Советское строительство.
5. Петров. Предварительные итоги по перевыборам сельсоветов и волисполкомов Татарии 35
Наша печать.
7. К. Магнов. Печать и „нечто“ 39
8. Л. Гумеров. Кое-что о непериодической печати 41
Критика и библиография.
9. Журналист. Производительность труда. Организация промышленности 43

1925

Дөнья пролетариаты юлбашчысы үлеменең бер еллыгына һәм аның истәлегенә «Коммунистический путь» 1925 елның 21 гыйнварыннан **«Путь Ильича»** дип үзгәртелә. Ул Ленин эшен, СССРда һәм чит илләрдә коммунизмны үстерү сорауларын киң яктырта. «Безнең фикеребезчә һәм йөзләгән иптәшебезнең бәяләмәләренә караганда, – дип яза үзгәртелгән журнал редакциясе үзенең баш мәкаләсендә. – «Коммунистический путь» артык авыр, массакүләм укучыга аңлашылмый иде. «Путь Ильича»

журналында без үзебездә, Татариядәге, һәм көнчыгыш илләрдәге (Төркия, Иран, Кытай, Әфганстан h.б.) партия тормышын тулырак яктыртырга тырышачакбыз».

Журнал мәдәният өлкәсендәге вакыйгаларга игътибарын арттыра. 1925 елда Татреспублика Парижда оештырылган халыкара декорация эшләре күргәзмәсендә катнаша. Бу турыда болай дип хәбәр бирә: «Татреспублика күргәзмәдә чигешләр, баш киемнәре буенча бик бай бүлек тәкъдим итә, шулай ук көнчыгыш телләрдәге китаплар күрсәтелгән үзенчәлекле бүлек тә бар, анда да Татреспублика китаплары аерымачык күренеп тора».

Сәяси материаллар белән бергә, журналда әдәби әсәрләр – шигырьләр, очерклар, хикәяләр күренә башлый, тәнкыйть әсәрләре, рәсемнәр һәм фотолар пәйда була.

1925

Әдәби юнәлешнең көчәюе нәшер итүчеләрне басманың исемен яңадан алыштырырга мәҗбүр итә. Һәм 1925 елның 1 маенда коммунистик «Путь Ильича» басмасы романтик **«Причал»**га – әдәби-иҗтимагый журналга әверелә.

«Журналыбыз укучыларының теләкләрен искә алып, без үзебезгә «Причал» исемен алдык», – дип аңлата яңа исемне редакция. Нинди теләкләр булган соң алар? «Гомумсәяси мәсьәләләр белән беррәттән, дөнья хроникасы, фәне, техникасы һәм беллетристикасы сорауларын да яктыртырга». Һәм чыннан да вәгъдәләрен тотып, әлеге тематика чыннан да шактый киң яктыртыла башлый. Журналның җаваплы мөхәррире булып Г. Цыпин эшли. Басмада еш кына М. Корбут һәм ул чорда Казан циркы директоры булып эшләгән А. Зиберов үз мәкаләләрен бастыра. Татария Халык комиссарлары Советы рәисе Хаҗи Габидуллин журнал битләрендә даими чыгышлар ясый. «Причал» битләрендә Сәгыйть Рамиев, О. Бать-Чернышов, Давид Виленский, Михаил Рудерман шигырьләрен укырга мөмкин була. Монда союз дәрәҗәсендәге һәм чит ил язучыларының әсәрләре белән танышалар. Әйтик, Максим Горький («Никита Рубцов»), Владимир Маяковский («Радио-агитатор»), О. Генри («Тому, кто ждёт»), Василий Каменский («Пожар Пугачёвский», «Емельян Пугачёв» поэмасы бүлеге) һәм башка авторларның әсәрләре дөнья күрә. Журнал битләреннән без Казанда ике властьлылык – Милли Шура һәм Хәрби Шура вакытлары (1918 ел) турындагы мәгълүматны да таптык.

Укучылар шулай ук журналда башка илләрдә ничек яшәүләре турында укыганнар. Республикадагы эре җитештерү предприятиеләре – «Спартак» фабрикасы, сабын заводы, Бондюг химия заводы турындагы материаллар сәнгатьчәрәк бирелә башлый…

1926

Ләкин бер ел да үтәргә өлгерми, 1926 елның мартында басманың исемен кабат үзгәртәләр. Бу юлы ул **«Спутник партийного активиста»** дип атала башлый, эчтәлеге турында исеме үк әйтеп тора. ВКП (б) өлкә комитетының ай саен чыгарга тиешле теоретик һәм сәяси басма органы тәп-түгәл ун мәртәбә рус телендә дөнья күрә. «Спутник партийного активиста» журналына пар итеп татар телендә партия өлкә комитетының «Җитәкче» журналы чыгарыла башлый. Соңгысы 1932 елга кадәр нәшер ителә һәм **«Татарстан большевигы»** итеп үзгәртелә. Бөек Ватан сугышына кадәр шушы исемдә барлыгы 139 сан чыгып кала.

1932

1932 елдан «Татарстан большевигы» рус телендә дә басыла башлый. 3000 данә тиражы булган **«Большевик Татарии»** басмасы ВКП (б) татар өлкә комитетының төп журналына әверелә. Ул җирле партия комитетларының, бигрәк тә беренчел оешмаларның, эшен һәм тәҗрибәсен гомумиләштерергә һәм киң яктыртырга тиеш була. Әлеге исем астында ул, татарча варианты кебек үк, 1941 елга кадәр нәшер ителә. Бу елларда җаваплы мөхәррирләр булып Б. Абдуллин (1935 ел), Л. Пинхасик эшли.



Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

ТАТАРСТАН БОЛЬШЕВИГЕ

ВКП(б) ның Татарстан өлкә комитеты журналы

Айга ике тапкыр чыга. | № 9/2 МАЙ 1940 ел. | Адрес: ВКП(б) ның Өлкә Комитеты.

ПАРТИЯ ПРОПАГАНДАСЫНА БОЛЬШЕВИСТИК ҖИТӘКЧЕЛЕК ИТӘРГӘ

„ВКП(б) тарихының кыскача курсы" чыгу һәм партия пропагандасын оештыру турында Үзәк Комитетның 1938 нче ел 14 нче ноябрь карары кадрларыбызның идея ягыннан үсүе өчен киң юл ачты. Партияле һәм партиясез большевиклар „Кыскача курс"ны үзлекләреннән өйрәнү процессында революцион теорияне һаман саен тирәнрәк һәм нигезлерәк үзләштерә баралар. Бу нәтиҗәле эш кадрларыбызда аларның үз көчләренә ышанычны арттырды, марксизм-ленинизм әдәбиятына карата тәм тудырды.

Марксизм-ленинизм нигезләрен үзләштерү, идея-политик яктан өзлексез үсү кадрларыбызның практик эшенә дә уңышлы йогынтысыз калмый, әлбәттә. Чөнки ул безнең кадрларыбызның дөньяга карашын киңәйтә. Марксизм-ленинизм теориясе „обстановкага карата ориентировка алу мөмкинлеген, әйләнә-тирәдәге вакыйгаларның эчке бәйләнешен аңлау мөмкинлеген, вакыйгаларнең барышын алдан күрү һәм вакыйгаларнең хәзерге вакытта ничек һәм кайда таба үсүләрен генә түгел, бәлки аларның киләчәктә ничек һәм кайда таба үсәргә тиешлеген дә танып-белү мөмкинлеген бирә".

Партияле һәм партиясез актив арасыннан күп кенә иптәшләр хәзер инде „ВКП(б) тарихының кыскача курсын" үзлекләреннән өйрәнүне тәгәлләп, марксизм-ленинизм классикларының төп әсәрләре буенча тагын да тирәнтен өйрәнүгә күчтеләр. Мәсәлән, Казан шәһәренең Бауман районында 175 кеше, Мизләлә районында 23 кеше „Кыскача курс"ны өйрәнүне тәгәлләделәр. Мондый иптәшләр хәзер һәрбер районда бар.

Партия членнарының һәм кандидатларының гаять күп өлеше партия тарихының Октябрь Социалистик революциясеннән соңгы чорын өйрәнә. Ләкин, әле „Кыскача курс"ның беренче бүлекләренән узмаган иптәшләр дә аз түгел. ВКП(б) тарихын, аның теориясен үзлегеннән өйрәнүчеләргә партия оешмаларының ярдәме дә шуңа ярашлы рәвештә, дифференциаль төстә оештырылырга тиеш.

ВКП(б) тарихын урта звено буенча өйрәнүне тәгәлләп, марксизм-ленинизм классикларының әсәрләре буенча өйрәнүгә күчкән

1

1958

Бөек Ватан сугышы елларында һәм аннан соңгы җимерекләрне торгызу чорында журнал басылмый. 1958 елның гыйнварыннан **«Татарстан коммунисты»** һәм **«Коммунист Татарии»** исемнәре астында татар һәм рус телләрендә нәшер ителә башлый. Тиражы төрле елларда 6000–30000 данә тирәсендә тибрәлә. Басма битләрендә КПСС өлкә комитеты секретарьларының чыгышлары, коммунизм һәм социализм турындагы лекцияләр һәм консультация текстлары урын ала, икътисад, сәясәт, җәмгыять, тарих, мәгариф һәм әдәбият турындагы материаллар белән фәнни хезмәткәрләр, предприятие җитәкчеләре, җәмәгать активистлары чыгыш ясый. Журналда укучыларның хатлары да басыла, араларында Бакый Урманченың хатларын күрергә мөмкин. Әдәби хикәяләр дә дөнья күрә, шул исәптән Туфан Миңнуллинның – «Мин», Дж. Оруэллның «Заметки о национализме» әсәрләре бар.

«Басма – теләсә кайсы партиянең ныклы идея коралы». «Татарстан коммунисты» журналының басылуы илебездә Ленин милли сәясәте тантанасының бер күрсәткече…» – дип яза җаваплы мөхәррир Шәмси Хамматов.



1991

1991 елдан «Татарстан коммунисты» **«Татарстан»**га әверелә. «Хәерле юл, «Татарстан», үзеңнең меңләгән кешелек аудиторияңә лаеклы бул», – диелгән «Татарстан» диген яңа, тугызынчы исемен алган басманың баш мәкаләсендә.

Журнал үзенең форматын һәм дизайнын берничә мәртәбә үзгәртә, төслегә, калынга әйләнә. 1991 елдан бирле басманың исеме үзгәрешсез кала бирә.

«Чагыштырырга рөхсәт итегез – «Татарстан» һәм «Путь Ильича» («Причал») үзара бай эчтәлекләре, темаларының төрлелеге, материалларының сайланышы, актуальлеге белән охшаш, дип саныйм, – дип яза журналның 75 еллыгына багышланган мәкаләсендә **Асия Махнина.** – Төрле елларда басылуларына карамастан, алар рухлары белән бер-берсенә охшаш. Журналга озын гомер, уңышлар телим. «Татарстан»ның 100 еллык юбилеен без инде киләсе гасырда бәйрәм итәрбез, дип уйлыйм. Ул заман нинди булыр – без белмибез. Ләкин кешеләр барыбер яшәячәк, төзиячәк, эшләячәк һәм иҗат итәчәк. Әлбәттә, журналлар һәм газеталар да чыгачак. Һәм алар арасында безнең яраткан басмабыз – «Татарстан» журналы да булачак».



Фото: Александр Ефремов

«Татарстан» журналы үзенең озак, вакыйгаларга бай эшчәнлеге дәверендә юбилейларны күп билгеләп үтте. 20 еллыгы, 50 еллыгы, 75 еллыгы, 80 еллыгы, 95 еллыгы... Барысы да әле генә үтте кебек. Журнал тупланмаларын карап утырганда илебезнең төрле почмакларында яшәүчеләрдән килгән фикерләрне, рецензияләрне һәм котлауларны очратабыз. Татарстанның беренче Президенты кебек даими укучыларыбыз басманың һәр юбилеен «Татарстан» журналына рецензия белән каршы ала – журнал ничек үзгәрә, кайсы мәкаләләр истә калырлык, кай як камилләштерүне сорый? «СЕЗ БУЛДЫРАСЫЗ!» дип әйтер өчен, тагын нәрсәләр эшләргә кирәк.

СЕЗ БУЛДЫРАСЫЗ!

Минтимер Шәймиев, Татарстан Республикасының беренче Президенты:

– «Татарстан» журналы – республикабызның яшьтәше, шуңа күрә аңа аерым бер миссия йөкләнгән. Ул Татарстан тормышында барган тарихи вакыйгалар елъязмасы гына түгел. Тарихны кешеләр тудыра, журналдагы очерклар һәм мәкаләләр – төрле елларда, кайчак хәтта бик кискен, авыр һәм катлаулы чорларда көндәлек фидакарь хезмәтләре белән республикабызны һәм илебезне алга әйдәгән кешеләргә хөрмәт күрсәтү, аларның истәлеген мәңгеләштерү. Бүген ачыкланганча, күпләрнең исемнәре йөз яшьлек журнал битләрендә генә сакланып калган. Журнал редакциясенең «Буыннар» проектын башлап җибәрүе бик күркәм гамәл. Мин, мәсәлән, ерак 50 нче, 60 нчы еллар турындагы материалларны рәхәтләнеп укыдым һәм янәдән яшьлек елларына кайткандай булдым. Юбилей елында «Татарстан»да республикабызның үткәне һәм бүгенгесе турында тагын да кызыклырак материаллар күтелә, дип өметләнәм.

«Татарстан» журналын даими укып барам һәм шунысын да әйтергә кирәк: соңгы елларда, журнал акыллы гамәлләр, игелекле эшләр һәм мәңгелек кыйммәтләр турында яза башлагач, материаллар тирәнрәк, эчтәлеклерәк була башлады, аларны бирү рәвеше дә яхшы якка үзгәрде, дип уйлыйм. Күңелгә үтеп керә, сокландыра һәм уйландыра торган фотосурәтләр дә ешрак күренә башлады. Бу, һичшиксез, журналда хезмәт куючы иҗат коллективының зур уңышы, аларга «Сез булдырасыз!» диясе килә.

Кто-то из мудрых сказал, «Чем больше в голове извилин, тем сложнее, извилистее жизненный путь». Судя по тем петляющим дорогам, которые привели журнал к его семидесятипятилетию, извилин в его «голове» хватает. А значит, не случайно этот журнал в наше беспокойное время остается уравновешенным, объективным, мудрым. Да и рассчитан он на таких же мудрых читателей.

Здоровья всем тем, кто делает и кто читает «Татарстан», спокойствия и душевного равновесия, благополучия в семье.

Михаил БОЯРСКИЙ,
заслуженный артист России

В Америке можно купить любое российское издание — «Огонек», «Известия», «Правду», «Сегодня», «Завтра», только журнал «Татарстан» купить там нельзя. Но я слежу за тем, что происходит в вашей республике. Она имеет свой приоритет: здесь народ имеет свой кусок хлеба. Я думаю, при нормальных обстоятельствах вы могли бы поднять уровень жизни очень высоко.

И все же — пожилые женщины стоят с протянутыми руками у гостиниц. Не потому, что они профессиональы-попрошайки, а потому, что от них уже отказались или у них уже нет сыновей... Но я бы хотел, чтобы у вас никогда не было нищих. Для этого нужно, чтобы у руля стоял человек, знающий свое дело. И журнал призван помочь власть предержащему.

Я хочу, чтобы журнал «Татарстан» и впредь печатал только правдивую, объективную информацию. И я по-прежнему буду приезжать в Россию, чтобы узнать истину о Татарстане. И увозить номера журнала с собой, своим американским соотечественникам.

С любовью из Америки!

Вилли ТОКАРЕВ



«ТАТАРСТАН» – АБРУЙЛЫ БАСМА

Роберт Миңнуллин, Татарстанның халык шагыйре:

– «Татарстан» – бер гасырлык журнал! Республикабызның яшьтәше! Бик бай тарихлы, эчтәлекле басма. Аның алтын битләренә Татарстан Республикасының, һичбер арттырусыз әйтәм, 100 еллык тарихы сыеп беткән! Мин аның «Татарстан коммунисты» булып чыккан чакларын да яхшы хәтерлим. Хәтта анда мәкаләләрем дә басылып чыккаңы булды. Аннары инде, үзгәреш җилләре исә башлагач, журнал «Татарстан» булып чыга башлады һәм бик популяр басмага әйләнде. Журналның ул чорда чыккан саннары да, журнал битләрендә басылган язмалар да миңа бик яхшы таныш. Чөнки редколлегия әгъзасы булып сайланганлыктан, аның эшендә турыдан-туры катнашырга, фикерләшергә, редакциягә килгән материаллар белән басылып чыкканчы ук танышып барырга туры килә иде...

Журнал Татарстанның иҗтимагый, сәяси, мәдәни һәм рухи тормышын һәрвакыт киң колач белән яктыртып барырга тырышты, җәмгыятебездәге кискен проблемаларны кыю рәвештә күтәреп чыкты. Ул дәүләт житәкчеләренең, халык депутатларының, җәмәгать эшлеклеләренең, иҗат әһелләренең алыштыргысыз мөнбәренә әверелде. Шуңа күрә дә һәрвакыт абруйлы басма саналды, Татарстанның визит карточкасы булып танылды. «Татарстан» журналы безгә ике дәүләт телендә чыгуы белән дә кадерле.



КИЛӘСЕ ЯҢА ГАСЫРЫҢ БЕЛӘН, «ТАТАРСТАН»!

Шамил Идиатуллин, журналист, язучы, «Коммерсантъ» Нәшрият йортының төбәк бүлеге җитәкчесе:

– Йөз яшь – зур гомер, олпат яшь… Кеше өчен генә түгел. Йөз ел эчендә ил юкка чыгарга, һөнәрләр үләргә, гаилә телен үзгәртергә, сүзнең мәгънәсе җуелырга мөмкин. Тормыш шулай корылган. Ләкин тормыш шуны да раслый: яңалык туа һәм исән калганнар, үскәннәр, ныгыганнар, сүзнең мәгънәсен, телнең ачыклыгын, һөнәрнең асылын саклаганнар, иле, гаиләсе һәм кеше үзе булсын өчен йөз ел дәвамында тырышып эшләгәннәр көче белән яңадан яшәвен дәвам итә. Киләсе яңа гасырың белән, «Татарстан»!

Как хорошо, что сегодня еще сохранились издания, наподобие журнала «Татарстан», которые отмечают такие вот юбилеи. Сиюминутные газетки рождаются и практически тут же умирают, а эти столпы отечественной периодики и сегодня в фаворе, и в эти смутные времена не потеряли читателей и, хочется верить, авторитета. Такой консерватизм я поддерживаю всей душой. И сердечно желаю «Татарстану» отметить 100-летие, 200-летие и так далее.

Никита МИХАЛКОВ,
кинорежиссер

Журнал родился раньше меня. Поэтому смело могу сказать, что слежу за ним всю свою жизнь, расту вместе с ним, набираюсь опыта. Журнал всегда шагал «в ногу» с жизнью, задавал темп республике,— а потому желаю ему дальнейшего процветания и неугасающей творческой активности.

Сейчас многие издания начали чернить нашу историю, вытаскивая на свет негативные факты. А ведь этим не очистишь, не облагородишь души тех, кому строить новую страну.

Искренне благодарен журналу за то, что он не пошел по пути «желтой» прессы, сохранив на своих страницах благородство истинного интеллигента.

Фуат МАНСУРОВ,
профессор, дирижер Большого театра Союза ССР, главный дирижер и художественный руководитель Государственного симфонического оркестра Татарстана, заслуженный деятель искусств Казахстана и Татарстана

КУЛЫҢДА КӘГАЗЬ ЖУРНАЛ ТОТУ – РӘХӘТ!

Гүзәл Уразова, Татарстанның халык артисткасы:

– «Татарстан» журналына инде йөз яшь дип белми идем! Искиткеч! Аны һәрвакыт яшь һәм заманча дип санадым. Еш кына сатып алам, укыйм, бигрәк тә ерак юлга чыкканда, үзем белән журналлар алырга тырышам. Һәрвакыт кызыклы материаллар табам. Журналның өлкәннәргә карата игътибарлы һәм ихтирамлы булуы бик ошый. Ел саен 8 март бәйрәменә әбиләрне матурлау-бизәүгә багышланган проектны яратам. Бик креатив һәм игелекле проект!

Аның сайттагы версиясе белән танышу, социаль челтәрләрдәге сәхифәләрен укып хушлану мөмкинлеге булса да, кулымда журналның кәгазьдә басылганын тотуны рәхәтрәк дип саныйм! Кәгазь битләрне актару, үзең өчен тамгалар ясау… Әнием әле һаман минем белән әңгәмәләр басылган газета-журналларны саклый. Үзем дә аларга тагын бер кат күз салырга, «элеккеге» фикерләремне укып искә төшерергә яратам. Сезгә зур уңышлар телим, ике йөз еллык юбилеегызны да үткәрергә насыйп булсын!

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
ТАТАРСТАН
TATARSTAN
ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ
WWW.PROTATARSTAN.RU
Реклама 16+

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2020 елның 1 февраленнән

2020 елның 2 нче яртыеллыгына «Татарстан» журналына алдан язылу игълан ителә

«Татарстан» журналына ТР буенча язылу индекслары:

П 2381 **татар телендә** 933 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 933 сум 00 тиен

Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ӘШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Туган якны **НИ ӨЧЕН** яраталар

Мөслим казын **НИЧЕК** әзерлиләр

Татарстанда иң бәхетле балалар **КАЙДА** үсә

Декабрь аенда «Татарстан» журналы protatarstan.ru сайтында «Татарстанның кайсы шәһәрендә яшәү рәхәтрәк?» дигән сораштыру уздырды. Үзләрендәге парклар, скверлар, мәктәпләр, ишегаллары, бассейннар, табигать өчен республикабызның барлык районнары халкы тавыш бирде. Иң активлар булып мөслимлеләр танылды. Икенче һәм өченче урыннарны Чистай белән Чирмешән районнары бүлеште. Без җиңү яулаган районнарның һәр өчесендә дә һичшиксез булачакбыз, әмма, беренче эш итеп, Мөслимгә юл тоттык. Сезне дә шунда чакырабыз.

1

Мөслим районы
(18%, 4328 тавыш)

2

Чистай районы
(17%, 3990 тавыш)

3

Чирмешән районы
(8%, 1997 тавыш)

МИН МӨСЛИМНЕ НИ ӨЧЕН ЯРАТАМ?



В каком районе Татарстана жить хорошо?

Муслюмовский район (18%, 4 328 голосов)

Чистопольский район (17%, 3 990 голосов)

Черемшанский район (8%, 1 997 голосов)

Сармановский район (7%, 1 708 голосов)

Казань (6%, 1 493 голосов)

Тукаевский район (6%, 1 383 голосов)

Мензелинский район (5%, 1 153 голосов)

Рыбно-Слободский район (4%, 1 040 голосов)

Аксубаевский район (3%, 750 голосов)

Лениногорский район (3%, 625 голосов)

Менделеевский район (2%, 442 голосов)

Альметьевский район (2%, 384 голосов)

Новошешминский район (1%, 328 голосов)

Алексеевский район (1%, 304 голосов)

САГЫНЫП, АШКЫНЫП КАЙТАМ

Әнисә Биктимерова:
– Яратканга күрәдер, монда яшәгән матур көннәрне һәм тыныч кичләрне бик якын күрәм. Карагыз әле, безнең район үзәге нинди ямьле – җәйләрен ул чәчәккә күмелеп утыра! Күп эшне үз кулларыбыз белән башкарабыз, шуңа күрә бу матурлыкны кадерли һәм саклый беләбез. Берәр кая барырга туры килгәндә, сагынып, ашкынып кайтам.





МӨСЛИМНӘН ДӘ ЯМЬЛЕ ҖИР ЮК!

Лариса Фәрдиева:
– Мөслимдә яшәү көннән-көн рәхәтрәк була бара. Тормыш шартлары күзгә күренеп яхшыра. Минә яшьләр өчен дә күңел ачу үзәкләре пәйда булса, тагын да шәбәячәк: кичләрен шунда барып, вакыт уздырыр, күңел ачарлар, шәһәргә китеп бармаслар иде. Дискотекалар булса, әйтик… Минем өчен җир йөзендә Мөслимнән дә ямьле җир юк!

КАЙСЫ ШӘҺӘР МӨСЛИМГӘ ТИҢЛӘШСЕН?!

Маргарита Микалина:
– Монда халык әйбәт, шул ошый. Эшем дә кызыклы – яр буйларын тәртиптә тоту белән шөгыльләнәм. Җәйләрен чәчәкләрне тәрбиялибез, газоннарны карыйбыз, көзен – яфрак, кышын кар чистартабыз. Ел әйләнәсе – саф һавада. Сез мондагы киңлекләрне генә күрегез, табигать искиткеч бит! Кайсы шәһәр Мөслимгә тиңләшсен?!

МОНДА БАР ДА ГАЗИЗ, БЕРНИГӘ АЛЫШТЫРМЫЙМ!

Рәзинә Сафиуллина:
– Җавап гади: бу – минем туган төбәгем, шуңа яратам. Монда бар да газиз, бу җирләрне бернигә алыштырмыйм. Балалар да туган җирендә калды, аларга да Мөслимдә ошый…

УРАМНАР ЧИСТА, ТАБИГАТЬ ГАҖӘЕП, КЕШЕЛӘР МӘРХӘМӘТЛЕ...

Ләйсән Исламова:
– Урамнар чиста, якты, табигать гаҗәеп, кешеләр мәрхәмәтле. Балалар бакчалары һәм мәктәпләр шәп, мәдәни объектлар белән инфраструктура да – югары дәрәҗәдә. Кешегә уңайлы тормыш корып яшәр өчен, тагын нәрсә кирәк, йә? Монда бөтенесе дә бар! Мин, мәсәлән, шәһәргә китеп бара ала идем, әмма үз теләгем белән биредә калдым. Мөслимдә тормыш ямьлерәк тә, тынычрак та.

КҮЗГӘ КҮРЕНЕП ҮСӘ, ЧӘЧӘК АТА

Халисә Мусина:
– Күзгә күренеп үсә һәм чәчәк ата Мөслимебез! Соңгы еллар эчендә танымаслык булып үзгәрде. Урамнар чәчәккә күмелеп утыра, кибетләр – адым саен, аларда бөтен нәрсә дә бар. Яшә һәм куан гына! Пенсияне дә бераз арттырсалар…

БЕЗДӘ ЧИСТА, ТЫНЫЧ, УҢАЙЛЫ, ЫГЫ-ЗЫГЫ ЮК

Эльмира Шабаева:
– Мин Мөслимдә тудым, укыдым һәм үстем. Ничек инде аны яратмыйм, ди? Бездә чиста, тыныч, уңайлы, артык ыгы-зыгы юк, ә мин нәкъ шушындый тормышны үз итәм.



– Без, мөслимлеләр, килгән кунакларга һәрвакыт шат, – дип каршылады безне **Мөслим муниципаль районы Үзәк китапханәсе мөдире Айсылу Мадъярова.** Ә кунаклар китапханәдә еш һәм күп була икән, бигрәк тә күрше районнардан коллегалар килергә ярата. Экскурсиягә килгән сыман йөриләр икән. Киләләр, карыйлар, аннан авыр сулыйлар… Суларлык та шул, мөслимлеләр бәхетенә тәтегән китапханә башка районнарда еш очрамый. Якты, иркен, бөтен кирәкле җиһаз да бар. Аның фондында 58 меңнән артык китап саклана.

Иртәдән үк китапханәгә өлкән яшьтәгеләр, пенсионерлар килә икән, ә инде төштән соң яшүсмерләр, балалар җыела башлый. Кичләрен, бала-чагасын җитәкләп, әти-әниләр килә. Кызыксынулары төрле булган берәү дә үзенә шөгыль тапмый калмыйдыр биредә, мөгаен. Шахмат, мавыктыргыч уеннар, буягычлар, Интернетка тоташкан компьютерлар, кафе… – барысы да бар. Әйе, әйе, китапханә эчендә – кафе, мондыйны шәһәр җирендә дә очратып булмый әле. Бирдә чәй, кофе эчеп, сөйләшеп утырырга мөмкин. Ә аннан, җаныңа һуш килгән китапны алып, берәр почмакка урнашып, укуга чумарга. Бүгенге тизлек һәм Интернет заманында онытылып барган әлеге шөгыльне мөслимлеләр яңадан кайтарып килә икән. Киресенчә, балалар әти-әниләрен алып килгән очраклар ешая бара, дип сөйләделәр безгә.



– Лицейның төп эш принцибы – укучыларны тәрбияләү, аларның үзаңын формалаштыру. Яхшы белем биреп, ул белемне киләчәктә тагын да арттыруга йөз тотардай чын шәхесләр үстереп, аларны олы тормышка аяк басарга әзерләү, – дип сөйләде безгә **«Мөслим лицее» муниципаль гомуми белем бирү бюджет учреждениесе директоры Лилия Хәбибуллина.** – Районда моның өчен балалар бакчалары белән мәктәпләр арасында дәвамчанлыкны күз уңында тоткан программа эшләнде. Һәр мәктәпнең шефлыкка алган бакчасы бар. Без аларга йөрибез, алар – безнең дәресләргә. Мондый аралашу һәр ике як өчен дә файдалы.

Лицей Россиянең иң яхшы 100 мәктәбе исемлегенә кергән, республиканың «Матур мәктәп – 2019» бәйгесендә җиңү яулаган. Ә Лилия Ягдиевна үзе «Иң яхшы мәктәп директоры» грантына дәгъва кылган республика бәйгесенең лауреаты булган.

Спорт, физика, математика, астрономия, химия, цифралы мәгълүматлар – лицей укучыларына ирек һәм сайлап алу мөмкинлеге бирелгән. Киләчәктә алар үзләрен кайсы өлкәдә күрә – үсмерләр үзләре хәл итә. Ә өлкәннәр моның өчен менә дигән уку-укыту базасы булдыра алган, Мөслим лицеенда балалар тулыканлы үсеш алсын өчен барысын да эшләгән.



«Татарстан» журналы өчен МАХСУС

МӨСЛИМ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫННАН **КАБАТЛАНМАС МӨСЛИМ КАЗЫ**

Сезнең кайчан да булса Мөслим казын авыз иткәнегез бармы? Алма һәм караҗимеш тутырылганын? Мондый казны Яңа ел бәйрәменә дә, иске Яңа елга да, күркәм гаилә мәҗлесләренә дә әзерләргә була. Мөслимдә шулай! Чөнки район каз үрчетү буенча алдынгы урыннарда бара – аны биредә борын-борыннан үз итәләр, кайчандыр бу затлы кошны өйләргә кертеп, ай буе сәке астындагы ояда утыртып, бәбкә чыгартканнар. Шунлыктан инде сез Мөслимгә килеп эләккәнсез икән, әзер булыгыз! Каздан авыз итми калмаячаксыз!

Автор:
Татьяна Вафина

– Хатын-кыз гаиләне туендыру өчен ашарга пешерә, ир-ат исә ризык әзерләүдән ләззәт ала, шунлыктан барысы да бик матур булырга тиеш, – ди Мөслим районы башлыгы Рамил Муллин. Һәм, «Татарстан» журналының крахмалланган алъяпкычын ябып, күз ачып йомганчы, гап-гади казны... эченә алма һәм кара җимеш тутырылган Мөслим казына әйләндерә.

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- Мөслим казы – 1 данә;
- алма – 6 данә;
- кара җимеш – 300 г;
- тәменчә тоз;
- аджика – 1 кечкенә банка.

Фото: Александр Ефремов

Журнал
ТАТАРСТАН
Редакционная Кухня
Обращение
к народам всего мира

Элекке заманнарда казлар да, бик кадерле булып, кешеләр белән бергә өйдә яшәгән – бәбкә чыгарганда, алар сәке астындагы ояларында кукыраеп утырган. Хәзер исә мондый күренешне Мөслим музеенда гына күреп була.

КОЯШЛЫ МАНЗАРА

Аннары каз өч сәгатькә газ мичендә кереп китә. Аның пешкәнен көтә-көтә Мөслим тәм-томнары белән чәй эчәбез һәм кышкы Мөслим яр буеның җәйге якты исемне йөрткән «Кояшлы Ык» манзарасы белән хозурланабыз.

– Тәрәзәдән гүзәл манзара ачылсын өчен, мин башта яр буен матурлап төзеттем, аннары инде яр буе күренешләре белән хозурланырга дип йорт салырга туры килде, – дип шаяртта район башлыгы. – Әмма мин генә яр буена сокланып калмыйм, Ык буенда йөргән мөслимлеләр дә мине бик яхшы күрә – койма тәбәнәк бит, ничек яшәгәнем, ни эшләгәнем – уч төбендәге кебек. Менә әле хәзер дә, урамда суык булмаса, безнең каз пешергәнне карый-карый сәйран кылып йөрерләр иде.

– Журналдан карарлар, – дип тынычландырабыз аны һәм кухня буйлап... экскурсияне башлыйбыз.

ИҢ ШӘХСИ МУЗЕЙ

Заманчалык һәм музейлык шундый килештереп бербөтенне тәшкил иткән мондый аш бүлмәләрен еш очратып булмый. Шунлыктан аны безнең «Татарстанның 100 музее» проектына «Иң шәхси музей» буларак курыкмыйча терки алабыз. Рамил Хәмзә улы борынгы матур әйберләр белән күптәннән мавыга икән. Барлык сәяхәтләреннән дә үзенең аш бүлмәсенә нинди дә булса яңа раритет алып кайтырга тырыша ул. Искиткеч матур итеп ялтыратылган самоварлар тупланмасы аш бүлмәсенең сул почмагында балкып утыра...

«Капкорсаклы» экспонатлар белән хозурланган арада сәгать сугуы игътибарны җәлеп итә. Аңа икенчесе, өченчесе кушыла... Рамил Хәмзә улы, укларны бер саннан икенчесенә күчереп, безгә барлык сәгатьләрнең сугуын да тыңлатып чыга.

– Матурмы? – дип сорый аннары, бездән мактау көтеп, коллекционер.

– Бик матур! – дип, соклануын белдерә «татарстан»лылар.

– Хәзер тагын да матуррак булачак, – дип кызыктыра безне Рамил Хәмзә улы һәм... патефон кабыза. – Мин сезгә «Дунай дулкыннары» вальсын тыңлатам...

Шыгырдый-шыгырдый, иске винил мөслимлеләрне һәм район кунакларын Дунайның ярсулы дулкыннарына чумдыра... Ә бәлки менә янәшәдә генә, тәрәзә төбендә, гыйнвар бозы астында агып яткан Ык дулкыннарынадыр. Икесе дә бик күркәм...

– Соңгы вакытта сезнең район күзгә күренеп үзгәрде. Башкаларны ничек куып тотып, узып та китәргә өлгердегез?

– Мин төрле рейтингларга бөтенләй каршы. Хәтта күрше районнарны да чагыштырырга һич ярамый, чөнки без – гаять төрле. Һәр районның үз шартлары һәм үзләренә генә хас булган өстенлекләре бар. Мөслим – кечкенә район. Без нинди дә колач җитмәс зур эшләргә тотына алмыйбыз, әмма без нинди дә булса уникаль нәрсәләр белән шаккатыра алабыз. Бу бары тик бездә генә бар, Мөслимдә генә эшләнә ягъни.

MADE IN MUSLUMOVO

– Әйтик, нәрсәләр инде ул?

– Мәсәлән, Рязаньда Россиядә бердәнбер булган «Форт» биофармацевтика компаниясе бар, ул иммунопрепарат – балалар өчен грипкка каршы вакцина җитештерә. Менә шуның өчен эмбрионнарның (бу – чимал) 50 процентын алар Белоруссиядән, 50 процентын исә Мөслимнән ала. Димәк, вакцина җитештерер өчен кирәкле чимал белән без ярты Россияне тәэмин итәбез! Казлар, кошчылык, «Агромастер» – «Менә бу – Мөслим!» дип әйтү мөмкинлеге бирә торган проектлар. Мәдәният, мәгариф, сәламәтлек саклау тармаклары да безгә үзебезне таныту мөмкинлеге бирә. Шунлыктан без һәрвакыт иң яхшы булырга тырышабыз. Кешеләр үзләренең иң яхшы булуын, иң шәп урында яшәвен аңлый башлагач кына, туган җирләре белән горурланачак. Менә сез бездәге ишегалларының нинди икәнен күрдегезме?

– Моны күрми мөмкин түгел. Башка беркайда да мондый шәп ишегалларын күргәнебез юк иде. «Безнең ишегалды» программасы сездә эшли башладымы әллә ул?

ЧҮП-ЧАР РЕФОРМАСЫ

– Бездә биш ел элек чүп-чар реформасы эшли башлады. 350 чүплекне бетердек! Ике полигон гына калдырдык. Һәр алты ишегалдыннан 3,5 меңәр КАМАЗ чүп түктек! Узган гасырның 80 нче елларында кешеләрнең сарайлары булып, анда терлек асраганнар... Әмма ул заман үтте, сыерлар бетте, ә менә абзар һәм тирес калган иде. Пычрак та, шыксыз да, тик чыгарып ташлавы кызганыч кебек. Һәм без әйттек: бер ишегалдын бирегез дә, без аны тәртипкә китерербез, сез, нәтиҗәсен күргәч, үзегез хәл итәрсез. Ясап күрсәттек. Шуннан соң бөтен кеше үз ишегалдын чистартырга ризалашты. Болай килештек: без бульдозер белән абзарларны ишәбез, юлларны, йортларга килү сукмакларын, парковкалар, скверларны ясыйбыз, сез исә барыгыз да безгә булышасыз – агачлар утыртырга, мәсәлән. Ризамы шуңа? Ризалаштылар. Хәтта машинаны йорт янында калдырмау белән дә килештеләр. Кеше, өеннән чыккач, машина түгел, бәлки иркенлек, гүзәллек, чисталык күрергә тиеш! Бу күңелдә рәхәтлек хисе тудыра.

Моннан ике ел элек безне кешеләрне агач юдырталар, дип, гаепләгән һәм ачуланган иделәр. Пычракка баткан агач кәүсәсен юган һәм, шуның белән горурланып, фотосын социаль челтәргә элгән

укытучы безнең янга елап килде. Ялганлап, янәсе, хакимият мәҗбүр итә, дип хәбәр тараттылар. Мин бу укытучыга рәхмәт кенә әйттем. Язсыннар, әйдә! Немецлар инде йөз ел буе шулай эшли – чиста булсын өчен, хәтта асфальтны да шампунь белән юа. Ни өчен әле бездә дә шулай булмаска тиеш?

ЧИСТАЛЫК ҺӘМ МАТУРЛЫК – ӘНИДӘН

– Чисталыкка шундый таләпчәнлек белемегез буенча санитар табибы булуыгыз белән бәйлеме?

– Юк, әнидән күчкәндер ул. Безнең өебез гел ялт иткән иде. Тагын әнием матурлыкны бик ярата иде. Әтием – машина йөртүче, ике көнгә командировкага китә, әни исә шул вакыт эчендә өйдәге җиһазларны тулысынча күчереп куя. Без булыша идек – диванны, сервантны икенче урынга күчерәбез, мәсәлән. Ул өйне гел яңартып торгандай була иде һәм безне дә шуңа өйрәтте. Ризыкларны да матур итеп бизәде һәрчак. Шапшак һәм ямьсез җирдә миңа бик уңайсыз. Минем өемме ул, күпфатирлы йорт подъездымы, урамны – анысы мөһим түгел... Менә быел кар аз һәм Мөслим пычрак тоела, кар ак булмагач, ямь юк...

– Карны да юыгыз соң!

– Кул кычыта инде юарга, – дип көлә Рамил Хәмзә улы. – Без юлларга ком түгел, реагентлар сибәбез – бу кыйбаткарак төшә, әмма чистарак та. Мөслимдә 40 чакрым тротуар бар. Әмма иртәнге сәгать алтыга кадәр бөтен тротуарлар, бөтен юллар чистартылган булырга тиеш. МУП командасы эшли (60 берәмлек техника). Чистарталар да, яшелләндерәләр дә. Безнең барлык балалар да МУП аша үтә – өлкән сыйныфларда алар яшелләндерүдә эшли. 5 тән 10 мең сумга кадәр акча алалар, ярты шар көн эшлиләр – агач һәм чәчәк утырталар, аларны карыйлар, себерке дә, китмән дә тота беләләр. Бездә вандаллык юк, чөнки бөтен нәрсә үз кулыбыз белән утыртыла.

Менә хастаханәне ремонтладык. Моңа республиканың 200 миллион сум акчасы тотылды, җиһазлар сатып алуга 50 миллион сумны исә иганәчеләрдән таптык. Башка беркайда дә мондый җиһазлар юк! Кечкенә генә Мөслимдә – һәркайсы 5–6 миллион сумлык, эксперт класслы УЗИ аппараты, ФГДС аппараты, 16 миллион сумлык санлы рентген җайланмасы. Тагын әле физиоҗиһазлар да бар – стационар һәм поликлиника системасы тулысынча көйләнгән. Миңа шундый эшләр эшләү, иганәчеләр табу ошый. Аллаһы Тәгалә җанга якын проектларга акча да, көч тә бирә.

ИГАНӘЧЕЛЕК ЯРДӘМЕ БУЛАРАК – ҮЗАРА САЛЫМ

– Тагын бер искиткеч нәрсә – үзара салым бар бит. Күп кенә районнар моннардан актив файдалана.

– Мин үзара салымны да күпмедер дәрәҗәдә халыкның иганәчелек ярдәме, дип саныйм. Без бу проектны республикада беренчеләрдән булып башладык. Башта мине бик нык ачуландылар: «Син нигә халыкны талыйсың?» – дигән сүзләрне дә ишеттем. Мин исә: «Егетләр, юллы буласыбыз килсә, һәрберебездән берәр мең акча җыярга кирәк, шуларның һәркайсына тагын дүртәр мең өстәләчәк бит. Булдыра алсагыз, булышыгыз!» – дидем. Халык хуплады һәм үзе биргән бер мең акчасы өчен нәтиҗәне күреп сөенде: юл бит салынды. Хәзер без иң ерак урыннарда да юлларны ясадык инде, һәр ишегалдына барып җиттек. Әйе, хаталар да булды. Әмма без тәҗрибә тупладык, халык боларның барысы да аларның көнкүрешләрен яхшырту максатыннан эшләнүен аңлады.

Былтыр бер авылда юл ачканда, бик аз кеше килде. Мин гаҗәпкә калдым: нигә килмәгәннәр? Һәм миңа бер әби: «Улым, безнең синә башка бер гозеребез дә калмады!» – диде.

БЕЗ НИ ӨЧЕН ЯШИБЕЗ...

Кеше берьялгызы гына бәхетле була алмый. Шунлыктан җәмгыятьнең үсүе мөһим. Җәмгыять баеган саен, һәркемнең тормышы уңайлана бара. Кешенең башкалар белән бүлешәсе, ярдәмләшәсе килә. Авылларда без социаль проектларны тормышка ашырабыз – күп балалы гаиләләргә берничә йорт сатып алдык, инвалидларга, ялгызларга ярдәм итәргә тырышабыз. Менә бу социаль максат кешене үзгәртә. Аның башка фикерләре, башка идеяләре туа башлый... Ул инде бөтен бәхетсезлектә дәүләтне гаепләми, ә уйлана: процесста аның үзенең роле нинди соң? Мәсәлән, Шуган һәм Шуран авылларында кайчандыр Ык елгасы аша күперләр булган. Алар җимерелгән. Ремонтларга кирәк. «Әйдәгез мин үземнең командам, техникам белән киләм, ә сез, бер 100 кеше тупланып килегез дә, совет чорындагы кебек бергәләп өмә оештырыйк...» – дидем. Җыелабыз икән – төзибез, юк икән – төземибез. Булмады, күперне ремонтламадык. Бер яктан, нәрсәдер эшләргә кирәк, ә икенче яктан, кем эшләргә тиеш соң моны?

ПРОЦЕССТА КАТНАШУЧЫЛАР

Әгәр халыкка аңлатмыйсың икән, ул кайдандыр кемнеңдер килүен һәм эшләп бирүен көтәчәк, һәм нәтиҗәдән канәгатьсезләр дә һәрвакыт булачак. Ә менә инде алар үзләре процесста катнаша икән, бөтенләй башка мөнәсәбәт. Менә яр буе – аны мөслимлеләр төзеде. Авыллардан килделәр. Хәтта пенсионерлар, йога яратучылар җәмгыяте дә килеп, үзләренә эш бирүне үтенде. «Арыдыгызмы?» – дип сорыйм. «Юк! Ә киләсе елга нәрсә эшлибез?» – дип, үзләре миннән җавап көтә.

Без республикада иң озын яр буен ясап куйдык. Әмма эш озынлыкта да, анда нәрсәләр урнашуда да түгел. Эш безнең моны барыбыз бергә эшләп куюыбызда. Чөнки без бергә яшибез.

1. Турыйбыз!

2. Тутырабыз!

3. Болгатабыз!

4. Сылыйбыз!

5. Куябыз!

6. Пешерәбез!

7. Алабыз!

8. Бизибез!

Канәгатьсезләр һәрвакыт бар – алар аз, әмма бик актив һәм «җәмгыять вәкилләре». Аларга көчне сарыф итәргә кирәк түгел – дөньяны үзгәртергә теләүчеләргә таяну зарур, һәм шул чакта ул чынлап та үзгәрәчәк. Сукранучыларга нәрсәнедер аңлату файдасыз. Аларның бурычы – булдыру түгел, тәнкыйтьләү генә бит. Аларны Аллаһы Тәгалә шундый итеп яраткан, баланс өчен андыйлар да кирәк.

НОРМАЛЬ ГЕРОЙЛАР

Шуңа күрә безнең өчен һәркем кадерле. Инфраструктураны булдыру мөһим – ул кешеләрне үзенә җәлеп итәчәк. Әгәр без шартлар тудырмыйбыз икән, алар китәчәк. Практика шуны күрсәтә: кешеләр китә дә, буш, үле шәһәрләр кала. Авыллар турында әйтеп торасы да юк. Мин шуны аңладым: тарихы булмаган, совет чорында ясалма оештырылган авыллар юкка чыга. Мәсәлән, Карл Либкнехт исемендәге авылда бер кеше яши. Бернишли дә алмыйсың! Миңа, район башлыгы буларак, безнең юкка чыкмавыбызны кайгырту мөһим. Миңа үз гомеремдә ташландык йортларны күрергә язмасын иде. Шунлыктан уңайлы шартлар тудыру зарур. Бирегә туарга, аннары белем алырга һәм кабат туган җиренә әйләнеп кайтырга, уңышка ирешергә – мин менә моны каһарманлык дип саныйм. Районнан читтә дә зур уңышларга ирешкән якташларыбыз шактый күп, алар белән дә горурланам. Алар Мөслимне данлый, таныта. Бирегә әйләнеп кайткан геройлар да бар, мәсәлән, Илгиз Исламов, ул – безнең мактаулы гражданин. Мөслимдә яши, бирегә туган, әйләнеше миллиард сумнан арткан «Агромастер» предприятиесен төзегән кеше. Анда 300 кеше эшли, уртача хезмәт хакы 40-70 мең сумны тәшкил итә. Мондый кешене ничек хөрмәт итмисең ди инде?! Шунлыктан мин алардан – үз каһарманнарыбыздан – уңышка илтү тарихларын балаларга батырлык дәресләрендә сөйләүләрен үтенәм. Бу матур һәм бәхетле урында яшәп, күп нәрсәгә ирешеп булганны сабыйларның балалар бакчасыннан ук аңлап үсүе бик мөһим.

– Шунлыктан сезнең балалар бакчаларыгыз – бәхетле, мәктәпләрегез матурмы?

– Мин шулай дип уйлыйм. Бу – туган җиребез бәхете хакына уртак тырышлык, уртак хезмәт нәтиҗәсе. Шәһәрдә нәрсә бар? Бернәрсәгә дә вакыт җитми. Биредә исә вакыт дигән байлык бар. Сәламәтлек һәм вакыт – безгә Аллаһы Тәгалә бүләге. Биредә без тынлыкны ишетәбез, вакытны ишетәбез – менә шул бәхет тә инде.

УКУ, КҮРҮ, ИШЕТҮ, ТОЮ

– Мөслим китапханәсенә кердек. Шундый уңайлы, рәхәт – телефон һәм Интернет турында онытып, укып утырасы гына килә. Сез, мөгаен, укырга яратасыздыр?

– Китап уку ул – җан рәхәте. Мин дини китапларны да, матур әдәбиятны да укыйм. Менә әле күптән түгел Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романын кабат укып чыктым һәм бер хыял пәйда булды... Әбүзәр Гәрәевич портретын безнең докторларга кычкырып укыйсым килә – табиб һөнәренең акча эшләү мөмкинлеге түгел, бәлки табигый сәләт, күңел халәте икәнен алар да аңласын иде. Моны аңламыйсың икән, син беркайчан да бәхетле булмаячаксың. Һаман кая да булса йөгерәчәксең... Без бит чабыш атлары түгел. Без күрә, ишетә, тоя алабыз.

– Ә сезнең күрергә, ишетергә, тоярга вакытыгыз каламы соң? Һәм гомумән, шәхсән үзегез өчен вакытыгыз каламы?

– Кала. Иртәнге намаздан соң бассейнга барам. Эштә хезмәткәрләремне дә тулы көчләренә эшләтергә тырышам, алар да үсеннәр, дип, кайбер вәкаләтләрне тапшырам. Минем киңәшчеләрем, дусларым күп, алар ярдәм итә, киңәш бирә. Мин аларның һәркайсына рәхмәтле.

Вакытны бушка үткәрергә яратмыйм. Бик каты арыган булсам да, китап укыйм. Безнең фани тормышыбыз бик кыска бит. Шуңа күрә аны мөмкин кадәр дөрес һәм нәтиҗәле итеп файдаланырга кирәк. Мин 5-6 сәгать йоклыйм. Кышын чаңгы шуам, җәен уйлана-уйлана сәйран кылып йөрүдән һушланам... Урманны, табигатьне, утны, суны яратам. Төзү эшләрен. Балаларымны, гаиләмне, әти-әниемне. Әнием минем өчен аккумулятор батарейкасы кебек. Ул миңа көч-куәт бирә. Йомшак күңеллелек, ярата белү – әниемнәндер, әтиемнән исә хезмәт сөючәнлек сәләте күчкән. Аңа быел 70 яшь тулачак, ул әле һаман бер урында тыныч кына утырып тора белми. Бер ир туганым – биредә, сеңлем – Казанда. Бер балам Казанда укый, калганнары әле үзебезнең янда.

МИЛЛИ ИДЕЯ КИРӘК

– Өйдә иминлек булса, эш тә җай барамы?

– Проблемалар бар. Авылларда вазгыять катлаулы. Халык картая, яшьләр китә. Статистика шуны күрсәтә: 150 кеше туа, 300 кеше үлә, гәрчә без озын гомерлеләр саны буенча беренче дистәгә керәбез. Хатын-кызлар уртача 83 яшькә кадәр яши. Әмма ир-атлар иртә үлә. Без аларга тормышның хәмерсез дә бик матур икәнен берничек тә аңлата алмыйбыз. Үткән елларда гына да шул сәбәпле биш кешене югалттык. Сәбәбе 90 нчы елларга барып тоташа. Эшсезлек, акчасызлык кешеләрне эчтән какшатты, халык эчкечелеккә сабышты. Хәзер шул заманның нәтиҗәләрен күрәбез – бу инде чиргә әйләнде.

– Котылу юлы бармы соң?

– Милли идея кирәк. Миңа финнар ошады – алар үз алларына 30 ел эчендә сәламәт милләт тәрбияләү максатын куйганнар. Моңа кадәр финнарның 60 проценты тәмәке тартса, хәзер ирләрнең 13%ы, хатын-кызларның 23%ы гына тарта. Чөнки алар башта тарта торган хатын-кызларга игътибар бирмәгән, ир-атларны сәламәтләндерү белән генә шөгыльләнгән. Хәтеремдә, кардиоүзәктә аның 75 яшьләрдәге җитәкчесе белән сөйләшкән идек. Ул: «Спортзалда үткәрергә тиешле 326 сәгать вакытымны инде күптән үтәдем», – диде. Спорт заллары – финнар өчен норма, алар тәүлек буе эшли.

Без дә спортка өстенлек бирәбез. Мөслимлеләр скандинавия йөреше белән шөгыльләнә, чаңгы шуа, велосипедта җилдерә – боларны мин көн саен яр буенда күреп торам.

Киләчәктә хезмәт күрсәтүне яхшыртачакбыз: халыкны тәмле ашатачакбыз, тәмле кучтәнәч бирәчәкбез. Кечкенә кафелар төзергә кирәк. Бездә әле туристлык индустриясе тиешенчә үстерелмәгән, чөнки без кешегә матур итеп хезмәт күрсәтә белмибез. Мөслим тирәсендәге шәһәрләрдә миллионга якын кеше яши, һәм алар барысы да безгә ял итәргә килә ала, без кабул итәчәкбез – нормаль шартларда, матур урында. Килгән кеше тәмле итеп сыйлансын, мөслимдәгечә генә каклана торган казны кучтәнәчкә алып китсен һәм үзен биредә ничек шәп каршылаулары турында башкаларга да сөйләсен иде. Биредә бит – искиткеч табигать. Шәһәрдә – ыгы-зыгы, боларның берсе дә юк.

Шуңлыктан күңел авылга тартыла да, безгә авыл җирлеген саклап калырга кирәк. Әмма милли программа булмагач, әлегә авылларны саклау буенча зур бурычлар куелмый. Авылларны саклап калу буенча иллюзияләрем юк. Россия бик зур. Минемчә, районнар арасында зур булмаган сәнәгать мәйданчыклары булуы кулай. Кеше 20-30 минутта барып җитсен, эшләсен һәм кире өенә кайтсын. Бу шәһәрләрне бушатыр, авылларга җан өрер иде.

АШ-СУГА КАГЫЛМАГАН КИҢӘШЛӘР

– Нәтиҗә ясыйк: гадәти районны ничек алдынгыга әйләндерергә? Акчаны кайдан алырга? Моңа ирешкән район башлыгыннан берничә киңәш.

– Акча һәрвакыт бар ул, аны дөрес файдалану мөһим. Мөмкин булмаганны эшләп булмый. Хәзер иң мөһим урын кайда – акча шунда җибәрелергә тиеш.

Без мәктәп һәм хастаханәләрдән башладык. Мәктәпләрне ремонтлау программасы кысаларында «бездән китсен – иясенә җитсен» кенә дип түгел, матур итеп ремонт ясауга күчтек. Укытучы һәм балаларның күзе яна башлады, сәламәт ярыш рухы пәйда булды.

Хәзер медицинада – кадрлар кытлыгы, бездә исә поликлиникада штат 97%ка, ә стационарда 99%ка тулы. Чөнки без хастаханәне ремонтлап кына калмадык, тулы бер чаралар комплексы эшләдек: студентлар белән очрашу, үз абитуриентларыбызны әзерләп, аларның биредә кайтуын тәэмин итү. «Земский доктор» программасы буенча биш елга гына кайтсалар да яхшы, чөнки 70 процент чамасы барыбер бөтенләйгә калачак. Кеше үзенә уңайлы, рәхәт булган җирдә яши.

Җаваплылыкны үз кулыңа алу мөһим. Мәсәлән, моннан ике ел элек безгә «Август» компаниясеннән делегация килде. Алар Татарстанда үзләренең заманча авыл хуҗалыгын үстерү буенча яхшы инвестицион программаларын гамәлгә кертеп булырлык мәйданчык эзли иде. Мин аларны дүрт сәгать буе Мөслим буйлап йөрттем. Парклар, мәктәпләр, китапханә, балалар бакчалары – аларга бөтен социаль структураны күрсәттем. Аннары: «Александр Михайлович, төшке аштан соң кырларны һәм фермаларны карарга барачакбыз», – дидем. Ә ул: «Юк! Җитте! – ди һәм үз хезмәткәрләренә борылып: – әгәр район үзәге шундый икән, безнең бурыч – авыл хуҗалыгын да алардан калышмаслык дәрәҗәгә җиткерү!» Һәм шул ел ярым эчендә алар 2 миллиард сум акча кертте! Кечкенә генә Мөслимгә – ике миллиард сум! Һәм, минемчә, без хәзер игенчелек тармагында иң алдынгыдыр. Без элек 80 мең тонна ашлык алсак, хәзер 150 мең тоннага якын ашлык җыябыз. Ике тапкыр күбрәк!

Барысын да этаплап эшләргә кирәк. Әйе, терлекчелек буенча проблемалар бар. Әмма бүген «Август» компаниясе яңа мегакомплекс төзелешен башлады һәм 1 миллиард 200 миллион сум акча кертә. Бу безнең өчен акылга сыймаслык саннар. Алар ни өчен безгә акча кертә? Чөнки аларга безнең уңайлы мохит ошый. Без төзекләндерүдән макроэффект алдык.

Россиядә авыл хуҗалыгы техникасы җитештерү буенча «Ростсельмаш»тан соң бишенче булган «Агромастер» компаниясе бүген «Татарстан» сериясеннән Т-360 тракторлары проектына алынырга ниятли. Аларның конструкторлары – бөтен конструкторлар арасында элита. Конструктор үзенә уңайсыз булган җирдә яши алмый. Шуңлыктан биредә яшәячәк.

– Сез ничек уйлыйсыз, мөслимлеләр сездән уңдымы?

– Мин мөслимлеләрдән уңдым. Бу – минем ватаным. Аларның мине ишетүләре – зур бәхет. Аларның миңа ышанулары – зур бәхет. Халыкның минем арттан иярүенә дә бәхетле мин. Монда туууым һәм биредә файда китерә алуым белән бәхетле.

Быел без Бөтенроссия авыл сабан туен үткәрәчәкбез. Бер федераль җыен – Мәскәүдә, икенчесе – Мөслимдә. Мин моның зур җаваплылык икәнен аңлыйм. Һәм безгә уңайлыклары булган авыл көнкүрешенең нинди булуын күрсәтә алу бик кадерле. Без үзгәрәбез, үсәбез. Мөслимнең шигаре: «Традицияләрне саклап, без иң яхшы, заманча бурычларны тормышка ашырабыз». Хак сүзләр, без трендта булырга тиеш.

БӘХЕТЛЕ БАЛАЧАК БАКЧАСЫ

Авызлар колакка кадәр ерылган, күзләр янып тора! Нидән дисезме? Нибары кар яуганга куанудан... – менә ул чып-чын һәм бәхетле балачак. Без аның белән Мөслимнең «Кояшкай» балалар бакчасында очраштык.

ӨЙГӘ – ТУҢДЫРМАГА АЛДАНЫП КЫНА...

– Дүшәмбе – минем иң-иң-иң яраткан көнем, – ди Софья исемле кечкенә кыз, карны әвәли-әвәли. Аңа алты яшьләр чамасы. – Чөнки дүшәмбе – бакчага. Миңа монда би-и-и-ик ошый! Йокларрррга мөмкин, ашарррга, уйнарррга. Тәррбиячеләр бик яхшы, аларрр безне укырррга һәм язарррга өйрәтә. Мин хәтта «р» хәрефен дә әйтергә өйрәндем бакчада. – Чынлап та, Софья «р» хәрефе кергән сүзләрдә аңа аерым басым ясый, без моны шунда ук абайлап алдык. – Кыскасы, мин бакчаны бик ярррратам!

– Мин дә! Мин дә! – дип, аның сүзләрен дәррәү күтәреп ала «Кояшкай»га йөрүче башка балалар.

Ә бит күркәм корылмалар, таганнар, таулар, сыннар белән бизәлгән балалар мәйданчыгына күз йөртеп чыкканнан соң, үзеңдә дә шул ымсынуны тоеп аласың. Мин дә баш тартмас идем мондый дүшәмбеләрдән! Якты, җете төсләр балкый, ямьле, иркен монда! Ә инде йөгереп, хәрәкәтләнеп арысаң, карда ятып аунарга була, верандада ял итәргә.

– Баштарак, капиталь ремонт тәмамланган гына көннәрдә, әти-әниләр балаларны бу мәйданчыктан алып китә алмыйлар иде, – дип көлә балалар бакчасы мөдире Миләүшә Солтанова. – Кемнедер өйгә туңдырма белән алдап-йолдап алып кайталар, кемнедер – кәнфит белән... Территориядә сез күргән барлык җайланмалар, уен верандалары, кече архитектура формалары моннан өч ел элек пәйда булды – ул чакта бакчага капиталь ремонт ясадылар. «Кояшкай» үзе әле совет чорында ук төзелгән бакча – 1977 елдан бирле эшли. 2016 елда без монда бакча ачылу бәйрәмен икенче тапкыр уздырдык: бер елга сузылган төзекләндерү эшләреннән соң яңа бинага сөенеп туя алмадык. Чөнки ул – искиткеч! Республика бюджетыннан бүлеп бирелгән 18,5 миллион сумга бөтен нәрсәгә дә капиталь ремонт ясалды – фасадка, түбәгә, су бирү системаларына, ягу системасына, канализациягә... Бер генә иске әйбер дә калмады бакчада. Хәтта урын-җир, җиһазлар да – өр-яңа. Без хәзер балалар белән бу яңа әйберләрне саклап тотарга тырышабыз. Алар башта нинди бакчага килеп, ремонттан соң ниндиенә эләгүләрен үзләре күрде бит – аңлатып тору да кирәкми. Сабыйлар алар бик игътибарлы!

УЙНЫЙ-УЙНЫЙ ӨЙРӘНӘБЕЗ...

– Кадерле Камил, сине туган көнең белән котлыйм, синең белән дуслыгыбызның озак елларга сузылуын телим, тагын бик күп тапкырлар бергәләп лего уйнасак иде, чөнки без синең белән конструкторны ничек җыярга икәнен беләбез, ә кызлар – белми, – дип, ояла-ояла, дустын туган көне белән тәбрикли бер малай. Күзләрен идәндә янган ясалма шәм утыннан алмыйча...

Әлеге шәм тирәли кечкенә урындыкларда төркемнең барлык балалары да тезелешеп утырган. Алар барысы да бүген туган көнен бәйрәм итүче Камилгә теләкләр тели. Күңелне нечкәртә торган күренеш.

Хәер, баксаң, бу күңел ачу чарасы гына түгел икән, ә тәрбия чарасы да.

– Әйе, без, өлкәннәр, балаларны бәхетле, шаян итеп күрергә телибез, яшьтәшләре белән аралаша белүләрен күрү дә – безнең өчен сөенеч, – ди Миләүшә Әзһәровна. – Әмма соңгысы – безнең алда торган иң мөһим һәм шактый четерекле эш, коммуникация ысулларын сабыйларга сеңдерми торып, аларны җәмгыятьтә яшәргә өйрәтү мөмкин түгел. Нәкъ менә шуның өчен без аларны көн дә балалар коллективында үзара аралашырга өйрәтәбез: дусларча мөнәсәбәтләр булдырырга, инициатива күрсәтергә. Бәхетебезгә тәтегән грантларның берсен – ул 50 меңне тәшкил итте – Санкт-Петербургтагы «Педагогический круг» технологиясен үзләштерү өчен файдаландык. Хәзер үзләштергән өр-яңа технологияне инде үзебездә көн дә кулланабыз. Моннан зуррак – олы түгәрәккә дә җыелабыз, анысы берәр эре бәйрәм вакытында оештырыла, әйтик, Космонавтика көнендә. Бу түгәрәкләр балаларны берберсенә якынаерга өйрәтә, үз төркемнәрендәге балалар белән генә түгел, ә балалар бакчасына йөргән башкалар белән дә аралашырга, дуслашырга. Шул рәвешле сабыйлар бакча җәмгыятендәге тормышта кайный. Карагыз әле, менә пиктограммалар. Балалар алар ярдәмендә көн режимын төзи. Кайчакта, һава шартлары урамга чыгарга әллә ни чакырып тормаганда,

Фото: Александр Ефремов

алар мөстәкыйль рәвештә берәр шөгыль сайлый. Үзләре теләгән шөгыльне...

БАЛАГА БӘХЕТ ӨЧЕН НИ КИРӘК?

Балалар бакчасын бизәгән төсләр, җете һәм ачык булуына карамастан, күзне камаштырмый. Артык кычкырып тора торган берни дә юк биредә, шулай ук – караңгы, күңелне төшерә торган төсләр дә. Бик уңайлы. Балаларны үстерер һәм тәрбияләр өчен бөтен нәрсә дә каралган. Әйтик, сабыйлар өчен эшләнгән махсус җиһазларның киштәләрендә уенчыклар аерым-аерым тора: «кызларныкы» – үз урынында, «малайларныкы» – үзенекендә. Китаплар, дәфтәрләр, өч йөзгә якын уен белән җиһазланган интерактив өстәл, интерактив такталар, музыка кораллары – алар да үз тәртибе белән тиешлечә урнашкан...

– Әйе, безнең бакчабыз бик матур һәм уңайлы, без аның белән горурланабыз. Әмма иң мөһиме бу түгел, – дип елмая «Кояшкай»ның мөдире. – Безнең балалар шат, бәхетле генә булып калмасын, ә биредә үссен, ныгысын да, дип телибез. Безнең команданың әти-әниләр алдында зур бурычы бар, ә иң беренче чиратта, балалар алдында. Без нәкъ менә бүген, шушында, булачак белемнәрнең, зирәклекнең, үзара аралашу мөмкинлекләре, мөнәсәбәтләрнең нигезе салынуын бик яхшы аңлыйбыз. Бу җәһәттән горурланырлыгыбыз да бар – «Кояшкай»дан мәктәп сукмагына аяк атлаган балалар укытучылар янына әзерлекле булып бара. Алар укый да, яза да, үз фикерләрен анык итеп җиткерә дә белә.

Балалар безне бәхетлерәк итә. Ә без аларны ничек бәхетле итә алабыз соң? Ешрак сөендереп, әлбәттә. Без нәкъ менә шуңа омтылабыз да, – ди Миләүшә Әзһәровна, елмаеп.

«Кояшкай» МБМББУ командасы үз эшчәнлегендә күпсанлы һәм төрле дәрәҗәдәге грант программаларын куллану буенча зур уңышларга ирешкән.

- 2011 елда мөслимлеләр Каюм Насыйри исемендәге премия лауреатлары була. 2014 елда, республиканың иң яхшы билингваль балалар бакчасы буларак, 1 миллион сумлык грантка лаек, дип табылалар.
- 2015 елда «Татарстан Республикасы белем бирү учреждениеләре арасында белем бирү процессын иң яхшы оештырганы өчен» дигән дәрәҗәле исемгә лаек дип табылалар, шуның өчен 500 мең сумлык грант алып, республикадагы иң яхшы балалар бакчасы арасыннан 20 алдынгы дистәгә эләгәләр.
- 2019 елда «Кояшкай» «Россиянең иң яхшы балалар бакчалары» бәйгесендә катнаша һәм 98 мең конкурсант арасында иң яхшылар меңлегенә эләгә. Шул ук елда үзенең авторлык программалары белән республиканың «Әхлакый патриотик белем бирү» бәйгесендә катнаша, 50 мең сум грант ота.

www.protatarstan.ru
Реклама 16+
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Подписка!
Поиск...
РУС | ТАТ
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
«Тәмле ашлар җырчысы»
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
20 января 2020
17 января 2020
16 января 2020
Эдуард Эверсман исемендәге зоология музее
"Мең тонна боз китте!"
Олы Әтнәдәге сәүдәгәр Даутов йорты

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Шандор-тауда **НӘРСӘЛӘР** яшеренгән

Иң таныш музейда **НӘРСӘЛӘР** турында белергә була

Тылда Җиңүне **НИЧЕК** якынайтканнар

Майна авылы **КАЙ** ягы белән аерылып тора

PRESSA

Яшәлгән һәр көн тарихка әйләнә. Ул фотосурәтләрдә, хатларда, әйберләрдә, җырларда, китапларда, мәктәп көндәлекләрендә, документларда кала... Соңрак, үткәннәрдәге әйберләргә карап, без кайчандыр, әле агачлар бик биек булган чакта, кичергән хисләрне, тәсләрне, авазларны искә төшерәбез... Татарстан Республикасы һәм аның адашы «Татарстан» журналының 100 ел яшәү дәверендә җөмһүриятебез халкында истәлекле әйберләр шактый тупланган. Гаилә тарихлары гаилә архивларында саклана, зур тарихны исә музейлар күз карасыдай саклый. Алар хәзер һаман саен күбрәк популярлаша һәм төрләнә, чөнки тамырларыбыз, бабаларыбыз, гореф-гадәтләребез белән кызыксыну сүнми, бәхеткә, арта бара. Республикабыз кебек үк 1920 елда туган «Татарстан» журналы үзенең 100 яшьлек юбилеена музейлар марафоны үткәрергә – җөмһүриятебезнең гадәти булмаган 100 музеенда булырга карар кылды. Бүген сезнең игътибарыгызга шундый берничә музейны тәкъдим итәбез.

ИҢ ТИРӘН.
ШӨГЕРДӘГЕ НЕФТЬ МУЗЕЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

ИҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ.
ЗӨЯДӘГЕ АГАЧ АРХЕОЛОГИЯСЕ МУЗЕЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

ИҢ ФӘННИ.
АКАДЕМИК АРБУЗОВЛАР МУЗЕЙ-ЙОРТЫ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА



ИҢ ТАНЫШ.
БАКЫЙ УРМАНЧЕ МУЗЕЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

100 ТАТАРСТАННЫҢ МУЗЕЕ

«Татарстан» журналы версиясе буенча

ИҢ ТИРӘН.
ШӨГЕРДӘГЕ НЕФТЬ МУЗЕЕ

Биек тауның итәгендә – тупас таштан салынган, тышкы яктан борынгы ныгытманы хәтерләткән бина... Шандор-тауның тирән ятмаларында нинди серләр саклана? Беренче битум заводына нигез салучы кем булган? Авантюрист, оптимист, әллә талантлы эшмәкәрме? Һәм, ниһаять, һавада нинди сәер ис бар? Бу сорауларга җавапны «Татарстан» монда, музейда, тапты.

Автор:
Алсу Троицкая

БАРЫСЫ ДА ЧЫНБАРЛЫКТАГЫ КЕБЕК

Шөгердәге Нефть музее буенча сәяхәт штольня кебек ясалган залларның берсендә башланып китә. Күсе чинаган, кешеләр сөйләшкән һәм металл кыргандагыдый тавышлар ишетелә. Югалып калуымны күреп, **Шөгер нефть музее мөдире Фәнис Галимов** имән баганага шакып алды да сөйләргә кереште:

– Галлюцинация түгел, курыкмагыз. Музейга килгән кеше шул чор атмосферасын мөмкин кадәр чынбарлык итеп тоя алсын, дип тырыштык. Күрәсезме менә бу терәкләрне, эшләүчеләр үз артларыннан түшәмне шулар белән ныгытып барганнар... Витринага куелган предметларны – тоткалар, кәйлә, ломнарны – барысын да шахтада табып алдык. Хәзер шахта үзе дә музейга килүчеләр өчен ачык.

– Һәм без анда да керә алабызмы?

– Әлбәттә! Битум эретү, нефть кудыру цехларын, нефть технологияләре тарихы паркын, остаханәләрне, штольняны да карарбыз... Баштарак битум эретү турында видеоролик күрсәтә идек, – дип, Фәнис Миншәһит улы безне «шахта» уртасындагы караңгы залга әйдәде. – Ә хәзер кунакларыбыз боларның барысын да үз күзләре белән күрә ала.

БИТУМ ЭРЕТӘБЕЗ, УРМАН КИСӘБЕЗ

Музейның «теоретик» өлешендә кызыклы макетка тап булабыз. Фантазиябезне эшкә җигеп, 1876 елның эссе июль аен күз алдына китерәбез.

Шушма елгасы үзәне буйлап: «Әйдә-әйдә, болгат, нәрсә карап торасың?» дигән сүзләр яңгырый. Тау итәгендә атлар, арбалар, утыннар, кешеләр – барысы да, кырмыскалар кебек, бертуктаусыз хәрәкәттә. Яр буенда пар чыгарып казаннар кайный: битум эретүнең беренче этабы бара. Әлеге хәзинә 18 метрлы тау куышлыгында – бихисап. Битум 30 градус эсселектә ялтырап тау комы арасында эреп ята. Ул бөтен җирдә бар, аны ала гына белергә кирәк. Әллә ни катлаулы булмаса да, авыр хезмәт. Моның өчен бер төркем ир-ат кайнар су әзерли, бер өлеше комташ җыя, өченчеләре аны битум җитештерү урынына алып килеп, казаннарга бушата. Ә анда, зур агач кашыклар

Фото: Александр Ефремов

бирешмәгән. Еллык җир салымыннан азат итәргә вәгъдә бирүе дә, авыл бәйрәмнәрендә акча өләшүе дә «эретә» алмый халыкны – дип сөйли безнең гид. – Шандор-тау итәгендә, Шушма елгасы буенда ул 16 гектар мәйданлы зур булмаган битум заводы төзи. Бу урында эшчеләргә кул белән битумлы комлыклар чыгару өчен штольнялар казыла. Ләкин венгрның эзләнүләре моның белән генә бетми. Нефть! Нәкъ менә нефть аңа тынычлык бирми дә инде.

БАР ИДЕ ШУНДЫЙ ЧАКЛАР!

Элеккеге заводтагы оператор залының безнең көннәргә кадәр үзгәрешсез саклануы шаккатыра. Өч кенә әйбер өстәлгән – идарә пульты операторы, нефть битумы комплексы макеты һәм фоторәсемнәр куелган стенд.

– Советлар Союзында иң яхшы саналган төрле маркадагы битум артыннан монда килгәннәр, бөтен төбәкләрдән, – ди Фәнис Миншәһит улы. – Төягәннәрен көтеп, машиналар атналар буе басып торган.

Мин үзем заводның соңгы көннәренә кадәр монда эшләдем. Табыш китермәгәнгә, аны 2009 елда консервациягә яптылар. Дүрт елдан соң предприятиене бетерү турында карар кабул ителде. Бәхеткә, ул вакытта «Татнефть» җитәкчелеге җирле халыкның 140 ел буе эшләгән заводны саклап калу турындагы фикеренә колак салды. Хәзер бу – уникаль сәнәгать-мәдәни мирас һәйкәле. 2015 елның 21 августында биредә Нефть музее ачылды.



белән 6–7 сәгать болгатып торганнан соң, судан җиңел битум өскә күтәрелә. Аны, сөт өстеннән каймак җыйган кебек, чүмеч белән агач мичкәләргә тутыралар да елга аша гына Сызрань белән Самарага – юл салучыларга сатып җибәрәләр.

– Битум чыгара башлаганчы, Шөгернең тирә-ягында куе урманнар булган, дип сөйли аксакаллар. Битум кайнату өчен шул агачларны якканнар. Анналары күрше урманнарга тотынганнар. Сөремнән, янып бетмәгән күмер тетененнән тончыгып, кошлар очкан җирләреннән егылып төшә торган булалар. Мондый гаять авыр хезмәткә җирле халык килмәгән, беренче эшчеләр сөргенгә сөрелгәннәр арасыннан булган. Алар яр буенда эшләгәннәр дә, шунда яшәгәннәр дә.

Кул астында атлар, гади эш кораллары һәм янәшәдә… хуҗа – чыгышы белән венгр булган Америка эшмәкәре Ласло Шандор, – Фәнис Миншәһит улының әлеге сүзләре безне чынбарлыкка кайтара.

НЕФТЬ АУЧЫЛАРЫ

Музейга килүчеләрне Ласло Шандор үзенең эш өстәле артында каршы ала. Нәкъ тере кеше кебек. Тәрәзәдән тау янында төзелгән корылмалар күренеп тора – тизрәк шунда бару теләге тынгы бирми.

– Ласло Идел буенда битум җитештерүен оештыру һәм нефть табу эшенә тотынган иң үҗәт америкалы булгандыр, мөгаен. Мондагы җирләрне арендага алу өчен аңа шактый тырышырга туры килгән. Халык тиз генә





«УЙНА ӘЛЕ ТАЛЬЯНЫҢНЫ СЫЗДЫРЫП...»

Без ачык һавада, агач буровойдан нефть технологияләре тарихы паркына кадәр барган арада, Фәнис Миншәһит улы венгр сәнәгатьчесе турында хикәясен дәвам итә:

– Шандорның бораулау өчен дөрес урын сайлап алуын танырга кирәк. Әмма ул нефть ятмаларына кадәр төшеп җитми, тиешле техник җиһазлары булмый. Кызганыч, инвесторларны да җәлеп итә алмый. Нәтиҗәдә, ул 1881 елда үзенең җитештерүен арзан бәягә генә сатып, китеп бара. Бөлә һәм күздән китеп югала...

Шушы урында без венгр сәнәгатьчесе тарихына нокта куябыз. Тальян моңнары астында күңелсез әйберләр турында сөйләшәсе килми. Туктале, каян килә соң бу тавыш? Көй кечкенә генә өйдән ишетелә икән.

– Без заводның хезмәт зонасын гына түгел, эшчеләр көнкүрешен дә күрсәтергә тырыштык. Менә шундый йортларда яшәгәннәр алар, – дип аңлата Фәнис Галимов.

Ә алда безне экскурсиянең иң кызыклы өлеше көтә.

«Татарстан»нан киңәш:
Сез монда елның җылы вакытында килергә уйласагыз, экскурсиягә алдан ук заказ бирегез. Шул чакта сезне хуш исле чәй һәм бал белән каршы алачаклар. Ә Шөгер нефть музее мөдире үз куллары белән чыгарган мичтә кунакларга тәмле коймак пешереп бирәләр.

ШТОЛЬНЯГА, ШТОЛЬНЯГА...

Менә ул – штольняга керү юлы. Монда тауны тыштан да, эчтән дә капшап карарга була. Караңгыга ияләшү өчен, күзләрне берничә мизгелгә йомып торырга кирәк:

– Вау! Искиткеч! Монда нинди ташлар аунап ята? Тау әле дә ишеләмени? Ә каскаларны кию мәҗбүриме? Ә бу атның күзләре ни өчен бәйләнгән? Ой, мин анда бармыйм, куркыныч! – без күргәннәрдән сүзсез калдык. Әмма барысы турында да сөйләп тормыйбыз. Киләчәктә килүчеләр өчен сер булып калсын. Бер генә нәрсә әйтик – тарихи чынбарлыкны үз күзләрең белән күрү мөмкинлеге бар монда.



Эретү залы диварларында – корым эзләре. Эретүчеләр эшли. Җитештерүне көйләп кенә җибәргән чорда, Ласло Шандор вакытында, битум кайнату эшләре елга ярында оештырылган. Еллар узгач, ачык типтагы казаннарны монда күчергәннәр. Элеккечә үк утын якканнар. Җилләтү өчен түшәмдәге тишекләр, тәрәзәләр һәм ишекләр генә була. Күпчелек хатын-кыз эшчеләр мондый төтендә хәтта бер-берсен күрмәгәннәр дә.

ҺӘРКЕМ ӨЧЕН АЧЫК

Күргәннәрдән өнсез калып, без 1906 елда төзелгән эретү цехына әйләнеп кайтабыз. Биредә һәр катта күзәтү мәйданчыклары урнашкан.

– Бу бинаны күп тапкырлар инде сүтәргә тырышып карадылар. Булдыра алмыйлар – дип сөйли экскурсоводыбыз. – Аны төзегәндә, йомырка сарысы өстәгәннәр, дип сөйлиләр. Ярый әле сүтә алмаганнар...

Бинаның уртасында лифт скважинасын күрәбез.

– Музей үсә, төрле кешеләр – инвалид, пенсионерлар да килә, – дип аңлата безнең Фәнис Миншәһит улы. – Барысының да бөтенесен дә күрәсе килә. Штольняны да. Шуңа күрә безгә хәтта электромобильләр сатып алдылар, шахтага кадәр урап узу өчен юл салдылар.

Ласло Шандор. Бәлки ул хәзер Самара губернаторы исеменә ярдәм сорап хат язадыр? Хат, мөгаен, җавапсыз калыр. Америкалы нефть катламына кадәр төшеп җитә алмый, ахыр чиктә, аның предприятиесе бөлә...



Ласло Шандор тапкан ятманың калынлыгы – 18 метр. Шөгердә кар аз булган вакытта, аны тышкы яктан да, эчке яктан да күрергә була. Карарак катламнар – битумлы комташ.

ВАКЫТ БУЕНЧА СӘЯХӘТ

– Сез биш дәрәҗәнең берсен сайлап ала аласыз, – ди алып баручы һәм һәр уенчыга уен сценарием биреп инструктаж үткәрә. – Барыгызның да максат бер – җимерелгән шахтадан чыгу. Исән калганнар бер-берләрен эзли. Һәм «ирекккә» чыга...

Шөгер квесты шулай башлана. Әгәр сезгә бу җиңел булып тоелса, ышандырып әйтә алабыз – җир астында адашып йөрүдән гыйбарәт бу бирем нык холыклы кешеләр өчен генә. Ә менә дусларыгыз белән бергәләп үзегезне сынап карарга, юлдашларыңның зирәк һәм ышанычлы булуын тикшерергә телисең икән, менә дигән мөмкинлек. Бердәнбер шарт-музей хезмәткәрләре белән алдан ук килештереп куярга кирәк. Алар исә квестка нәкъ менә кыш көне килергә киңәш итә: «Салкын булгач, баш мие дә тизрәк эшли башлый. Беркем дә штольня диварларында туңып калырга теләми».

Шөгер битум заводыннан фронтка 180 кеше киткән. Аларның өчесе Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган. Ибрай Мурзин һәм Ислам Халиков сугыштан кире кайта алмый. Самат Садриев исән кала һәм әле күп еллар нефтьче булып эшли.

НӘРСӘ:
Шөгер нефть-битум заводының музей комплексы

КАЙДА:
ТР, Лениногорск районы, Шөгер авылы, Завод ур., 7

КАЙЧАН:
Көн саен 8:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр.
Шимбә, якшәмбе – ял көннәре.

100 ТАТАРСТАННЫҢ МУЗЕЕ

«Татарстан» журналы версиясе буенча

ИҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ.
ЗӨЯДӘГЕ АГАЧ АРХЕОЛОГИЯСЕ МУЗЕЕ

Зөя утрау-шәһәре пристаненнан бераз уң яктарак бер таучык күзгә чалына. Якынрак килеп баксаң, бу гади калкулык кына түгел икән бит. Ул үз эченә Агач археологиясе музеен «яшергән».

Автор:
Алсу Троицкая

АК-КЫЗЫЛ-КАРА

Кечкенә, ямьсез генә йортлар бер-берсенә сыенган. Алар, без күнеккәнчә, урамга алгы яклары белән каратып түгел, ә һәр хуҗа үз тәрәзәсеннән бөтен урамны күрсен өчен, бераз аркылырак салынган – урта гасырда җәмәгать иминлеген саклау системасы шулай көйләнгән булган, күрәсең. Слюдадан ясалган тәрәзәләр хуҗаларның хәлле булуы турында сөйли: слюданы читтән китерәләр, мондый байлыкка ул вакытта теләсә кемнең теше үтә алмый. Үгез яки балык куыгыннан тарттырылган тәрәзәләр ешрак очрый. Аллага шөкер, Зөядә зур балыкларга кытлык булмаган һәм юк.

– Кызыл тәрәзә, ягъни «пыялалы» тәрәзәне «кызыл» өйдә генә кисеп куюның мәгънәсе бар. «Кызыл» дип ак мич белән җылытылган йортны атыйлар. Ә менә өй морҗасыз мич белән ягылса, андыйны кара өй (курная изба) дип йөртәләр. Анда әнә шундый урта гасыр кондиционерыннан башка мөмкин түгел. Бу – шудырма тәрәзә. Шкаф-купега охшаганмы? XVI гасырда йортларда да, мунчаларда да, гыйбадәтханәләрдә дә шундый тәрәзәләр кулланылган. Ә кара өйләрдә алар, кагыйдә буларак, өчәү: түшәм астында, янып-көеп китмәсен өчен карый-карый, хуҗабикә ашарга әзерләгән җирдә һәм өченчесе – хуҗа кешенең күз биеклегендә. Ә монын өчен иң кулай урын кайда? Әлбәттә, кызыл почмакта – тәреләр астында. Чөнки хуҗа кеше урамнан кем узып барганын, капкага кем кергәнен күрергә тиеш…

ҺӘРНӘРСӘ ДӘ – ҮЗ УРЫНЫНДА

«Зөя утрау-шәһәре» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы экскурсоводы Ольга Малахова безгә урта гасырларга сәяхәт ясау мөмкинлеге бирә. Хисләребез тулы булсын өчен, Ольга Анатольевна безгә урта гасыр урамы буйлап узарга тәкъдим итә:

– Менә бу 30 метр озынлыктагы һәм 2,6 метр киңлектәге тыкрык биредә XVI гасырда ук булган. Археологлар казу эшләре вакытында кайры һәм йомычка түшәмә тапкан. Ә югарырак урнашкан подиумнан XVII гасырда урамга инде яркалар һәм такталар җәелүе аңлашыла. Әлбәттә, болар яңа чимал булмаган, бу агачлар башта үз вазыйфаларын йорт эчендә башкарган, аннары инде аларны урамга да түшәргә мөмкин дип табылган.

– 100 ел эчендә шундый зур мәдәни катлам ничек үсә алган соң?

– Зөя каласының түбәнлекле өлешендә туфрак һәрвакыт дымлы – әнә шул төп сәбәпче. Пычрак, лай ярып йөрмәс өчен, кешеләр урамнарны гына түгел, ишегалларын да күтәртеп түшәгән, – дип аңлата гидыбыз. – Бу эш шактый даими эшләнгәнгә күрә, корылмалар бик тиз җиргә иңә бара, билгеле. Берничә буыннан соң инде яңа йорт төзү таләп ителә, чөнки искесе землянкага әйләнеп бетә. Менә бөтен сер шуннан гыйбарәт. Безнең музейның үзенчәлеге шунда, мирасханәбездә шәһәр үсешенең барлык этаплары да күрсәтелгән – XVI гасыр уртасында нигез салыну вакытыннан алып XVIII гасырга кадәр. Йорт һәм хуҗалык корылмаларының буралары, коймалары һәм юл түшәмәләре – һәркайсы нәкъ үзләре табылган урында.

Фото: Алсу Троицкая, Александр Гайнетдинов

КАПМА-КАРШЫЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ

Археология музее әле сабый гына – аңа бер яшь яңа тулып узды. Коллекциясе табигатьнең үзе ярдәмендә – дымлы археологик культура катламы дип аталган үзенчәлек бәрабәренә барлыкка килде. Ни өчен дымлы катлам дип атала, диярсез? Чөнки ул су белән мул туендырылган, башка шартларда бик тиз тарала, череп югала торган агач, тире, йон кебек барлык органик материал бу катламда консервацияләнә бара.

Музейда футуризм һәм борынгылык искиткеч рәвештә бер-берсенә керешеп китә. Мирасханәләргә хас катгый шартлар юк, әмма чиктән тыш авангардлык басымы да сизелми – тарих һәм модернның үзара ярашкан күркәм мәйданы хасил булган.

Музейны тышкы яктан кечкенә генә калкулык дип уйларга мөмкин:

– Мондый форманың сайлануы бер дә юкка түгел, – дип аңлата Ольга Малахова, – ЮНЕСКО белгечләре гадәти булмаган, тыюлыкның тышкы күренешенә дә туры килерлек архитектура карарын табарга киңәш иткән иде.

Музей нәкъ казу эшләре барган җирдә урнашкан. Казу урыны – урта өлештә. Экспонатлар, табылу вакытына карап, вертикаль катламнарга бүленгән. Иң аскысы – XVI гасыр уртасына, Зөянең төзелгән чагына карый, бераз өстәрәк – XVII гасыр башы, аннары асылмаларда XVII гасыр ахыры – XVIII гасыр башы чагылыш таба.

Ә казу урыны тирәли экспонатлы витриналар, шул исәптән интерактив витриналар да куелган. Музейга килүчеләр экскурсоводсыз гына да бик шәп йөреп, үзләре өчен шактый кызыклы нәрсәләр таба ала. Бер яктан монда – XVI–XVII гасырлардагы төзелеш технологияләре турында сөйли торган табылдыклар. Икенче яктан – күпсанлы эш кораллары, уенчыклар, зәркән эшләнмәләре, аш-су кирәк-яраклары, кайры сүстән ясалган әйберләр, кораллар, тәңкә акчалар. Иң борынгы экспонатлар – болгар тибындагы савыт-саба һәм шул чордагы тәңкәләр... Барлыгы 1600 дән артык экспонат тәкъдим ителә.



Тимер-томыр әйберләр, күгәннәр, атламалар, кадаклар ул чорда бер дә арзан йөрмәгән һәм осталар алардан башка гына эш итәргә өйрәнгән. Менә бу ишек, әйтик, күгәннәрсез генә ясалган. Ишек астында – чөйсыман аяк, ә ишек яңагында – уем. Бу – XVI гасыр яңалыгы. Бүген дә фатирларда-йортларыбызда шул ук принцип белән чөйләргә утыртылган тимер ишекләр тора. Һәр яңалык – күптән онытылган борынгылык ул.

ЧЫП-ЧЫН, ХАЛЫКЧАН ТУЛА

– Музей экспонаты булганчы, теләсә нинди археологик табылдык бик сабыр һәм тыйнак, чып-чын тылсымчыларга тиң реставраторлар кулы аша уза, – дип сөйли-сөйли, Ольга Малахова безне реставрация кораллары тезеп куелган витриналарга таба алып килә. – Реставраторлар фәнни ачышлар, мәшһүр исемнәр күләгәсендә кала, гадәттә. Алар тарихи һәм мәдәни белемнәргә генә ия булып калмыйча, физика һәм химия белән дә бик якын таныш булырга тиешләр. Күз алдыгызга китерегез әле, нииндидер йомарланган төерчек табып алдылар, ди, шул табылдыкны әфсенлиләр-төфсенлиләр дә, нәтиҗәдә, безнең алда тукыма пәйда була. Русларда «сермяжная правда» дигән гыйбарә бар, ә күпләр «сермяга» сүзенең нәрсә икәнен дә белми. Асылда, бу йон һәм җитен җепләрдән өй шартларында тукылган тула, постау. Менә ул, каршыбызда! 400–500 ел элек ата-бабаларыбыз, иң гади кешеләр, нәкъ менә шундый тукымадан тегелгән кием-салым киеп йөргән.

Борынгы осталарның бураларны төрле ысул белән кискәнен, аларның бүрәнәне кайрыдан ничек чистартканын, пычкысыз гына бу агачларны тактага ярганын, чөйләр белән ничек такта эшләгәннәрен шушында тыңлап беләбез… Төзелеш технологияләренә заманча реконструкция уздырган Александр Попов – Вологда өлкәсеннән агач ядкәрләр реставраторы, урта гасыр архитектурасы буенча абруйлы белгеч. Без балта, кайры каезлау өчен атламалар, өтергеләр, бораулар, мүкләгечләр һәм хәтта пычкылар да күрәбез. Гид аңлатмасыннан рус осталарының пычкы дигән коралны бик аз файдаланганын беләбез. Ник алай икән?

– Пычкы агач җепселләрен боза, бу исә агачның тизрәк черүенә китерә. Ә балта агачтагы бик кечкенә ярык-тишекләрне изеп кыса һәм, шул рәвешле, табигый консервация ясый. Борынгы бабаларыбыз, әлбәттә, агачның микрокүзәнәкләре турында берни дә белмәгән, алар барысына да тәҗрибә юлы белән ирешкән.

Табышмак: урта гасырда Зөягә дөя каян килеп чыккан?

Җавап: Сере бик гади. Казан ханлыгы Урта Азия һәм Шәрык илләре белән тыгыз сәүдә элемтәләре тоткан. Бу территорияне үзенә кушкач, кем инде шундый багланышларны өзсен, ди? Казан урамнарында дөяләр басып торган XX гасыр башы фоторәсемнәре әле һаман да саклана.

Музейның төп залына керү юлында кунакларны ерак чорларны үзенә сыйдырган хронологияле менә шушындый дивар каршылый. Иң аскы катлам XVI гасырга карый.

Монда казу эшләренә килгән археологлар ниләр күргән соң? Бик күп йомычка, агач кисәкләре, алар арасында – төрле корылмалар, көнкүреш кирәк-яраклары, уенчыклар, аяк киеме, кием-салым һ.б. да бар. Тәрәзәләргә күз салсак, археологларның эш барышын күзәтә алабыз.

«ШӘҺӘР ҮЗ КЕШЕЛӘРЕНЕҢ БӘХЕТЕ БЕЛӘН ЯШИ»

Урта гасырларны гизгәннән соң, музейдан чыгу юлына юнәләбез. Монда да безне таң калырлык манзара көтә. Борынгы Зөя каласы көндәлек тормышы белән яшәп ята. Менә мичкәләр төялгән атлы арба бара, каршы ярга чыгар өчен бу ярдан паром кузгалган. Шунда ук, су читендә, хатыннар кер юа. Элегрәк агачтан төзелгән гыйбадәтханәне – Апостолларга тиң Констънтин белән Елена чиркәвен таштан салып яталар, ә күрше урамнарның берсендә янгын сүндерәләр. Янәшәгенә – туй һәм тәре йөреше. Менә бер почмакта балык чистарталар, ә бераз читтәрәк уйчан дөя басып тора...

Болар барысы да XVII гасырдагы Зөя шәһәренең көнкүрешен сурәтләгән 21 метрлык паннода чагылыш тапкан. 120 мизансценада 450 персонаж гәүдәләнгән. Әлбәттә, бу – тарихи документ түгел, әмма бик шәп иллюстрация, Зөя рәссамы Рәшит Сафиуллин тарафыннан «Сәмруг» иҗат берләшмәсе белгечләре белән берлектә иҗат ителгән чын сәнгать әсәре. Урта гасырлардагы барлык антураж – корылмалар, предметлар, һөнәрләр, кием-салымнар һәм сюжетлар тарихи чыганаклардагы рәсемнәр вә тасвирламалар буенча башкарылган.

НӘРСӘ:
Зөядә Агач археологиясе музее

КАЙДА:
«Зөя утрау-шәһәре» музей-тыюлыгында

КАЙЧАН:
Көн саен 10:00 сәгатьтән 18:00 сәгатькә кадәр

100 ТАТАРСТАННЫҢ МУЗЕЕ



ИҢ ФӘННИ. АКАДЕМИК АРБУЗОВЛАР МУЗЕЙ-ЙОРТЫ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

Бүгенге тормыш ыгы-зыгысында сакланып калган узган гасыр утравы. Тәбәнәк тәрәзә төпләрендә – гөлләр, җәйге верандада – талдан үрелгән җиһазлар һәм бакча – болар барысы да үзенә чакырып-ымсындырып тора. Ә инде җөрьәт итеп, бусагадан узасың икән, хуҗалар өйдә юк чакта яшерен генә кергәнсең кебек тоела…

Автор:
Ольга Туманская

КЕШЕЛӘР АРАСЫНДАГЫ МӨНӘСӘБӘТЛӘР ХИМИЯСЕ

Бервакыт Арбузовлар музей-йортына күренекле поляк химигы Ян Михальский килә. Күп еллар элек аның биредә кадерле кунак хокукында булганы бар икән.

– Кызганычка каршы, без сезнең белән тәрҗемәче аша гына аралаша алабыз. Мин русча яхшы беләидем, әмма картая-картая оныттым, – ди ул музей-йортның директоры Наталья Кореевага. Әмма кунак бүлмәсенә үткәч, шулкадәр дулкынлана һәм шунда ук… бөтен нәрсәне исенә төшерә.

– Бернәрсә дә үзгәрмәгән! Бөтен нәрсә үз урынында! Арбузовлар вакытында ничек булса, хәзер дә нәкъ шулай! – дип, русчалатып сокланганын сизми дә кала ул.

Музейга моннан да зуррак бәянең булуы мөмкин дә түгелдер.

«Огонек» журналының 1954 елгы гыйнвар саны тышлыгы. Менә ул уникаль тандем – ата һәм ул, ике күренекле химик. Александр Ерминингельдович кулына колба тоткан. Аның хезмәттәше һәм варисы Борис Александрович каләм һәм блокнот белән «коралланган». Аларны бик мавыгып гәпләшкәндә төшереп алганнар кебек…

– Арбузовлар – феноменаль күренеш. Күз алдыгызга китерә аласызмы – бер гаиләдә ике академик булсын әле! – дип сөйли Наталья Кореева. – Аларны коллегалары гына түгел, гади кешеләр дә белгән һәм хөрмәт иткән. Арбузовларга мактаулы исемнәр, бүләкләр бирелгәндә, гади совет гражданнары да галимнәрне котларга ашыккан. «Казан, академик Арбузовка» адресына бөтен илдән хатлар яуган. Бәхеткә, һәр хат ташучы аларны кая илтергә кирәген яхшы белгән.

Музей фондларында әлеге күпсанлы котлаулар саклана. Тагын әле анда «теләсә күпме акчага» дару җибәрүне үтенгән хатлар да бик күп. Александр Ерминингельдович беркемнең үтенечен дә җавапсыз калдырмаган, диләр. Ул уйлап тапкан дару – дөньяда глаукома үсешен акрынайта торган беренче препарат фосарбин – бик күп кешене сукыраюдан саклап калган.

Фото: Александр Ефремов

Александр Ерминингельдович кечкенә утарлы алпавытлар нәселеннән. Борынгы фотода – зур нәселнең әле бик аз өлеше генә! Нәселдән килгән утарлары, Арбузово-Баран авылы, хәзер дә исән әле.

Ул умартачылык белән шөгыльләнгән, чәчәкләр үстергән, чәйнең безнең климат шартларында үсә алырлык сортын чыгарырга тырышкан… Бу – Бутлеров турында. Яшь Саша үзенең бөек адашы белән гимназиягә керер алдыннан танышкан. Берничә көннән соң атаклы химикның гомере өзелгән, әмма әлеге очрашуны Саша бөтен гомере буе онытмаган.

Сүз уңаеннан, журнал тышлыгына эләккән колба гади генә түгел. Ул Александр Арбузов эскизлары буенча ясалган. Һәм әле бу галимнең лаборатория тикшеренүләре фәне һәм техникасына керткән яңалыкларының бик аз өлеше генә. Аның үзе һәм улы Борис ясаган ачышлар илебездәге күп кенә дарулар, шулай ук бүген авыл хуҗалыгында һәм сәнәгатьнең төрле тармакларында кулланыла торган бик мөһим кушылмалар җитештерүдә беренче баскыч була.

Борис үз сүзендә нык тормаса, әлеге тандем оешмас та иде, бәлки. Өлкән Арбузов улының абруена тап төшерерлек имеш-мимешләрдән – янәсе, гыйльми дәрәҗәне «нәселдәнлек буенча» алган, дип сөйләүләрдән курыккан. Әмма Борис бирешмәгән.

– Ул, башка шәкертләренә караганда, улы Бориска күпкә таләпчәнрәк булган, һәм бу кайвакыт артык катгый кебек тә тоелган, – дип сөйли Наталья Кореева. – Мондый мәктәп яшь Арбузовка әтисенең көрәштәше булырга гына түгел, башка кыенлыкларны җиңәргә дә мөмкинлек биргән.

1938 елда Борис Александровичны кулга алалар. Әтисе көн саен Сталинга телеграмма җибәрә: улын иреккә чыгармыйча, ул эшкә тотынмаячак. «Мин уңайлы вакыт аралыгына туры килдем», – диячәк соңрак Борис Арбузов: Ежов урынына билгеләнгән Берия амнистия игълан итә, һәм химик иреккә чыга.

Һәм ул Татарстанга зур файда китерә! Борис Александрович 1911 елдан – Александр Ерминингельдович Казан Император университетының органик химия кафедрасы җитәкчесе итеп куелган вакыттан башланган алтын «Арбузов дәвере»н 1991 елга кадәр озайта. Бу – Казан химия мәктәбенең гөрләп эшләгән чагы. Арбузовларны тере легенда дип йөртәләр. Александр Арбузов җитәкләгән химия институтына 1947 елда Сталин фәрманы белән Александр Арбузов исеме бирелә, һәм әле тагын озак еллар буе өлкән Арбузов үз исемендәге институтны җитәкли, бу үзе дә – моңарчы тиңе булмаган күренеш.

Сүз уңаеннан, Борис кына түгел, Александр Ерминингельдовичның башка балалары – Юрий һәм Ирина да абруйлы галимнәр, фән докторлары. Әлеге искиткеч музей-йортта йөргәннән соң, үзеңне даһилар тәрбияләүнең серенә төшенә башлагандай тоясың.

ДЖЕНЕРИК – КОТЫЛУ ЧАРАСЫ

Беренче Бөтендөнья сугышының иң киеренке фронтларыннан берсе фармацевтика фронты була. Россиядә дару кытлыгы башлана – чит илләрдән дарулар кертү туктала. «Яу кырына» иң акыллы галимнәргә чыгарга туры килә. Арбузовның җиңүгә керткән өлеше бәяләп бетергесез: 1914 елда Александр Ерминингельдович ацетилсалицил кислотасының Россиядәге аналогын синтезлый. Ул вакытта аны бары тик Германиядә генә җитештерә торган булалар.

Дженерик оригиналы кебек үк яхшы булып чыга! Арбузовка тагын бер бурыч – бөтен илне тәэмин итү өчен, аспиринны сәнәгатьтә җитештерүне җайга салу йөкләнә. Тиздән Казанда, бертуган Крестовниковларның сабын кайнату заводы территориясендә, фармацевтика җитештерүе эшли башлый. Арбузов үз даруының этикеткасын да шәхсән үзе ясый, аның дарухәнә бизәгенә әйләнүен тели. Мин исә әлеге этикетканы бер гасырдан соң музей витринасында карап хозурланам. Лалә чәчәгендә һәм аждаһа сурәтендә Казан турындагы хәбәр яшерелгән, һәм ул шәһәр данын меңнәрчә чакрымнарга тарата...

Музей экспозициясендә 1962 елгы кызыклы фото бар: депутат Александр Арбузов СССР Югары Советы сессиясен ача. Хрущёв һәм Брежневның аны алкышлавы күренә. Александр Ерминингельдович бик җаваплы кеше була. Аның төп варисы – өлкән улы да шундый ук. Татарстанның иң изге урыннарыннан берсенең сакланып калуы өчен нәкъ менә Борис Арбузовка бурычлы булуыбызны бик аз кеше белә. Борис Александрович Болгарның талануын туктата, объектны 1970 нче елларда дөрес консервацияләп, аны кагылгысыз итә. Ул тарихны саклау өчен янып йөри, һәйкәлләрне яклау җәмгыятенең мактаулы әгъзасы була. 1978 елда Казанның миллионынчы кешесе туугa багышланган митингта Борис Арбузов чыгыш ясый. Ул үзәгенә үткән нәрсә – мәркәзебездәге тарихи үзәкнең юкка чыгарылуы турында ачынып сөйли. «Бездән соң килгән буын мондый хаталарны кабатламас, дип өметләнәм...» – диелә аның музей фондларында сакланган чыгышында.

Борынгы шкафта бу лаеклы кешеләр яшәгән чорга һәм аларның шәхси казанышларына кагылышлы дәлилләр саклана. Александр Арбузовның 1946 елда Лондонга Ньютонның тууына 300 ел тулуны бәйрәм итәргә бару өчен тектергән фрагы. Борис Арбузовның 1977 елда Гданьск университетының мактаулы докторы итеп сайланганда кигән мантиясе. «Казанның мактаулы гражданины» тасмасы. 1987 елда – революциядән соң беренче тапкыр! – әлеге исем Борис Арбузовка бирелә. Урманче, Девятаев, Исәнбәт белән беррәттән...

ЭШ ТУРЫНДАМЫ? СӨЙЛӘШМИБЕЗ!

– Мемориаль урынның үзе, мәйданы, коллекциясе – барысы да бергә сакланып калу – бик сирәк күренеш. Россиядә мондый музейлар берничә генә, – ди Наталья Кореева.

Ул моннан ярты гасыр элек ачыла. Беренче экскурсияне Борис Александрович үзе үткәрә, һәм мондый музей химия белән мавыгучыларга гына кызыклы булыр, дип саный. Тик бу юлы ул ялгыша! Узган гасыр зыялылары тормыш һәм көнкүрешенә бернинди чикләүләрсез баш белән чуму искиткеч кызык бит ул! Әйберләр фактурасы, авазлар, исләр аша әлеге дәверне бөтен сизү әгъзалары белән тоясың. Бу йортта, элеккечә үк, һәр нәрсә үз урынында ята, буш шкаф һәм сандыклар юк...

Арбузовлар йортында табышмак-экспонатлар күп. Наталья Кореева буфет ишеген ача һәм әллә кайдан гына тишек төпле пыяла «ваза» тартып чыгара. Сәер графинмы бу? Әллә шәмдәлме? Бик озак баш ватарга мөмкин бу турыда. «Чебен тоткыч!» – дип безгә ярдәмгә килә директор, һәм мин бу бик сәер савытны әйләндерә-әйләндерә карый башлыйм.



Сүз уңаеннан, 1914 елда төзелгән бу йорт беркайчан да Арбузовларныкы булмаган – алар аны илле елдан артык арендага алып яшәгән. Баштарак йортның законлы хуҗасы – атаклы рәссам Иван Шишкинның бертуганының кызы Алексеевадан, соңрак исә – дәүләттән.

– Бу – җыйнак кына табышлы йорт үрнәге, – дип сөйли Наталья Кореева. – Бик күп ишекле дом-трансформер, йозакларның барысын да ачсаң, аны зур коммуналкага әйләндереп була.

Уйлануччан кешеләрне гаҗәпкә калдырырлык тагын бер факт – Александр Арбузов кебек зур галимнең өендә эш кабинеты бөтенләй булмаган! Чөнки катгый кагыйдә сакланган: өйдә эш турында бер сүз дә сөйләнергә тиеш түгел. Бу – бары тик гаилә һәм мавыгулар вакыты гына.

Уңайлы кунак бүлмәсендә ике язу өстәле тора. Зурысы – Александр Ерминингельдович өчен, икенчесе, кечерәге – аның хатыны Екатерина Петровнаныкы. Аларны музыка бәйли. Бер-берсен балачактан белгәнгә, икәү скрипка һәм фортепианода уйный, вакытлар үтү белән, әлеге дуэт гаиләнекенә әйләнә. Аларның һәр киче тылсымлы моң белән тулы була.

Һәм менә инде Штраусның «Гүзәл зәңгәр Дунайда» вальсы минем өчен яңгырый. Чын патефоннан бераз шытырдабрак агыла көй, әмма җанга шундый рәхәт! Вакыт машинасы төсле, ул мине әллә кайчангы Арбузовлар йортына җибәрә – кич, бөтен гаилә кунак бүлмәсенә җыйналган, алар бергә җырлый, укый, уйный, аралаша....

Екатерина Петровна рояле, Александр Ерминингельдович скрипкасы – барысы да үз урынында. Һәм әле тагын картиналар – авторның үзенең пейзажлары һәм бөек рәссамнарның әсәр күчермәләре. Барысын да өлкән Арбузов ясаган.

– Куинджины күчереп ясау өчен нинди кыюлык кирәк! – дип соклана Наталья Кореева. – Ә Александр Ерминингельдовичта шундый кыюлык булган. Ул, кеше һәрьяклап сәләтен үстерергә – музыка, әдәбият, сынлы сәнгать белән кызыксынырга, концертларга йөрергә һәм хәленнән килгәнчә язарга, рәсем ясарга тиеш, дип санаган. Һәрвакыт зәвык белән бик матур, пөхтә киенгән, үзен-үзе бик карап йөрткән. Балалары да шундый булган. Бигрәк тә – Борис Александрович, ул агачка уеп бизәк төшерә, фотога төшерү белән мавыга... Музейда аның эшләрен дә күрергә мөмкин.

Бу йортта йөрү бик рәхәт хисләр тудыра. Һәм бик күп сораулар да. Иң фәнни музей күп нәрсәләр турында уйланырга мәҗбүр итә.

НӘРСӘ:
Академик Арбузовлар музей-йорты

КАЙДА:
Казан, Катанов тыкрыгы, 8

КАЙЧАН:
Көн саен 10.00 сәгатьтән
17.00 сәгатькә кадәр.
Шимбә,якшәмбе – ял көннәре

100 ТАТАРСТАННЫҢ МУЗЕЕ



Фото: Лилиана Вәлитова

ИҢ ТАНЫШ. БАКЫЙ УРМАНЧЕ МУЗЕЕ

ПО ВЕРСИИ ЖУРНАЛА «ТАТАРСТАН»

Анда килеп кергәч тә, үзеңә төбәлгән карашларны тоясың. Әле кемнәр генә карый бит: татарның берсеннән-берсе затлы, даһи уллары – Тукай, Әмирхан, Мәрҗани, Дәрдемәнд, Җиһанов... Ул ясаган сыннар шул дәрәҗәдә җанлы булып күренәләр ки, килеп сүз кушардай буласың... Бакый Урманче музеендагы сыннар безне әнә шулай чынбарлыктан ерак үткәннәргә алып китте...

Автор:
Руфия Фазылова

ЕГЕРМЕ ЕЛ ЭЛЕК...

Бакый Урманче исемен ишетмәгән татар кешесе юктыр дип уйлыйм. Аны татар сынлы сәнгатенә үзеннән искиткеч олы өлеш керткән атаклы сынчы, талантлы, күпкырлы иҗади мирас калдырган рәссам буларак беләбез. Рәсем сәнгате белән сынлы сәнгать – аның ике канаты. Шунысы кызык: сынчылар Бакый аганы: «Ул безгә юл күрсәтте», – ди, рәссамнар исә: «Юк, ул – безнеке», – ди. Боларга өстәп, Урманче турында тагын нәкыш, графика остасы дип тә әйтергә кирәк. Хәер, бик күп нәрсә белән кызыксына, мавыга, үзен сынап карый ул тормышта...

Бөек шәхеснең биографиясенә, иҗатына кагылганчы, башта музей турында сөйләү кирәктер. Әлеге бина тарихи: ул XIX гасыр азагында төзелгән булган. Ике катлы йорт 1997 нче елга кадәр «коммуналка» дип атап йөртелгән, анда кешеләр яшәгән. Алар белән килешеп (торак биреп), йортны дәүләт карамагына күчерәләр. Шуннан ике катлы йортка өченче кат – чарлак (мансарда) өстәп коралар. 1999 елда аны Бакый Урманче музее итеп ачалар.

– Әлеге музейны оештыручы – Бакый Урманченың тормыш иптәше, фольклор белгече – Флора Әхмәтова-Урманче, – диде музей җитәкчесе Гөлүсә Әсфәндиярова. – ТРның ул вакыттагы Президенты Минтимер Шәймиев янына үзе барып, Бакый Урманче шәхесенең ни дәрәҗәдә бөек икәнен сөйли ул. Андый кешенең Казан үзәгендә музее булырга тиеш, ди. Президент әлеге идеяне берсүзсез хуплый. Нәтиҗәдә шушы музей барлыкка килә.

Биредә өч зал бар. Беренче катта – Фатих Әмирхан, Шиһабетдин Мәрҗани,

Бакый Урманченың шәхси әйберләре.



Беркайчан да музыка мәктәбендә
укымаган егет үзлегеннән скрипкада уйнарга өйрәнгән.

Флора Әхмәтова-Урманче портреты. Сәламәтлеге какшау сәбәпле,
оста тормыш иптәшенең рәсемен эшләп бетерә алмаган.

Габдулла Тукай, Кол Гали кебек бөек шәхесләрнең сыннары, икенчесендә – останың картиналары, ә инде өченчесендә – Бакый Урманченың шәхси әйберләре, шулай ук берничә картинасы урын алган.

– Бу шәхси әйберләрне Флора Әхмәтова–Урманче үзе алып килгән музейга, – дип сөйләде **музейның экскурсоводы Гөлгенә Абилова.** – Ул чакта әле мин монда эшләми идем. Флора ханым музей ачылганнан башлап, соңгы көннәренә кадәр биредә әдәби хезмәткәр булып эшләгән. Кинәт кенә вафат булмаса, әле Бакый аганың тагын күпме иҗатын өйрәнер, халыкка җиткерер иде.

Бакый Урманченың шәхси әйберләре өченче залда, чарлакта. Түрдә зур картина – тәмамланмаган эше тора. Бу – Флора Әхмәтова-Урманче портреты. Сәламәтлеге какшау сәбәпле, оста тормыш иптәшенең рәсемен эшләп бетерә алмаган. Ләкин шулай да бу картинада гаҗәеп бер җылылык бар. Ир белән хатынның бер-берсенә булган тирән ихтирамы, мәхәббәте сирпелә гүяки.

«НИНДИ КЕШЕЛӘР СОҢ СЕЗ?!..»

Бакый Урманчега шактый авыр язмыш сынауларын узарга туры килә.

Буа районының Күл Черкене авылында туган малайга әти-әнисе яхшы белем бирә. Әтисе, Идрис атлы авылның мулласы, башта улын Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укырга җибәрә (1907–1914 еллар). Аннан кайткач, үсмер малай Тамбов губернасының Тархан авылында мөгаллим була. Беренче бөтендөнья сугышы елларында армиягә алына, Казахстанда хезмәт итә. Менә шунда ул ныклап торып рәсем сәнгате белән кызыксына башлый. Революциядән соң Тәтештә Наркомпрос инструкторы булып эшли. Клублар, мәктәпләр һәм бәйрәм демонстрацияләре бизәү өчен лозунг һәм нәфис паннолар ясый.

Егерме ике яшендә Бакый Урманче Казан Сәнгать мәктәбенә укырга керә. (Ул вакытта әлеге мәктәп Казан ирекле сәнгать остаханәсе дип атала). Аннан соң белемен күтәрергә Мәскәүгә китә. ВХУТЕМАСның берьюлы ике факультетында – нәкыш һәм сынлы сәнгать остаханәләрендә укый. 1926 елда, укуын тәмамлап, бик күп идеяләр белән туган ягына – Казанга кайта. Иҗат итә, шуның белән беррәттән, Казан сәнгать техникумында уку-укыту бүлеге мөдире вазыйфасын алып бара. Тик оста, мөгаллимнең бу уңышлы юлы озакка бармый – 1929 елда аны кулга алалар. Сталинга гарәп әлифбасын сакларга өндәп язылган «82 кеше хаты»на кул куйганы өчен, аны Соловки атауларына сөргенгә җибәрәләр. Анда ул 1929 елдан 1933 елга кадәр була. Азат ителгәч, Мәскәүгә кайта. Тик бу шәһәрдә озак тормый, 1941 елда Алма-Атага китә. Соңрак Сәмәрканд, Ташкентта яши. Шулай итеп үндүрт ел буе Казахстан һәм Урта Азия мәдәниятен күтәрә, сәнгатьне пропагандалый, мәдәни-агарту эшчәнлеге алып бара. Ә Казанга ул бары тик 1958 елда, Сталин үлеп, «дөньялар тынычлангач»

«Җамбулда кунакта». 1946 ел.


«Йөзем җыю». 1958 ел.

кына кайта. Ул вакытта Бакый Урманчега 61 яшь тулган була инде.

– Кайбер кешеләрдән, Бакый Урманче татар милләтенә хезмәт итмәгән, дигән сүзләр ишетергә туры килә, – диде музейның экскурсоводы Гөлгенә Абилова. – Ә бит бу – нахак сүзләр. Беренчедән, яңадан Казанга кайткач, ул утыз елдан артык яши. Үзенең иң күренекле, иң дәртле әсәрләрен нәкъ менә шул чорда иҗат итә. Икенчедән, Казахстанга ул чарасызлыктан китә. Соловкида сөргенлектә күпме нужа чигеп, исән калганнан соң, аңа Санкт-Петербург, Мәскәү, Казан кебек шәһәрләрдә яшәргә ярамаган, чөнки «халык дошманы» дигән тамгасы булган...

Кызганыч, шул кара тамга белән Бакый Урманче гомеренең соңгы көннәренә кадәр яши. Дөрес, заманалар үзгәреп, аның кайчандыр сөргендә булганын күпләр онытa. Шулай да үзе ара-тирә искә ала торган була. Иң гаҗәбе – үләренә берничә ай кала, ягъни 1990 нчы елның 6 июнендә Бакый агага бер документ тапшыралар. Аны останың өенә бер яшь кенә егет алып килә. Документта мондый юллар була: «Габделбакый Идрис улы Урманчеев, ялгыш репрессиягә дучар булган...» Бакый ага шул юлларны укып чыга да, кәгазьне өстәл читенә куя. Аннан соң, берничә секунд читкә карап торганнан соң: «Нинди кешеләр соң сез?!..» – дип куя. Шуның белән бетә. Тормыш иптәшенә, балаларына да бу хакта башка сүз әйтми. Күрәсең, җитмеш ел буе нахакка «халык дошманы» исемен күтәреп йөри торгач, гарык була.

– Яшьрәк чакта Бакый Урманче үз исемен аклауны сорап бик күп хатлар язган, – диде Гөлгенә Абилова. – Тик ул вакытта аның бер хатына да җавап булмый. Мөгаен, алар кайдадыр югалгандыр. Гаепсезгә репрессиягә дучар булучылар бик күп бит. Ә инде олыгайгач, Бакый ага үткәннәрдә дөреслек эзләп казынмый. Үләр алдыннан «аклануы» шуның белән бәйле – 1990 нчы елларда архив документлары белән танышырга мөмкинлек туа, шул гына.

ТАЛАНТНЫҢ ЧИГЕ ЮК...

Җитмеш елдан артык сәнгатькә хезмәт итү дәверендә Бакый Урманче дүрт йөзгә якын нәкыш, йөз илледән артык скульптура һәм кәгазь битләрендә меңнәрчә график әсәрләр иҗат итә. Аңлашыла ки, башкаланың Щапов урамы, егерменче йортта урнашкан әлеге өч катлы бинага ул эшләрнең чиреген дә сыйдырып булмый. (Аларның күбесе дәүләт карамагында түгел дә). Шулай да останың бирелә шактый кызыклы эшләре бар. Мисал өчен, Тукайның Шүрәлеләре! Билгеле булганча, рәссам тарафыннан Габдулла Тукайның әлеге поэмасына карата бик зур игътибар бирелгән. Аның Шүрәлеләр турында ике йөздән артык эше бар! Урманчы Шүрәлене урман хуҗасы, хайваннар дөньясының кызыклы бер вәкиле генә түгел, ә табигатьнең якты рухы, рәхәт бер символы буларак та тасвирлый.

– Бу – Шүрәлеләрнең берничәсе генә, – дип таныштырып йөрде безне Гөлгенә Абилова.

Шүрәле турында сүз чыккач, Габдулла Тукайның Кырлайдагы музее турында да язасым килә. Бакый Урманче 1979 елда Кырлайга барып, берничә ай яшәп кайткан. Музейны ясау, бизәү – тулысынча аның идеясе, планы буенча эшләгән. Быел язын безнең редакция дә Кырлайда булып кайтты. Шулчак җирле халык Бакый Урманче турында: «Бакый ага үз эшенең чын остасы иде. Урманга үзе барып, музей төзү өчен өлгергән агачларны гына алып кайткан. Шуңа күрә ул бүрәнәләр бүген дә бер дигән итеп тора, хәтта ярылган урыннары да юк», – дип, тирән хөрмәт белән искә алдылар.

Музейга көн саен халык килә икән. Хәер, бу гаҗәп тә түгел, беренчедән, Бакый Урманченың шәхесе бөтен элеккеге СССР күләмендә билгеле. Икенчедән, берьюлы скульптура, нәкыш, графика, сценография үрнәкләренең оригиналларын кайда күрәсең?

Шулай ук бирелә сәнгать остасының иҗатына бәйле төрле кичәләр дә уза.

Музейга бүген дә студентлар, мәктәп укучылары бик теләп килә.


Автопортрет. 1947 ел.

Тукай, Әмирхан, Мәрҗани, Дәрдемәнд, Җиһанов... Ул ясаган сыннар шул дәрәҗәдә җанлы булып күренәләр ки, килеп сүз кушардай буласың...

– Флора Әхмәтова-Урманче әлеге үзәкнең җанлы булуын теләде, – диде музей җитәкчесе Гөлүсә Әсфәндиярова. – Үзе биредә эшләгәндә дә Бакый Урманче иҗатына багышланган кичәләр үткәрә идек. Бүген дә бирегә студентлар, мәктәп укучылары бик теләп килә. Бакый Урманче шәхес буларак бик кызыклы бит. Аның иҗаты аша татар сәнгате белән танышудан кала, Казахстан һәм Урта Азия мәдәнияте белән дә танышып була. Бакый ага РСФСРның һәм ТАССРның халык рәссамы булуы белән беррәттән, Казахстанның да атказанган рәссамы исеменә лаек булган кеше. «Җамбулда кунакта», «Тирмәдәге кызлар», «Тут агачлары», «Йөзем җыю» – барысы да шул якта яшәүчеләрнең тормышын, көнкүрешен яктырта...

Мин исә менә нәрсәгә игътибар иттем: Бакый Урманче мирасының скульптура өлеше, вакыт буенча соңгырак чорга – 1960–1970 нче елларга карый. Ләкин оста ясаган бөек шәхесләрнең сыннары музейның беренче залына ук урнашкан. Ни өчен? Музей хезмәткәрләре болай дип җавап бирде:

– Беренчедән, сыннарны аска катта саклау уңайлырак, – диде Гөлгенә Абилова. – Икенчедән, музейга килгән кунакларны Кол Гали, Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Дәрдемәндләр «каршылый». Әйе, бу – мәрмәр бюстлар гына, шулай да килгән кешеләр күңелендә нәкъ менә алар истә кала. Беренче чиратта, Бакый ага республика сәнгатендә үзенчәлекле скульптор буларак теркәлеп калган бит.

Музейда безне күп нәрсәләр тәэсирләндерде. Аерым картиналары күңелгә кереп калды. Тагын – Бакый аганың скрипкасы. Беркайчан да музыка мәктәбендә укымаган егет үзлегеннән скрипкада уйнарга өйрәнгән. «Талантлы кеше бөтен өлкәдә талантлы була», диләрме әле? Бу гыйбарә Бакый Урманче турында кебек тоелды. Биш-алты телдә аралаша алу – монысы да аның белемле, зыялы шәхес булуы турында сөйли. Һичшиксез, XX гасыр тарихына Бакый Урманче исеме эре хәрефләр белән уелып калган. Аның иҗатына, шәхесенә, киләчәк буын кат-кат әйләнеп кайтыр әле. Ә Казан уртасындагы музей бу юнәлештә аларга ярдәмче булыр, дип өметләник.

Останың Шүрәлеләр турында ике йөздән артык эше бар.

НӘРСӘ:
Бакый Урманче музее

КАЙДА:
Казан, Щапов ур., 20

КАЙЧАН:
Көн саен 10:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр. Дүшәмбе – ял көне

Бурлакчылык беркайда да Россиядәге кебек киң таралмаган була. 1895 елгы фото.

ИДЕЛ БУЕ КОРАБ УРМАННАРЫ: ТАРИХИ ЭКСКУРС

Төньяк сугышы барышында әле Петербургка нигез салынган гына, ә рус корабларына Балтыйк диңгезенә иркенләп чыгу мөмкин булмаган вакытта Петр I Казанны диңгез суднолары төзү буенча илнең төп үзәге итеп күрә. 1709 ел фәрманы нигезендә Идел буеннан Петербургка кораб төзү өчен имән урманнары кисеп җибәрелә башлый. Моңа кадәр ул кәүсәсе каты зур имәннәрне кисүнең бер хаҗәте дә булмаган, йорт төзелешенә, утынга, башка кирәк-яракка җиңел киселә торган яшь агачлар гына тотылган. Кеше кулы тимәгәч, меңәр еллык карт имәннәр сакланып килгән. Һәм менә берничә дистә ел эчендә Идел елгасы, аның кушылдыклары тирәсендә Идел буена болгарлар килгәнче үк, аннары Болгар дәүләте, Алтын Урда, ханлык чорларыннан ук калган карт имәннәр киселеп бетә.

Автор:
Илшат Фәйзрахманов



Агачны тамыры белән төпләп алу.

УРМАН – УРТАК БАЙЛЫГЫБЫЗ

Кораб төзү өчен иң беренче чиратта кәүсәсе нык, тыгыз имәннәр кулланылган. Корабның бөгелешле өлешләренә диеп күп вакыт агачны тамыры-ние белән казып алганнар. Шулай ук мачтага яраклы төз наратлар, бөгелүчән карама, элмә агачы, зирек күп тотылган, сирәгрәк булса да, каен, усак агачларын да кулланганнар. Идел буе урманнарының әлеге агач төрләренә бай булуы XVIII–XIX гасырларда аларның аяныч киләчәген билгели.

Кораб төзү эше бөтен ил белән алып барыла, ул Петербургта үзәкләштерелгән була. Башкаладагы төп Адмиралтействоның таләпләре, заказлары буенча Казан адмиралтействосы Петербург верфьләренә үзендә әзерләнгән агачның 85% ка кадәрен ел саен җибәреп тора. Тора-бара кораб төзелешенә урманнарны чама белмичә кисүнең зур зыян салачагын чамалаган хөкүмәт махсус чаралар күрә башлый. Зур елгаларга якын кораб урманнарын тәртипсез рәвештә кисү һәм кораб төзүдән тыш башка максатларда куллану тыела, законсыз урман кисүчеләрне зур штрафлар, тән җәзасы көтә. Урманны тоташ кисү туктатыла, кирәкле кораб агачларын гына кисү рөхсәт ителә. Болай эшләгәндә, урман мәйданнары кимемәгән дә кебек тоела, шулай да елга буйларында кораб төзү өчен яраклы агачлар бөтенләй калмый.

УРМАННАРНЫ – КАРТАГА

Петр I вакытында Идел буендагы кораб урманнарының күләмен беркем чамалап та белми. Петербургтан Казанга җибәрелгән капитан-командор Иван Козловка 1729 елда беренче мәртәбә биредәге кораб урманнарын барлау (опись төзү), күләмнәрен ачыклау максаты йөкләнелә. Ул һәм берничә солдат, урман каравылчылары, подьячийлар, геодезистлар Идел, Кама, Зөя, Сура елгалары һәм аларның кушылдыклары буенда үсүче кораб урманнарын барлыйлар, һәрберсенең тасвирламасын язып, кар-

Казан һәм Казан адмиралтействосы. Флот лейтенантлары П.Прончищев һәм П.Чаплин төзегән Идел елгасы атласыннан фрагмент. 1735 ел.

тага төшерәләр. Төп елгалардан 100–200 чакрым ераклыкка кадәр сузылып үскән кораб урманнары барлана. Картада шулай ук киселгән агачларны төяп чыгару өчен билгеләнгән 30 дан артык пристань, аларның зурлыклары билгеләнә.

Идел елгасы ярындагы татар авылы. 1914 ел.

ЛАШМАНЧЫЛАР – КЕМНӘР АЛАР?

Идел буендагы кораб урманнарын әзерләп пристаньнарга чыгару эше 1718 елдан морзаларга, йомышлы татар, чуваш һәм мордваларга йөкләнеп куела. Әлеге авыр хезмәт шул чорлардан ук «лашман эше», ә аны башкаручылар «лашманнар», «лашманчылар» дип атала башлый. Урман кисү гадәттә кыш айларында башкарылып, башта җәяүле лашманнар эшкә барган. Алар юан-юан имән агачларын балта белән чабып яки төпләрен казып, тамырларын чабып аударганнар, ботакларыннан арындырганнар, корабка яраклы өлешләрне әзерләгәннәр. Бу эшләр Казан адмиралтействосының кораб мастерлары, офицерлары тарафыннан тикшерелеп, күзәтеп торылган. Әзер агачларны атлы лашманнар, килеп, чана башларына куеп, пристаньнарга кадәр махсус алдан әзерләнгән юллар (сабан юллары) буйлап тарттырганнар. Бу эш яз җитеп, карлар эреп, юллар йөрмәслек булганчы дәвам иткән.

ИДЕЛ БУРЛАКЛАРЫ УЗГАН ЮЛ

Бурлакчылык, ягъни ләмкә киеп елга көймәләрен агымга каршы тартудан торган яллы хезмәт, дөньяның төрле җирләрендә бик борынгы заманнардан ук билгеле булса да, беркайда да Россиядәге кебек киң таралмаган була. XVIII гасыр–XIX гасырның беренче яртысы – Идел буенда бурлаклар аеруча күп заман. Моның бер сәбәбе – кораб урманнарын Петербург верфьләренә ташуның зарурлыгы. Петербургка агач запасларын билгеләнгән вакытка илтеп җиткерү дәүләтнең мөһим бурычы булганга күрә, җәйге-көзге сезонда ялланып көймә тартучы бурлакларга шактый түләнелгән. Һәр сезонда уннарча мең ир-ат (алар арасында хәерче крестьяннар, исерекләр, тормыш төбенә төшкәннәр, сукбайлар күп була) бурлак булып ялланырга дип, елга пристаньнарына агыла, эш көтеп яр буенда бөтерелә. Агач төялгән көймәләрне бурлаклар ялланып үз иңнәрендә, шулай ук атлар белән тарткан. Бурлакларның яр буйлап үтә торган юллары «сакма» («бечевник») дип аталган. Бурлаклар юлы Иделнең таулы уң як яры буйлап үткән. Кайбер уңайсыз урыннарда гына елганың сул ягына чыгып тартканнар.


Идел балыкчылары. XVIII гасыр. И.Георги рәсеме.

КАЗАННАН – ПЕТЕРБУРГКА

Идел буе кораб урманнары Идел елгасының югары агымында Петр I вакытында тирәнәйтеп казылган Вышний Волочек су юлы системасы аша озын юллар үтеп, Тверца, Мста, Волхов елгалары буенча, Ильмень, Ладога күлләре аша Петербургка таба озатылган. Бу юл озын гына түгел, бик михнәтле дә. Хәзерге сусаклагычлар булмаган заманда Идел елгасының агымы бик көчле, язларын ярларыннан ташып чыгып, зур мәйданнарда тугайларны су баса. Йөзәр өчен дә һич уңайлы булмаган, елганың суднолар үтәрлек фарватеры һәр ел үзгәреп торган, элеккеге юл ком утырып югалган, ә яңасының кайдалыгы су астында күренми торган – бу хәл көймәләрне алып барган лоцманнарга зур уңайсызлыклар тудырган.

Яр буеннан бурлаклар йөри торган юл да бер дә җиңелләрдән булмый – үтәргә авыр сазлыклы урыннар, ерганаклы, таулы урыннар бихисап, Иделгә килеп кушылучы елгаларны да кичәргә кирәк. Казаннан Идел буйлап күтәрелүче көймәләр Рыбинскига кадәр генә бара алган. Зур көймәләр сай елгадан бүтән бара алмаганга, йөкләрне кечерәк көймәләргә күчереп, юлны дәвам иткәннәр. Вышний Волочек турыларында йөкләрне кайчагында тагы да кечерәк көймәләргә бернечә тапкыр күчереп кенә юлны дәвам итеп булган.

Әлеге су юлында урман ташучы көймәләрнең дә еш кына тоткарлануы бу юлны тикшеренүләргә этәргән. 1735 ел башында Казанга Петербургтан флот лейтенантлары Петр Чаплин һәм Петр Прончищев солдатлар һәм геодезистлар белән бергә килеп төшә. Аларга Идел елгасы буйлап кораб урманнарын ташу юлларын тикшереп, кораб урманнары чыгарылучы Зөя, Сура елгаларындагы присьтаннарга кадәр сузылган юлларның барысына да опись ясап, картага төшерү йөкләнелгән була. Бу сәяхәт Идел белән Кама кушылган урыннан алып югарыга таба Казан, Чабаксар, Козьмодемьянск, Сундырь, Кострома, Ярославль, Рыбинск, Углич аша Кимры авылына (хәзерге Тверь өлкәсендәге шәһәр) кадәр бара. Сура һәм Зөя елгаларындагы пристаньнарга кадәрге су юллары җентекләп тикшерелә. Төп игътибар елгаларның фарватерын ачыклауга, көймәләр комга утыра торган урыннарны билгеләүгә, бурлакларның үтә торган юлларыннан маршрутны төгәлләүгә юнәлтелгән була. Шулай ук елга буйларындагы кораб урманнарын барлау дәвам итәлә.

Чаплин белән Прончищев тасвирламасында язылганча, сакма Идел белән Чулман кушылган урыннан алып, югары агымда Иделгә Ока елгасы кушылган җиргә кадәр уң як яр буйлап бара. Сул як яр тәбәнәк, язын тугайлар су астында калып, җәен дә үтә алмаслык хәлдә сазлыклы була. Бу урыннарны агач-куаклар басып китә, су да тирән түгел – суднолар



А.И. Свечинның Казан, Түбән Новгород, Оренбург губерналарындагы кораб урманнары картасы фрагменты. 1765 ел.

комга утыра. Шулай ук озын култыклар күп. Елганың ком яткан сай урыннары башка җирләрендә дә шактый – елга уртасында ком өелеп утрау ясалган урыннар җитәрлек. Елганың төп агым юлы – фарватеры ел саен үзгәреп тору суднолар йөртүне үтә катлауландыра.

Төзегән планнарыннан күренгәнчә, Иделдә Казан янәшәсендә агач-куаклар үсеп утырган өч зур утрау булган. Берсе – Ирихов утравы. Ул Казансу елгасының кушылган җирендә буйга сузылган утрау. Казаннан чыгып, елганың түбәнге агымы буйлап барганда, Югары һәм Түбән Ослан арасында ике зур утрау – Кәҗә һәм Казак (Казачий) утраулары булган. Соңгысында Казан губернасы вице-губернаторы, шул ук вакытта Казан адмиралтействосы обер-комиссары Нефед Кудрявцевның йорты урнашкан.

ТАНЫЛГАН СӘЯХӘТЧЕЛӘР – КАЗАНДА

1735 елда кораб урманнарын ташый торган су юлларын тикшерүче Петр Чаплин була, ул – танылган рус диңгезчесе. Витус Беринг, Алексей Чириковлар белән бергә, 1 нче Камчатка экспедициясендә катнашкан шәхес. Тагын күп кенә танылган кешеләрнең исемнәре Казан һәм Казан адмиралтействосына бәйле. Мәсәлән, 1733 елның мартында диңгезләр гизүче, рус флоты офицеры, капитан-командор Витус Беринг, 2 нче Камчатка экспедициясенә барышлый, Казан аша үтә. Ул биредәге адмиралтейство да азык-төлек юнәтә, Тын океандагы экспедициясенә берничә кораб төзүчене үзе белән ала. Себер һәм Ерак Көнчыгышны тикшерүче Д.Я. Лаптев һәм Х.П. Лаптев (алар исеме белән Лаптевлар диңгезе аталган) 1738 елда Лена елгасын тикшерер өчен чираттагы экспедицияләре вакытында Казанда булалар. Казан адмиралтействосында аларны канат, такелаж, җилкәннәр, балталар, киез итекләр һәм толыплар белән тәэмин итәләр.

ТАРИХИ ДОКУМЕНТЛАР

Идел буенда кораб урманнарын әзерләүдә, урманнарны саклауда күпсанлы кимчелекләр, крестьяннарның шикаятьләре нәтиҗәсендә Сенат Петербургтан Казанга подполковник Александр Свечин җитәкчелегендә тикшерү комиссиясе җибәрә. Свечин комиссия белән 1763 елда Казанга килеп, күп кенә кораб урманнары әзерләнә торган урыннарда, лашманнар яши торган авылларда булып, урындагы хәлләрне тикшерә. Крестьяннарның шикаятьләре буенча тупланган кимчелекләргә 168 пункттан торган документ эшләнә. 49 пунктлы икенче документта лашманнарны авыр хәлгә китерүче сәбәпләр ачыклана, 39 пунктлы өченче рәсми язуда Казан губернасы имән урманнарын саклау һәм арттыру мәсьәләләре күтәрелә. Соңгысында ачыкланган кайбер кимчелекләр турында тулырак мәгълүмат бар. Мәсәлән, имән урманнарын саклаучы вальдмейстерларның башбаштаклыгы чиктән аша – уйдырма сәбәпләр табып, кешеләрне кораб урманы кисүдә гаепләү, булмаган гаепләренә күз йомарга вәгъдә биреп, моның өчен акча сорау гадәти хәл санала. Зыяны чынлыкта күренмәсә дә, «таптыйлар», «имән чикләвекләрен ашыйлар» дип, имән урманнарында йорт хайваннарын (аеруча дуңгызларны) йөртүне тыялар. Хәер, халыкның үзендә дә урманга сакчыл караш булмый. Халык саны арта барган саен, чәчүлек, көтүлек җирләре күбрәк кирәк, шуңа урманнарны төпләп, чәчү җирләрен арттыру XVIII гасырда зур темплар белән алып барыла. Кисәргә тыелган имән агачларының төптән тамырларын чабып, чирәм, балчык белән каплыйлар, аннары агачлар корыгач, бу җирләрдән чәчүлек җирләре ясыйлар. Урманнарда янгыннар еш чыгып тора, беркем дә үз артыннан учагын сүндереп китү турында уйламый. А.И. Свечинга Идел буендагы кораб урманнары картасын элеккеләреннән тулырак итеп яңадан ясау бурычы да бирелә. 1765 елгы картада Казан, Түбән Новгород, Оренбург губерналарындагы кораб урманнары аерып күрсәтелә, кыйммәтле агачлар яхшырак үссен өчен, биредәге урманнар вак агач-куаклардан чистартылган, имәннәрнең аскы ботаклары киселгән була.

Сугыш чоры балалары... Алар күргән нужа, газапны кәгазь битенә генә язып бетереп булмыйдыр. Шулай да...

Бөек Җиңүнең 75 еллыгын каршыларга әзерләнгәндә, без аларны барларга, бер мәлгә булса да ул елларны күз алдына китерергә тырыштык. Юк, бу өлкәннәр өчен генә түгел, бу, иң беренче чиратта, безнең үзебез өчен мөһим.

Алар кичергән фаҗигаләр шәүләсендә бүгенге тормышыбызның кадерен белү, шөкер итү өчен кирәк...



«ТУГАН ҖИРДӘ ҮСКӘН АРЫШ ИПИЕН БҮТӘН АШАМАБЫЗ ДИГӘН ИДЕК...»

Автор: Руфия Фазылова

Бәләкәй чакта, сугыш турында киноларны карагач, мин ул хәлләрне чынлыкта була алмый, дип уйлый идем. Янәсе, актерлар гына шулай уйный. Бары үсә төшеп, китаплар укыгач, ул дәһшәтле көннәрнең шаһиты булган өлкән яшьтәге кешеләр белән аралашкач кына, илебез халкының бу хәлләрне чын-чынлап кичерүен аңладым.

Сарман районының Карашай-Саклау авылында яшәүче Мәрьям әби Гарипова сөйләгәннәрне тыңлагач, бу хәлләргә тагын бер мәртәбә шаккатасың... Аның язмышы сугыш турындагы кинолента кебек... тетрәндергеч.

Фото: Алёна Кутыркина

Фото «Сарман» район газетасы архивыннан алынды

«БЕТКӘ ТҮЗЕП БУЛМЫЙ...»

Мәрьям әбигә 95 яшь. Бүген ул туган авылында ялгызы яши. Әнисе аны соңлап, 50 яшендә генә таба. Тик кызга әни кочагында иркәләнергә озак насыйп булмый – сигез яшендә ул әнисеннән ятим кала. Аларны әтиләре тәрбияли. Сигез баладан хәзер ул гына исән.

Сугыш башланганда кызга унҗиде яшь була. Ни кызганыч, яшьлегенең ямен, матурлыгын күрми кала ул. Буй җитүгә, башта җигелеп колхоз йөген тарта. Үткен кызга эшне аеруча күп бирәләр. Ә 1943 елда, районның берничә кызын сайлап, Сталинградка – хәрби заводка эшкә җибәрәләр. Шулар арасында Мәрьям дә була.

– И, апаем, әле менә яңа гына телевизордан Сталинградта булган хәлләрне күрсәттеләр, – диде Мәрьям әби. – Шуны күз яшьләре белән карап утырдым. Күпме яшь кешеләр әрәм булды бит... Авылдан без 1943 елның 13 июлендә чыгып киттек. Куйбышевка кадәр пассажир поездында алып бардылар. Аннан товар поездына күчерделәр. Эчәсе килә, ашарга юк. «Тизрәк заводка барып җитсәк, тамагыбыз булса да туяр иде», – дип, кызлар белән үзара сөйләшеп бардык. Тик, Сталинградка җитәргә егерме биш чакрым калгач, безне кире бордылар. Бик каты сугыш бара, керергә ярамый, диделәр. Шуннан безне, хәрби машиналарга утыртып, урман эченә алып киттеләр. Палаткалар корып яши башладык. «Кызларны кайтарып җибәрмәскә, сугыш тынса, заводка алып барырга», – дигән боерык булган. Көн эссе. Йөзләп хатын-кыз. Көндез җиләк-мазар эзләп урман буенча таралабыз. Самолет тавышы ишетелсә, палаткаларга таба йөгерәбез. Дошман самолеты булырга мөмкин бит. Андый вакытта палаткалардан чыкмый ятабыз. Көнгә бер тапкыр кызлар белән җыелышып, ипи белән үлән чәе эчәбез. Әле дә ярый җәй булган дим, катып та үләр идек. Бер ай тирәсе шулай яшәгәч, барыбызны да бет басты, тиф таралды. Алма кебек кызлар берәм-берәм егылып үлә башлады. Ике райондаш кызым да күз алдымда җан бирде...

Янәшәдә әҗәл йөргәндә, унтугыз яшьлек кыз нәрсә уйлый? Фәлсәфи сорау, шулай бит. Ә Мәрьям апа моның җавабын әле дә төгәл хәтерли.

– Бермәл үзеңнең үләсеңне аңлап, шуңа разый буласың икән, – ди Мәрьям әби. – Бөтен кеше кырылганда, үлемнән курыкмый башлыйсың. Әллә ачлык, хәлсезлек шулай итәме, белмим. Көнелдә зур бер үкенеч барлыкка килә: «Авылда яңа өлгергән алмаларны ашый алмадым», – дип уйладым мин. Аннан бигрәк әтине кызгану – үзе ашамыйча, авызыннан өзеп каптырып, безне үстерде, ә без шулай бер-бер артлы үлеп бетәрбезме? Ул минем кайда күмелгәнемне дә белмәс инде... Ачык һавага карап, менә шулай уйлап ятасың. Йоклап та булмый бит, беткә түзә торган түгел. Апаем, ачлыкка чыдап була ул, кием бетенә – булмый...

Палаткаларда яшәүче хатын-кызларның күпләп үлүе турындагы хәбәр югарыдагыларга барып ирешә. Август урталары була ул. Төнге сәгать икедә, берничә солдат килеп, кызларны үзләре белән алып китә.

– Кичтән безгә җыенып торырга куштылар, – ди Мәрьям әби. – Әмма кая алып барасыларын әйтмәделәр. Солдатлар безне су ярына алып чыкты. Пароходка төялдек тә офыкка таба йөзеп киттек. Пароходның ничек кара төтен чыгарып, үкереп барганы әле дә күз алдымда.

Заводка эшкә дип барган кызлар урманнан әнә шулай котыла. Ә вафат булган дистәләгән яшь кызның гәүдәсе мәңгегә шунда кала. Кызлар төялгән пароход Куйбышевка җиткәч туктый.

– Юлда кайбер кызларның хәле бик авырайды, – ди Мәрьям әби. – Тиф бик зәхмәтле чир ул. Паромга туктап, безне төшерделәр, мунча билеты булмаган кешеләрне яңадан пароходка утыртмыйбыз, диделәр. Шәһәр буйлап мунча эзләп киттек. Таптык, тик якын бара торган түгел – мунчага өч көнлек чират. Чыдар хәл юк, үтереп ашыйсы, эчәсе килә. Тиф иярткән кызлар барган җирдән үк егылып китә. Кире паромга кайттык. Пароходка кертмиләр, дезинфекция бара. Ерак түгел ашханә барлыгын белдек, тик безне анда ашатмадылар. Шулай да кызлар белән ашханә буена тезелешеп утырдык. Азрак вакыт узгач, пешекчеләр безгә су чыгарып бирде. Аннан чиләкләргә тутырылган кәбестә яфрагы чыгардылар. Аларны ташларга әзерләп куйганнар икән. Ул кәбестә яфрагының тәмлелекләре, ашап туя торган түгел иде! Ике тәүлек паромда яшәгәннән соң, безгә пароходка утырырга куштылар. Ни хикмәт, мунча билеты да сорап тормадылар.

ТУГАН ЯККА КАЙТУ

Әнә шулай үлем белән көрәшә-көрәшә, безнең якның бер төркем кызы туган җирләренә кайтып төшә. Дөрес, пароход аларны Кама ярына – Чаллыга кадәр генә алып кайта. Аннан – кем ничек булдыра, шулай өйләренә таралыша.

– Чаллы безгә әллә ни ерак түгел – турыдан егерме чакрымлап кына, – ди Мәрьям әби. – Ул чакта машинар юк бит, ат заманы. Мин үзебезнең авыл кызы Нәгыймә белән идем. Паромнан юлга чыкканчы, тау менәсе бар. Башка вакыт булса, ул тауны уйлап та бирмәс идек, ә монда икебез дә ач, хәлсез. Тауны көч-хәл белән мендек. Егерме чакрымны җәяү кайтыр чама юк, аякларны көчкә сөйрибез. Нәгыймә белән юл буена чыгып утырдык. Карасак, бер-бер артлы иярләнгән ике ат килә, иген төягәннәр.

– Абый, зинһар өчен, арбагызга безне дә алыгыз. Кайтып җитәргә чамабыз юк, юл буенда үләбез, – дидек.

Абзый безне күреп шаккатты:

– Нәрсә булды сезгә? Әсирлектән качтыгызмы әллә? – диде.

Без барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирдек. Арбасына алды. Ул безне бик кызганды. Куеныннан алып бер түгәрәк ипи чыгарды. Иптәш кызым белән шуны икебезгә урталай бүлеп ашадык. Үзебез ашыйбыз, үзебез: «Туган җирдә үскән арыш ипиен бүтән ашамабыз дигән идек», – дип елашабыз.

Ат иярләгән ир мәрхәмәтле булып чыга. Кызларны авыл башына кадәр кайтарып куя. Алай гына да түгел, хәтта аларга бирәр уч иген дә бирә. (Гаҗәп бит, ул чакта, бер уч иген өчен ул иратны утыртып куярга да күп сорама-

ганнар. Тик кызларны кызгану хисе, күрәсең, куркуны да җиңгән!) Арбадан төшеп калган кызлар, туры өйләренә түгел, авыл башындагы чокырга таба йөгерә.

– Кеше күзенә күренергә курыктык, – ди Мәрьям әби. – Күзләр эчкә баткан, гәүдә сөякка калган, юынмаган, бет баскан... Ничек итеп оялмыйча урам буйлап атлыйсың, ди?! Өйгә караңгы төшкәч кенә кайтып кердек. Әти аптыраудан бер мәлгә сүзсез калды. Аннан сабый бала кебек елап җибәрде. Безнең кешелектән чыгып кайту хәбәре тиз арада бөтен авылга таралды. Авылдашлар хәл белергә килә башлады. Рәхмәт яугырлары, нык ярдәм иттеләр. Ул чагында барысы да ач, шулай булса да, күрше-күлән берәр тәмле ризык пешерсә, миңа да алып керделәр. Әни булмагач, бигрәк тә кызганганнардыр. Хәер, әти бик яхшы кеше иде. Авызыннан беркайчан аракы, тәмәке исе килмәде. Хәленнән килгәнче ул да тәрбияләде. Көн аралаш мунча ягып кертте, беттән арындырды. Сыер савып, көн саен җылы сөт эчертте...

Ниндидер могҗиза белән Мәрьям әбигә тиф иярми. Ә менә аның белән булган авылдашы Нәгыймә, туган авылына кайтып, бер генә атна яши – бакыйлыкка күчә. Соңрак тагын хәбәрләр килеп ирешә – заводка эшкә барган бүтән кызлар да, өйләренә кайткач, озак яшәмәгән... Шул кызлар белән бергә йоклап, бергә ашап яшәгән Мәрьямгә ничек чир йокмаган – могҗиза!

– Аллаһы Тәгалә озын гомер биргән булган миңа, бөтен сәбәп шунда дип уйлыйм, – ди Мәрьям әби, ул хәлләргә нәтиҗә ясап.

«КАЕНАНАМНЫ РӘНҖЕТМӘСӘҢ, КИЯҮГӘ БАРАМ»

Яшь организм тиз тернәкләнә, санаулы көннәрдән соң, кыз аякка баса. Яңадан колхоз эшенә чыга. 1948 елда үзләренең авылы егете Фаилгә кияүгә чыга. Тик аның белән дүрт кенә ел яшәп калалар – яшь ир, үпкәсе шешеп, вафат була. Кечкенә улы белән Мәрьям тол кала. Каенанасы белән көн итә башлыйлар. Тагын кияүгә чыгармын дигән нияте булмаса да, парлы тормыш насыйп була аңа.

– Алтмышынчы елларда авылга ут кертергә ирләр килде, – дип искә ала Мәрьям әби. – Араларында Гариф исемлесе дә бар иде. Чистай мишәре, яп-яшь, озын буйлы, бик чибәр егет. Авылда бит хатын-кызлар күп, тик ул гел минем тирәдә чуалды. Мин әле аны-моны уйламыйм, дусларча сөйләшәдер, дим. Ни дисәң дә, яшь аермабыз зур, мин – 1924 елгы, ул 1940 елда туган. Шуннан берсендә бу миңа: «Синең белән бергә буласым килә», – ди.

Тугыз яшьлек улымны какмасаң, әнкәйне рәнҗетмәсәң, яшәрбез, дидем. Менә шулай бер уйламаган җирдән ир хатыны булып куйдым. Улыма карата да, әнкәйгә дә бик йомшак булды. Әнкәй белән аеруча тату иделәр. Гариф үзе акыллы, зирәк кеше иде шул. 2011 елда җирләдем үзен. Елга якын урын өстендә ятты. Анда да бер авырлыгын да күрмәдем. Авыр туфрагы җиңел булсын!

– Алар бер-берсенең авызына гына карап тордылар, – дип сүзгә кушылды Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы Вероника Хөсниева. – Гариф абый килгән кеше булса да, авылда зур абруй казанды. Белемле, сабыр иде. Гомер буе тырышып эшләде. Мәрьям апаның ирдән бәхете булды аның, монысы бәхәссез.

Ир белән хатынның уртак балалары булмаган. Гариф абый ракеталар частендә хезмәт иткән, шунда нурланыш алган.

– Гарифка әти булмаска кушканнар, – диде Мәрьям әби. – Минем белән кавышырга теләве дә шуның белән бәйле булгандыр. Баласы булган хатын эзләгән ул. «Бер күргәч яраттым», – дип тә әйтә иде инде үзе. Хәрби хезмәте турында бик сөйләшергә яратмады ул. Нәкыйпне үз улы кебек тәрбияләде.

Мәрьям әби уңган хатын булган. Колхозда да хезмәт куйган, өйдә маллар да асраганнар, умарта да тотканнар. Илле яшендә әле колхоз умарталыгына эшкә кергән. Ялгызы йөздән артык оя корт караган. Ул чакларны искә алып, әби болай диде:

– Колхозның умарталыгы әрәмәдә, бик матур бура өйләрдә иде. Минем белән корт карарга Гариф та бара. Пенсиягә чыккач та, алты ел эшләттеләр. «Картайдым, кеше табыгыз», – дип, каткат әйтә килгәч кенә, эштән җибәрделәр. Әле бит колхоз умартасыннан тыш өйдә дә кортлар күп иде.

...Менә шундый язмыш. Мәрьям әби, күпме михнәт күрсә дә, тормышны яратудан, аннан тәм табудан туймаган. Яшәү дәрте, кешеләрне яратуы – коточкыч авыр хәлләрдә дә аңа көч биргән. Бүген дә шул көч яшәтә аны! Мәрьям әби кебек көчле рухлы кызлар, хатыннар тылның терәге, таянычы булган, җиңүне якынайтырга булышкан.

Мәрьям Гариповны 95 яшьлек юбилее белән котларга туганнары-якыннары җыелган, шулай ук Сарман районы җитәкчелеге вәкилләре дә килгән. (Фотода: уңнан беренче – улы Нәкыйп.)

75 ПОБЕДА! 1945–2020

СОЛДАТ ГӘРӘЕВНЕҢ ҖИДЕНЧЕ СУГЫШЫ

«1941 елда Мәскәү янында хәлиткеч сугышлар барганда бер сапер юл баганасына: «До Берлина – 2000 км» дип язып куя. Тирән карга чума-чума янәшә атлаган җәяүле солдат болай дип өсти: «...Ничего, дойдем!» («ничего» урынына сүзнең катырагы әйтелә, әлбәттә)». Фронтта булган әлеге хәлне ул бик еш искә төшерә. Шул ук вакытта һәрвакыт болай дип тә өстәп куя: «Мондый солдатлар һәм аларны тудырган һәм үстергән халык барысын җиңә, ул җиңелә алмый!» Алты сугышта катнашкан солдат Мәхмүт Гәрәев Җиңү теориясен гамәлдә үзләштерә.

Автор:
Әскәр Сабиров

Үзенең алтынчы сугышына, Әфганстанга, генерал-полковник Мәхмүт Гәрәев 1989 елның февралендә килеп төшә – совет гаскәрләрен чыгарырга бер атна вакыт калганда. Вазыйфасы – президент Наҗибулланы сакларга куелган безнең хәрби-оператив төркем белән җитәкчелек итү. Башың себер китәрлек вазыйфа, дөресен генә әйткәндә: Көнбатыш хәрби аналитиклары барысын да инде исәпләп чыгарган була – Әфганстаннан безнең күпсанлы контингентны чыгаруга, Нәҗибулла хакимияте ике-өч атна эчендә җимерелеп төшәчәк. Ә менә совет аналитикларының исәпләрен тарих никтер теркәп калдырмаган. Әмма шунысы билгеле: хәрби генераллар арасыннан икәү, Кабулга барырга кирәк булачак, дигән мәсьәлә кабыргасы белән килеп басуга, кинәт кенә, чирләп, госпитальгә кереп ята. Хәтәрдән ераграк торыр өчен, күрәсең. Гәрәев, 65 яшьтә булса да, чиргә сабышып, кеше көлдереп тормый: хәрби әмерләр кире кагылыр өчен бирелми чөнки.

СССРның оборона министры Дмитрий Язов, Әфганстанга командировкага җибәрелгән офицерны кабул иткәндә, сак кына сорап та куя:

– Куркытмыймы?

– Миңа инде куркырга соң, – дип җавап бирә Гәрәев. – 1941 елда Ташкент хәрби училищесын тәмамлап чыккан безнең төркемнән 26 кеше генә әйләнеп кайтты. 119 дан – 26 сы. Миңа язмыш сугыштан соң болай да 40 ел гомер бүләк итте, ризасызлык белдерү гөнаһ булыр иде...

КӨЧСЕЗ КАЛГАНДА КУРКЫНЫЧ

Теге чакта, беренче сугышта, иң куркынычы бомбага тотулар булган аның өчен. Бу турыда 1942 елда аларның батальонына килгән хәрби корреспондентка сөйли ул. Кайдадыр Медынь тирәсендә, Көнбатыш фронтта. Батальонны яңа гына алдагы сызыктан чыгарганнар, алар урман аланында окоплар казу белән мәшгуль чакка туры килә корреспондент. Хәбәрче төпченә, барысын да беләсе килә, куркыныч янаганда, кемнәрнең нәрсә кичерүен ачыкларга тырышып аптырата. Комбат Гәрәев аңа үз куркулары мисалында аңлатып бирә: һөҗүмгә барганда бер нәрсәне беләсең – йә син дошманыңнан өстен чыгасың, йә ул сине юк итә. Артиллерия снаряды төшкән бүрәнкәгә төшеп сеңгән очракта исән калырга мөмкинсең: ихтималлык теориясе буенча икенче снаряд анда төшмәскә тиеш. Әмма менә өстән бомбага тотканда, берничек тә котылу мөмкинлегең юк, көчсезлектән нишләргә белмисең...

1941 елның ноябрендә беренче мәртәбә бомба астында калганнан соң, догалар укый башлавы турында командир Гәрәев корреспондентка әйтеп тормый, билгеле. Комсомолларча ул да динне искелек калдыгы дип саный. Әмма еллар узгач, әлеге эпизодны хәтеренә төшереп, аңлатырга кирәк таба: «Сугыш – коточкыч нәрсә. Адәм баласы, язмышы белән бергә-бер калгач, яклау эзли башлый. Әгәр син үзеңнән өстен һәм сине яклый, саклый ала торган көч барына ышанасың икән, иң өметсез мизгелләрдә ул көч синең ягыңдадыр кебек тоела. Һәм монда синең нинди дин вәкиле булуың инде әллә ни зур әһәмияткә ия түгел».

Батальонга килгән хәбәрченең фамилиясе Симонов булып чыга. Аларның хәрби юллары әле бер генә мәртәбә түгел, күп тапкырлар кисешәчәк, хәтта дуслашып та китәчәкләр. Инде беренче очрашудан соң күп сулар аккач, 1974 елда,

Фотолар Гәрәевләрнең гаилә архивыннан

язучы Константин Симонов фронтташ иптәшенә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә: хәрби архивларга кертмиләр. Генштабның хәрби-фәнни идарәсе башлыгы Мәхмүт Гәрәев рөхсәт боерыгы бирә. Моның өчен аңа партиянең баш идеологы, КПСС ҮК секретаре Михаил Сусловның хәерхаһлыгын алырга туры килә.

ИКЕ РӘТКӘ ТЕЗЕЛЕП БАС!

– Инде совет гаскәрләре чыгарылып бетерелгәч, монда килергә ничек гайрәтегез җитте? Без ничек, кем ярдәмендә каршы тора алырбыз икән соң? Әфганстан Хәрби көчләре Югары башкомандующие, ил президенты Нәҗибулла Кабулда үзенең баш хәрби киңәшчесен әнә шулай каршы ала. Һәм аның сүзләрендә аптырау катыш ирония дә яңгырый.

Гәрәев тә сүзгә төшеп калганнардан түгел: «Рус армиясендә борын-борыннан бер мәкаль йөри: «Яхшы командир бер татарны да ике рәткә тезеп бастыра ала». Мөселманнар буларак, бергәләп тырышып карыйк, бәлки, сезнең рәтләрне дә икегә тезә алырбыз. Соңгы чиккә, соңгы мөмкинлеккә кадәр тырышырга гына кирәк...»

Аңа вәгъдәсен шактый катлаулы шартларда үтәргә туры килә. Әфган армиясендә, Гәрәев соңыннан искә алганча, төшенкелек хөкем сөрә. Мөҗәһитләрнең һөҗүмнәре генә түгел, Әфганстан халык-демократик партиясенең үзендәге эчке каршылыклар, низаглар, оешканлыкның бик түбән дәрәҗәдә булуы да җимерә армиянең умыртка баганасын. Боларны күргәч, тәҗрибәле Гәрәев бурычларны төгәл билгеләде: гаскәрләрдә эшне активлаштырырга, төшенкелек белән көрәшергә һәм аннан котылырга. Союзникка исә шуны сеңдерү зарур: оппозиция һөҗүменә каршы торып була. Һәм монда бер хәрби белем генә җитми, дипломатия юнәлешендә дә могҗизалар тудырырга кирәк. Гәрчә 1989 елда Мәскәүдә Әфганстан кайгысы булмаса да – Союз менә җимерәләм, менә таркалам, дип тора...

Командировкасына ел ярым дигәндә, Мәхмүт Гәрәевне Әфганстаннан чакыртып алалар. Өенә ул инде армия генералы дәрәҗәсендә кайтып төшә. Совет армиясе чыгарылганнан соң, Көнбатыштагылар фаразынча, күп дигәндә, 3 атна гомер калган Нәҗибулла хакимияте әле Гәрәевтән соң да яшәп кала. Пакыстандагы газеталарның берсе бу хакта болай дип язалар: «Руслар Әфганстаннан үзләренең йөз мең солдатын чыгардылар, әмма бер татарны керттеләр...»

МӘСКӘҮ ЯНЫ ОКОПЛАРЫНДА

18 яшьлек кече лейтенант Гәрәев беренче тапкыр яуга 1941 елның ноябрендә керә. Немецлар башкалага бик якын килгән вакыт: Мәскәү янындагы Чернышевский казармаларыннан фронтка кадәр ара шактый кыска. Фронт сызыгына кайда машинага утырып, кайда җәяү барып җитәргә мөмкин. Гәрәев взвод кабул итеп алырга тиеш була, әмма өлгерми кала. «Батальонга килеп төштем. Каршыма кулы бәйләүле старшина килә. Яралы. «Батальон командиры кайда?» – дип сорыйм. «Юк», – ди ул. «Ә офицерлардан кемнәр бар?» – дим. «Беркем юк, беркем дә калмады», – ди. Миңа батальон белән командалык итәргә туры килде, гәрчә штат буенча комбат – подполковник, бер дә булмаса майор дәрәҗәсендә булырга тиеш булса да. Ике тәүлектән соң батальон командиры итеп бер капитанны җибәрделәр. Миңа рота белән җитәкчелек итү йөкләнде...»

Гәрәев өчен сугышның 1942 елның августында ук Калуга өлкәсендә тәмамлану мөмкинлеге була. Җәйге һөҗүмнәр вакытында ул аерым рота белән командалык итә. Атакага күтәрелгәндә яралана. Кулын тиз генә бәйли дә янә яуга ыргыла. Яңа командир килеп җиткәнче, ике көн яу кырында була. Ул арада кулы кара янып чыга. Медсанбаттагы хирурглар озак сөйләшеп тормый, кисәргә дигән карарга килә. Шунда олы яшьтәге бер санитарка ярдәмгә килә: егетне эшелон белән бергә Рязаньга җибәрттерә. Андагы госпитальдә Гәрәевнең кулын саклап калалар.

Икенче мәртәбә аны Витебск янында яралыйлар. Тиз арада дәваланып, кабат фронтка китә ул...

1944 елда Мәхмүт Гәрәев батальоны Молодечноны (Мәхмүт Гәрәев бу шәһәрнең почетлы гражданины – **ред.иск.**) беренче булып керә. «Узып барышлый», Белоруссия операциясе вакытында, аның солдатлары Ворошилов исемендәге партизан отрядында сугышкан берничә мең кешене коткара. Тылларын чистартырга дип, немецлар партизаннарга каршы берничә дивизиясен ташлый. Отряд урмандагы күл буена яшеренә, әмма аларны бөтен яктан уратып алалар. Азык-төлексез калган сугышчылар һәлак булырга дучар ителә. Гәрәев подразделениесенең юлсыз шартларда көтелмәгән һәм кискен марш-бросок ясавы нәтиҗәсендә немецларның чылбыры өзелә, әсирлеккә һәм үлемгә мәҗбүр ителгән үзебезнекеләрне коткару мөмкинлеге ачыла...

«Сугышның буеннан-буена, 1944 елның уртасына кадәр, мин иң түбән звеноларда сугыштым, – дип сөйли бер әңгәмәсендә Мәхмүт Гәрәев. – Рота командиры, батальон штабы башлыгы, комбат, аннан соң – бригада звеносында оператив бүлек башлыгы. Җиңел вазыйфалар булганын хәтерләмим. Һәрвакыт – сугышта, окопта. Сугыштагы һәр көнне без бер генә уй белән кичә идек: исән калырбызмы-юкмы?»

50 елга сузылган армия хезмәте дәвамында ул СССР Генштабы башлыгы урынбасары дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Бу үсеш – Садовое кольцо чигендә үз җиңүләрен «әвәләгән» штаб офицерларының карьерасы белән чагыштырып та булмый торган батырлык елъязмасы. Сугыш фәнен Мәхмүт Гәрәев Мәскәү яны окопларында, Ржев сазлыкларында, Кенигсберг өчен каты бәрелешләрдә үзләштерә. Инде аннан соң гына – академияләрдә...

Әфганстанда командировкада.

1945 елның 1 мае.

бигрәк тә. «Бу инде историография түгел, статистикага да берлинди катнашы юк монын, бу – гап-гади пычрак, җирәнгеч сәясәт», – дия иде ул. «Кайберәүләрнең югалтуларны күбрәк булуын исбат итәсе килә, шул рәвешле алар Җиңүнең бәясен киметергә тырыша, – ди Мәхмүт Гәрәев. – Бу тема – бик четерекле һәм яраларга тия торган, фронтовиклар өчен – бигрәк тә. Бу мәсьәләдә ярыш юлына басу – коточкыч хәл».

Мәхмүт Гәрәев югалтуларны раслау комиссиясенең рәисе булып тора һәм аның иманы камил: «Югалтулар турындагы хакыйкатьне кешеләргә җиткерү – кирәк эш. Моны эшләмәсәк, без сугышның нәтиҗәләрен билгели алмыйбыз, җиңүнең нәрсә бәрабәренә яулап алынуын да бәяләү мөмкин түгел». Нәкъ менә Мәхмүт Гәрәевкә саннарның халыкка барып ирешүе өчен рәхмәтле булырга тиешбез: Советлар Союзының Бөек Ватан сугышындагы югалтулары – 26, 5 миллион кеше гомере. Шуларның 18 миллионын гади халык, фашистлар яулап алган территорияләрдәге явызлыкларның корбаннары тәшкил итә...

Алай гына да түгел, Мәхмүт Гәрәев, замана сәясәтенә яраклашырга тырышып, беркайчан да үз фикереннән баш тартмады. Бөек Ватан сугышында Сталинның роле нинди булган, дигән сорауга да җавабы кискен һәм анык аның: «Моңа хак җавапны тарихны өйрәнеп әйтергә мөмкин. Бөек Ватан сугышы тарихын гына да түгел. 1812 елдагы сугыштан соң, Россия барлык сугышларда да диярлек җиңелеп килә – Кырым сугышы булсынмы ул, Рус-япон сугышымы, Беренче бөтендөнья сугышымы. Минем фикеремчә, моның төп сәбәбе – хакимият башында торучыда, димәк, армия белән күп еллар дәвамында тәҗрибәле, яхшы җитәкчеләр идарә итмәгән, дигән сүз. Сугыш шартларында идарә тиешле дәрәҗәдә дөрес оештырылмаса, бер генә халык та җиңүгә ирешә алмый, алай гына да түгел, хәтта тиешле юнәлеш тә таба алмаска мөмкин...» Гәрәев бер генә мәртәбә дә Сталинны тиран булмаган дип расламый, шуңа да карамастан, үзенең әлеге «хөрлеге» өчен әллә никадәр тәнкыйть утына тотыла. Шулай да фактлар белән беркетелгән фикереннән баш тартмый.

– Бөек Ватан сугышы хакындагы хакыйкатьне әле киләчәктә әллә ничә буын галимнәр һәм язучылар ваемлар, дип уйлыйм. Ә спекуляцияләргә килсәк, яңалары табылып торачак, – ди ул. – Чөнки конъюнктура, әдәп-әхлак кагыйдәләре үзгәреп тора, мәдәният... Чөнки бу сугыш – кешелек тарихындагы яхшылык белән явызлык көрәшенең иң югары концентрациядәге чагылышы иде...

Ул Бөек Җиңүнең 75 еллыгына аз гына яшәп җитмәде. Ләкин бүгенге көндә бик кирәкле китаплары – югары дәрәҗәдәге төгәл коралы калды. Димәк, сугышчы Мәхмүт Гәрәев әле һаман да безнең сафларда. Ул һаман да көрәшүен дәвам итә.

КАЙСЫ ХАКЛЫ?

1945 елның 9 маен майор Гәрәев Ерак Көнчыгышта хәрби эшелонда каршылый. Японияне җиңгәннән соң – Кытай, анда Мәхмүт Гәрәев Халык-азатлык армиясен төзергә ярдәм итә. Алга таба инде – Сүрия вакыйгалары, Мисыр, җитмешенче елларда ул безнең хәрби киңәшченең штаб башлыгы вазыйфасын башкара...

Хәрби фәннәр докторы Мәхмүт Гәрәев белән профессиональлектә күпләр ярыша алганмы? Ул үзе, бу сорауны биргәндә, тормышындагы бер вакыйганы искә алып сөйләргә ярата. Бу хәл аның яшь чагында, хәрби хезмәтенең башында була.

«Рота белән тар гына юлдан барабыз, як-ягыбызда – кыр. Каршыга сугышның ачысын да, төчесен дә татыган тәҗрибәле сержант килә, медсанбатка барышы. Минем яшь икәнемне күрептер инде, болай ди: «Әй, лейтенант, – ди, – син нәрсә, нишләп ротаңны колонналап алып барасың? Бүлгәләргә кирәк!» Мин бүлдем: бер рәтне – уңга, икенчесен сулга куйдым. Алга таба юл тотабыз. Каршыга – тагын бер сержант. Анысы да дәшми генә уза алмады: «Син нәрсә, лейтенант, солдатларыңны минага эләктереп, күккә очырырга телисеңме? Колоннага тез дә үзләрен, юлның кыл уртасыннан алып бар!» Тездем, алып киттем... Аннан соң, күп гомерләр үтте, мин ике академия тәмамларга өлгердем, әмма ике киңәшченең кайсы хаклы булуына тәки төшенә алмадым», – дип, көлеп, сүзен тәмамлый Мәхмүт Гәрәев.

Хәрби тарих белән кызыксыну – монысы да аның хәрби карьерасының аерылгысыз бер өлеше. Кайбер батырлыклар турында вакытында белүебез өчен без нәкъ менә аңа бурычлы һәм рәхмәтле: майор Петр Гаврилов һәм Брест крепостен яклаучылар турында, әйтик. Сугыштан соң берничә ел узгач, Гәрәев Брест крепостена дивизия полкының штаб башлыгы булып билгеләнә. Озакламый әлеге дивизиянең командиры вазыйфасын йөклиләр аңарга. Сугышчылар чәрдәкләнеп беткән кирпечләрне актарганда коралларга, диварлардагы язуларга юлыгалар. Крепостьне саклаучыларның язуларына. Гәрәев бу хакта «Огонёк» журналына хәбәр итә. Шуннан соң Брестка язучы Сергей Смирнов килеп төшә...

ЯХШЫЛЫК БЕЛӘН ЯВЫЗЛЫК КӨРӘШЕ

Галим һәм фронтовик Мәхмүт Гәрәев язган соңгы китапларның берсе – «Сражения на военно-историческом фронте» дип атала. Бу китап, әлбәттә, сугыш турында. Гәрәевнең җиденче, соңгы көннәренәчә дәвам иткән сугышы турында. Дөреслек, хакыйкать өчен сугыш. Ялганга һәм фальсификациягә каршы сугыш ул. Җиңүнең мәгънәсен һәм дәрәҗәсен киметергә, төшерергә тырышучыларга каршы сугыш.

Бу җиденче сугышны Мәхмүт Гәрәев һәм Хәрби фәннәр академиясе (ул – Академиянең алыштыргысыз президенты) соңгы дистә еллар дәвамында алып барды. Аның без искә алган китабы да, күпсанлы башка басмалары да – тарихны яңабаштан үз җайларына язарга омтылучыларга каршы ачылган утка тиң. Ул бу фальсификаторларга бернинди мөмкинлек тә калдырмый: фактлар, саннар, аргументлар – Гәрәевнең коралына каршы корал юк җир йөзендә. Чөнки ул барысын да үз язмышы һәм йөрәгә аша кичергән. Моннан тыш – җентекләп туплаган, өйрәнгән, чагыштырган, ваемлаган.

Ул һәр сан артында кеше гомере торганын бик яхшы аңлый – яу кырында ятып калганнар күз алдында торганга, мөгаен. Шуңа да бәхәсләр вакытында аның бер генә карышка да компромисска бармавы аңлашыла. Сүз югалтулар, саннарны алыштырулар турында булса –

Фото РФ Президенты сайтыннан алынды

Җиңү парады. 2015 ел.

ДОСЬЕ

Мәхмүт Әхмәт улы Гәрәев. 1923 елның 23 июлендә туа. Армия генералы, Бөек Ватан сугышында, Япония белән сугышта, тагын 4 сугышта һәм локаль конфликтларны җайга салу операцияләрендә катнаша, шул исәптән – Әфганстандагы вакыйгаларда да. Хәрби фәннәр һәм тарих фәннәре докторы. 1995 елдан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр – Хәрби фәннәр академиясе президенты. 250 дән артык фәнни һәм публицистик хезмәт авторы. Алар арасында мондыйлар бар: «Хәрби фән», «Әгәр иртәгә сугыш булса», «Сугышның бәхәсле сәхифәләре», «Маршал Жуков. Гаскәр белән идарә итү сәнгатенең уникальлеге һәм бөеклеге», «Бөек Җиңү полководецлары һәм хәрби мирас» һ.б. Ленин ордены, дүрт мәртәбә Сугышчан Кызыл Байрак ордены, Александр Невский ордены һ.б. хәрби орденнар, медальләр иясе. 2019 елның 27 декабрендә Мытищидагы Федераль хәрби-мемориаль зиратта җирләнде.

«ТАТАРСТАН» журналы өчен МАХСУС

АЛЕКСАНДР ДЕВЯТАЕВНЫҢ КИТАП КИШТӘСЕ

Үзенең атаклы атасы – Советлар Союзы Герое Михаил Девятаев турында өч китап чыгарганнан соң, медицина фәннәре докторы Александр Девятаев галимнәргә хас җентеклелек белән сугыш тарихын, илебез тарихын, Казан тарихын өйрәнүен дәвам итә. Без исә китап сөюче әлеге шәхеснең китап киштәсенә күз салабыз һәм анда шактый кызыклы мәгълүматка тап булабыз.



1. ЯШЬ ВАКЫТЫМДА ЙОГЫНТЫ ЯСАГАН ӘСӘРЛӘР…

Мин бәхетле идем – әтигә гел китап бүләк иттеләр. Аларның бик күбесен инде китапханәгә тапшырдык. Таныш китапханәгә, анда мин нинди генә китапны сорасам да, һәрвакыт табып бирәләр иде. Тагын күршебездә бик кызыклы кеше яшәде. Аның да шактый бай китапханәсе бар иде, ә анда – җитди әсәрләр тупланмасы. Миңа ул китапларны укырга рөхсәт ителде. Шуңа күрә язучыларны җентекләп өйрәнергә җаем күп булды. Джек Лондонны укый башлыйм икән, димәк, төпле итеп өйрәнәм! Кулыма Лион Фейхтвангер китабы эләгә икән, аның артыннан башкаларны да укый башлыйм. Аның яһүдләр сугышына багышланган «Иосиф Флавий» дип аталган өч томлыгы миңа шундый көчле йогынты ясады. Фейхтвангер ярдәме белән мин үзем өчен әлеге теманы ачтым һәм бүгенге көнгә кадәр өйрәнүдә.

Әйе, мине һәрвакыт тарих кызыксындырды, ләкин гадәтирәк әдәби китапларны да беркайчан да читкә этәрмәдем. Бу, әйтик, Ильф һәм Петров әсәрләре, Швейк солдатлы Ярослав Гашек, Леонид Соловьевның «Повесть о Ходже Насреддине» дилогиясе… Болар барысы да фактта яттан диярлек өйрәнелә иде. Владимир Козинның хикәяләрен яраттым, әле тагын фантастиканы – Иван Ефремовның «Лезвием бритвы» әсәрен һәм бертуган Стругацкийлар романнарын кызыксынып укыдым.

Әдәби зәвыгымны формалаштыруга йогынты ясаган тагын ике кеше булды. Шуларның берсе – Эрнст Галим улы Улумбеков. Мединститутта императорлар заманыннан ук үзгәрешсез сакланып калган профессор кабинетында, чәй эчә-эчә, әдәбият турында сөйләшеп утырганыбыз әле дә хәтердә. Аның өчен берәр кызыклы нәрсә табарга туры килгәндә, шундый шатлана идем! Бервакыт әле яңа гына басылып чыккан «Мастер и Маргарита» романының журналдагы вариантын таба алдым. Дустым белән күчермәсен ясаттык та (гәрчә бу тыелган булса да) Ленин бакчасындагы китап базарына киттек. Минем «бизнесым» көч-хәл белән ясалган һәм тегелгән күчермәне Марсель Прустның ул вакытта бик популяр булган «В поисках утраченного времени» китабына алыштырудан гыйбарәт иде.

Икенче бер остазым профессор Ирек Мәхмүт улы Рәхмәтуллин булды. Ул мин 45 елга якын эшләгән патологик физиология кафедрасы мөдире иде. Шигърият сөюче. Мин, әлбәттә, элегрәк тә Есенин белән Евтушенко укырга, Шарль Бодлерны ятларга ярата идем. Ләкин нәкъ менә аның белән һәм аның ярдәмендә Омар Хәйям тәрҗемәләрен тикшерергә, фикеремне белдерергә өйрәндем. Бүген дә шәхси китапханәмдә берничә бик кызыклы китап саклана.

2. ЯРАТКАН ӘСӘРЛӘРЕМ

Яшь чагымнан Юрий Германның табиб Устименко турындагы трилогиясен яратам: «Дело, которому ты служишь», «Дорогой мой человек», «Я отвечаю за всё». Әлеге китаплар күпмедер дәрәҗәдә һөнәри юлымны сайларга булышты кебек – мин мединститутка кердем. Гәрчә ул вакытта абыем инде анда укый, әни дә һәрвакыт: «Төрмә яисә лагерьда да табиб була алачаксыз», – дип кабатларга ярата иде. Бәхеткә, моның кирәге чыкмады.

Яраткан китапларым арасында Катаев, Паустовский, Солоухин әсәрләрен атый алам. «Роман без вранья. Мой век, мои друзья и подруги» китабына аерым басым ясыйсым килә. Аның авторы Анатолий Мариенгоф (әлбәттә, Козинны санамаганда) минем игътибарымны беренче мәртәбә 1920 нче елларга юнәлтте. «Проклятые поэты» китабының (Бодлер, Верлен, Рембо поэзиясе җыентыгы) кесә форматы миңа гыйльми советларда зур ярдәмче булды.

3. ХӘЗЕРГЕ ВАКЫТТА УКЫЙМ…

Минем әдәби кызыксынуларым әтием бакыйлыкка күчкәч, 2002 елда үзгәрде. Без аның турында беренче китапны әзерли башладык, һәм кинәт кенә мин үземнең, дәреслектә, әтием турында бернәрсә дә белмәвемне ачыкладым. Әйе, аның истәлекләре бар, әмма биография турында язганда төгәл фактлар, саннар кирәк бит. Һәм менә инде 18 ел дәвамында диярлек мин эзлекле рәвештә әтиемә кагылышлы бөтен нәрсә турында укыйм. Мәсәлән, үземә шундый сорау бирәм: 1930 нчы елларда нәрсә булган? Һәм утызынчы еллар турында укый башлыйм. Ә эти «У-2» очкычында ничек очкан икән? Аннан соң госпитальләр темасы пәйда булды, чөнки 1941 ел ахырында эти Казан госпиталенә эләккән… Болар барысы да безнең тарих.

Казан турында сөйләшәбез икән, мин җентекләп укыган басмалар арасында Загоскин редакциясендәге «Спутник по Казани», шулай ук Пинегинның «Казань в её прошлом и настоящем» китабы бар. Бүген китап киштәмдә игътибарымны көтеп яткан китаплардан шәһәребез турындагы яңа басмаларны атый алам: Алексей Клочковның «Казань: логовища мокрых улиц», Лев Жаржевскийның «О казанской старине и не только», «Евреи в Казанской губернии и Республике Татарстан. Очерки истории» басмалары.

4. ВАКЫТ-ВАКЫТ ЯҢАДАН УКЫЙМ…

Һәрвакыт күз алдымда яткан китаплардан Борис Чертокның дүрт томлы «Ракеты и люди» китабын атый алам. Искиткеч язылган, теле шәп. Академик Черток илебез ракета техникасына нигез салуда катнашкан шәхес. Космик техникага да. Аның китапларында мине кызыксындырган нәрсәләр бар, әтием белән бәйлеләре дә. Һәм, әгәр сез Россиядә нинди ракета һәм космик техника барлыгын, аның нинди булачагын аңларга телисез икән, СССРда нәрсәләр булуын өйрәнүдән башларга кирәк. Черток китапларында барысы да тәфсилләп – исемнәр белән бәйле тарихлар аша язылган.

Тагын берничә китапны еш кулга алам. Бу – Өченче рейхның ракета ясау урыны – тикшеренү үзәге һәм Пенемюнде полигоны турында. Анда дөньяда беренче мәртәбә «Фау-2» баллистик ракеталары төзелгән. Нигездә болар немец авторлары китаплары, ләкин араларында Дмитрий Верхотуров язган «Подземные заводы Третьего рейха» китабы да бар. Тагын ике басма – Дэвид Портерның «Секретное оружие Гитлера. 1933–1945» һәм Роджер Фордның «Вторая мировая война. Секретное оружие» китаплары ул елларда дошман кулында нинди корал, аның ни дәрәҗәдә көчле, куәтле булуы турында сөйли. Тарихи хәрби документларны һәм китапларны өйрәнү минем өчен гади кызыксыну гына түгел. Мин әлеге вакыйгаларны әтием кылган батырлыкның ролен һәм әһәмиятен билгеләргә тырышу яссылыгында карыйм.

5. СОҢГЫ ВАКЫТТА КӨЧЛЕ ТӘЭСИР КАЛДЫРГАННАРЫ…

Соңгы вакытта мин әтием турында нәфис фильм төшерүче төркемгә консультация бирү белән мәшгуль. Шуңа күрә күптән өйрәнергә җыенган темага бик якын килдем. Бу концлагерьлар темасы. Әгәр сез миннән, үсеп килүче буын һичшиксез нәрсә турында укырга тиеш, дип сорасагыз, җавабым бер: концлагерьлар турында. Европа белем бирү программасы мәктәп укучыларының кайчандыр концлагерьлар булган урыннарны һичшиксез карап кайтуын күздә тота. Бу урыннар коточкыч көчкә ия! Һәм мин үзебезнең укучыларыбыз һәм студентларыбыз белән очрашканда бу темага кагыла да алмыйм! Чөнки бөтенләй белмиләр. Болай булырга тиеш түгел. Без бүген патриотизм турында еш сөйлибез, ләкин сугыш турында әйтәбез икән, нәкъ менә концлагерьлар темасы – безнең авырткан урын. Ә бит миллионлаган ватандашыбыз – хәрбиләр дә, гади кешеләр дә – сугыш чорында нәкъ менә шунда килеп эләккән. Үз тормышы, көнкүреше, теле булган гаять катлаулы дөнья… Бу турыда Николаус Вахсманның «История нацистских концлагерей», Олег Смысловның «Плен. Жизнь и смерть в немецких лагерях», Станислав Аристовның «Повседневная жизнь нацистских концентрационных лагерей» китапларыннан укып белергә була.

6. КИҢӘШ ИТӘМ

Миңа ниндидер китапны укырга киңәш итү авыррак. Ләкин әтием турындагы китапларны тәкъдим итүне үземнең бурычым дип саныйм. «Михаил Девятаев», «Михаил Девятаев. Воспоминания, отклики, публицистика, хроники», «Позывной «Мордвин» дип аталган китапларны. Әтиемнең «Побег из ада» һәм «Полёт к солнцу» кебек биографик китапларын укыгыз, аларда әтием үзенең тормышы, шул исәптән концлагерьда булуы турында да сөйли. Аның турында шулай ук әдәби әсәр дә бар – «Сотый шанс» дип атала. Повестьны Николай Стуриков язган. Бергә әсирлектән качкан гомерлек дусты Иван Павлович Кривоногов сугыш турында «Родина зовет: Записки офицера Советской Армии» дип аталган истәлекләрен дә язды.

7. МИҢА ОШАМАГАН КИТАПЛАР

Мин китап кибетенә еш керәм, яңа басмалар белән кызыксынам. Бигрәк тә сугыш турындагы китаплар тезелгән киштәгә күз салам. Башка темаларны да караштыргалыйм. Кайчак китапны кулга алам, битләрен актарам да… кире куям. Юк, алар миңа ошамый, дип әйтә алмыйм. Мин андыйларны укымыйм гына.

8. КӘГАЗЬ ЯИСӘ ЭЛЕКТРОН КИТАПМЫ?

Әлбәттә, кәгазьгә басылганы. Балаларым кечкенә чакта аларның караватлары янына китап киштәсе куйдым. Укып чыкмасалар да, күрерләр дип уйладым. Ниятем барып чыкты. Укыйлар, бик күп.

Бүген минем шәхси китапханәмдә шактый кызыклы басмалар бар. Мәсәлән, инглиз авторы Уолтонның «Философия рыбалки» басмасының бүләк варианты. Әйе, искиткеч юмор белән язылган чын фәлсәфә. Ә бизәлеше – карап туйгысыз! Бу китапны мин берничә битләп кенә укыйм. Десертка! Бу мин кулыма тотып карый ала торган бәхет!

9. КИТАП МИНЕМ ӨЧЕН НӘРСӘ

Монда мин кабатланамдыр – белем чыганагы. Хәер, бу чыннан да шулай! Ә моннан тыш, китап чын ләззәт алу чыганагы да була ала – Хәйям яисә Киплинг әсәрләре, мәсәлән. Яисә сэр Роберт Брюс Локхартныкы. Без аны инглиз дипломаты, сәяси үзгәрешләрдә катнашучы буларак беләбез. Ләкин ул әле виски турында бик шәп китап язган автор да булып тора. Һәм бу гади мәгълүмат кына түгел, бәлки тарихи-поэтик гимн, ләззәт! Вакытның җитмәве генә кызганыч.

БАШКА ДӨНЬЯЛАРГА ИШЕК: ФАНТАЗИЯ БЕЛӘН ТАРИХИЛЫК ЧИГЕНДӘ

Автор: Луиза Янсуар

Яңа ел бәйрәмнәре тау шуып, бозгалакта җилдереп үткән актив ял белән генә истә калмый, ә интеллектуаль эчтәлеге белән дә хәтергә уела. Бу – ел дәвамында көтеп алган яраткан фильмнарга чират җитә торган вакыт. Бигрәк тә – сериалларга һәм алар бүләк иткән дәвамлы адреналинга. Шуңа да «кышкы ял сезонында» каналлар белән стриминглар, тамашачының ихтыяҗын исәпкә алып, «иң-иң» дип исәпләнгән сериалларны агымга куя. Без дә шуларның кайберләренә күзәтү ясыйк...

Сезонның иң көтелгән вакыйгасы, әлбәттә, «Викинги» сериалының дәвамы иде. «Амедиатека» белән көтмәгәндә жанрлы сериаллар әйләндерүгә йөз тоткан (күрәсең, бу килешү үзара файдалы булгандыр) History каналы аның чираттагысын тамашачыга 4 декабрьдә тәкъдим итте. History каналы сериалга, аңлашыла инде, интеллектуаль караучылар катламын китерде һәм 6 нчы сезонның дәрәҗәсенә олпатлык, затлылык өстәде. Скандинавия мифологиясенә тулаем кереп чумган җанатарлар өчен бу сезонда тагын бер интрига бар иде: ул да булса, Данила Козловский каһарманы һәм вакыйгаларның Борынгы Русь җирлегенә, аның борынгы елъязмаларына турыдан-туры килеп тоташуы.

Шәхсән минем өчен бу йомгаклау сезоны 1 нче сезоннардан калган ностальгиягә яңадан кайтып чуму өчен күңелле бер чыганак булды. Әмма сүземне викинглардан башка яккарак борып, күз уңыннан читтәрәк калган, ләкин игътибарга чын-чынлап лаек булган күпсерияле һәм сезонлы проектларга юнәлтәсем килә.

Фото: https://www.kinopoisk.ru/, https://www.ivi.ru/, https://www.kp.ru/putevoditel сайтыннан алынды

ДВОЙНИК (ПО ТУ СТОРОНУ),
2017–2019
2 СЕЗОН

Сценарист Джастин Маркс белән режиссёр Мортен Тальдумнның проекты бүгенгә 2 эпизодтан һәм 20 сериядән гыйбарәт. Сүз уңаеннан, режиссёрлар исемлегендә Дженниффер Гетцингер, Алик Сахаров кебек инде шактый билгеле, үзенчәлекле исемнәр дә бар. STARZ каналы безгә бүләк иткән сериалның иң зур уңышы – төп каһарманны уйнаучы актер Дж.К. Сиимонс һәм аңардагы симпатия белән антипатия чигендә торган энергия, дәрт, харизма кушылмасы, дияр идем. Моннан тыш, Оливия Уильямс, Гарри Ллойд, Сара Серайокко, Назанин Бониади, Николас Пиннок, Стивен Ри һәм башкалар да уены, экрандагы яшәеше белән күңелдә канәгатьлек тойгысы уята, сокландыра, яраттыра.

Проектны тудыручылар сериалның дөнья моделен Берлин җирлегендә кора. Һәм, аңлашыла инде, безне Салкын сугыш елларындагы тарихи барлыкка алып кайта. Дөресрәге, шуннан этәрелергә чакыра. Фәнни фантастика белән детектив, хәтта ки шпион детективы, нуар чигендә торган сериал атмосферасы белән беренче кадрлардан ук җәлеп итә.

Говард Силк («шёлк» сүзенә иронияле сылтама булуы шунда ук аңлашыла) каһарманы Берлиндагы Яшерен оешмаларның берсендә инде 30 елдан артык гадәти вак клерк булып эшли. Ул үз эшенең нидән гыйбарәт икәнен, нинди миссиясе барлыгын үзе дә белми: интерфейста гади сөйләшүләр алып бару белән эш сәгатьләрен тутыра. Хыялы – Стратегия, менә анда чын-чынлап дөнья белән идарә итүчеләр утыра...

Говард – типик «кечкенә кеше», «лузер». Аның белән әнә шул ноктадан таныштыра безне режиссёрлар сериалның башында ук. Эшеннән бушагач, әлеге төссез һәм күңелсез кеше, коллегалары белән барга барудан да баш тартып, кайтырга кузгала, буталчык урамнардан атлый һәм хастаханәгә килә. Баксаң, аның хатыны комада ята, ул һәр кичне аның баш очында китап укый икән.

Тормышы шулай җай гына, давылларсыз дәвам да иткән булыр иде дә бит, әмма көннәрдән бер көнне ул яшәгән параллельдә аңа ике тамчы судай охшаган игезәк – икенче бер Говард пәйда була. Бу Говард без инде таныш булганыннан холык-фигыле, тотышы белән бөтенләй аерылып тора: ул тәвәккәл, кыю, әрсез, хәтта ки дуамал зат. Һәм менә төссез Говардка үзенең копия-нөсхәсе белән очрашырга туры килә һәм ул аның кем булуын белә: разведкага эшли торган агент, Салкын сугыш елларында Берлинда ике дөнья чигендә торгызылган порталдан үтеп кергән шымчы. Һәм ул үзен без белгән «мескен» Говардның күпкә камилрәк һәм булдыклырак варианты буларак тәкъдим итә.

Фильмнан «Люди в чёрном», «Матрица», «Нирвана», «13-й этаж» һ.б. охшаш жанрдагы картиналарга хас булган чалымнарны эзлисе килә. Әмма юк, биредә алардагы шикелле мистика һәм абсурд кушылмасы, ирония белән романтика каршылыгы түрдә тормый, «Двойник» бик тә реалистик тукымалы, хәтта ки тарихи фактларга, казусларга сылтамалы нуар-детектив.

Әйтик, массачыл грипп эпидемиясе. Кораллар ярышы. Вакциналар, вируслар, космик алгарышлар. АКШ белән СССР арасындагы күп елларга сузылган киеренкелек. Бүген соң чигенәчә җитеп актуальләшкән Көнбатыш белән Көнчыгыш конфронтациясе...

Баксаң, ике дөнья арасында бу вакыйгаларның барысы да валютага тиң, кеше гомерләре дә копияләрнең сәяси уендагы роленә, урынына карап бәяләнә. Юкка гына геройлар сериалның буеннан-буена әле шахмат уены, әле го уйнамый: бу һәр нөсхәнең иҗтимагый аренадагы роленә ишарә: пешкамы син, ферзьме, атмы, корольме...

Ләкин иң куркынычы әле бу түгел... Иң куркынычы – бер дөньядан икенче дөньяга үтеп-кереп йөргән яшерен киллерлар һәм мәгълүмат ташучылар барысы да Бер Системага хезмәт итә –

«НИ ӨЧЕН УЙЛАП ЧЫГАРГАННАР СОҢ УЛ ИШЕКНЕ ҺӘМ БАШКА ДӨНЬЯНЫ? ЧЫННАН ДА, УЙЛАП ЧЫГАРГАННАР, ДИСӘҢ, ДӨРЕСРӘК БУЛЫР: МОНЫСЫ БУЛМАСА, АНЫСЫ ДА БУЛМАС ИДЕ БИТ. ДИМӘК, АЛАРНЫҢ ИКЕСЕ ДӘ БЕР-БЕРСЕ ЯШӘСЕН ӨЧЕН КИРӘК...»



дөньяны йомшак, җылы кәнәфиләрдә утырып, йә булмаса дини тарафка йөз тотып, үз максатларын алга сөрер өчен кулланучы дәһши фанатикларга. Масонлыкка да ишарә бар биредә, неофашизмга да, яңа сулларга да, заманча либералларга да… Кыскасы, винегрет. Әмма яхшы ингредиентлардан әзерләнгән винегрет.

70 нче еллар белән бүгенге кәрәзле телефоннар, күккә ашкан биналар чуарлап алган чынбарлык арасында бәргәләнгән каһарманнар ахыр чиктә бер генә нәрсәне исбат итә: кешенең асылы, табигате, тышкы факторлар нинди генә булмасын, иң хәтәр хәлләрдә үзен һәм үзенекеләрне яклауга, саклауга йөз тота. Башкаларның гомере бәрабәренә булса да… Хәтта сине махсус мәктәпләрдә җәллад итеп тәрбияләсәләр дә…

«КӨННӘРДӘН БЕР КӨННЕ ДӨНЬЯ ҮЗЕНЕҢ КОПИЯСЕН ЯСАДЫ ДА, АЛАР БАРЛЫККА КИЛДЕ. ХӘЗЕР СЕЗ, ИҢ ХӘЛИТКЕЧ МИЗГЕЛДӘ, АЛАРНЫ ҮЗЕГЕЗ БЕЛӘН АЛМАШТЫРЫР ӨЧЕН ӘЗЕРЛӘНӘСЕЗ...»

Ике якта да хәлләр кискен: Штази белән кәрәзле системага корылган яңача шпионлык челтәре уеннары каршылыкка нокта куярга җыенмый. Мондый чакта без нәрсәгә сәләтле соң? Бигрәк тә ваемлый алмый иза чиксәк: кайсы дөнья кайсысын тудыра да, кайсы чор кайсысын билгели? Кем чын? Кем ялган?! Симмонс гәүдәләндергән Говардлар – ничәү алар?! Спойлер ясый башласаң, ничә катлы булыр иде икән, анысы да…

Әлегә проектны тудыручылар 2 нче сезонда тукталып калды. Минә дигән актёрлар составы, каст белән бергә ахыргача киеренкелектә тотарга сәләтле экшн тудыра алаулары белән котларга гына кала «Двойник» командасын. Һәм, бәлки, шушы сезон белән генә тукталып калган очракта да, алар үз максатына ирешкәндер, шәт. Кайчакта әйбәт сериалның, Lost вариацияләренә барып җитмичә, яхшы чакта төгәлләнүе хәерле.

БРИТАНИЯ, 2017–2019

2 СЕЗОН

Фэнтези жанры үзенең алдынгы позицияләрдә торуын һаман да исбатлап килә. 2017–2019 нчы еллар аралыгында төшерелгән һәм бер өлеше инде киң кулланыла торган платформаларга чыккан «Британия» сериалы – моның ачык мисалы. Sky1 һәм Amazon Prime Video эшләгән бу проектның режиссеры – Джереми «Джез» Баттеруорт һәм аның командасы борынгы бриттлар яшәгән кыргый да, сихри дә дөньяны гәүдәләндерер өчен күп көч һәм энергия сарыф иткән. Бюджет ягыннан да ким-хур түгеллекләре күзгә ташланып тора.



Сериал беренче кадрлардан ук үзенең табигать күренешләре белән сихерли. Режиссёр төшерү урыны итеп мәһабәт Уэльс пейзажлары белән Праганы сайлый.

Тарих, экшн һәм мистика кушылмасы булган микс ни өчендер рейтингларны әллә ни шартлатмады. Гәрчә эшләнеше ягыннан шактый провокацион һәм кызыклы, заманча укылышлы булса да. Ни өчендер, аны «Игра престолов», «Викинги» сериалыннан соң «чираттагы», «шул рухтагы» проект буларак кабул итәргә тырышты хәтта тәнкыйтьчеләр дә. Безнең карашка, бу сериалларны бюджет ягыннан да, категориясе буенча да гомумән янәшә куеп карарга кирәкми. Кирәкми генә түгел, ярамый да. Чөнки аларның максаты һәм форматы гаять төрле. «Британия» бу авыр йөк атлары белән

«БЕЗНЕҢ ЭРАГА КАДӘР 55 НЧЕ ЕЛДА ЮЛИЙ ЦЕЗАРЬ БРИТАНИЯГӘ БӘРЕП КЕРӘ. УТРАУ КУРГАШ, ТИМЕР ЗАПАСЛАРЫ, АЛТЫН ҺӘМ КӨМЕШ ЯТМАЛАРЫ БЕЛӘН ДАН ТОТА. ӘММА ЦЕЗАРЬНЫ БИРЕДӘ БӨТЕНЛӘЙ БАШКА, УЛ КҮЗ АЛДЫНА ДА КИТЕРЕП КАРАМАГАН ЛЕГЕНДА БЕЛӘН ОЧРАШУ КӨТӘ – ДРУИДЛАР БЕЛӘН...»

алышка чыгуны күз уңында тоткан проектлардан шактый аерылып тора...

Авторлар сеттинг һәм фабула белән ничек кенә ирекле эш итмәсен, картинада иң үзәктә – реаль тарихи вакыйгаларның авторча укылышы һәм аларны үз заманы вәкилләре тарафыннан ваемлана, кичерелә торган тере процесс итеп күрсәтүгә йөз тоту. Әнә шул соңгысы белән җәлеп итә дә сериал – без, каһарманнарга ияреп, чын-чынлап архаик кичерешләр дәверенә кайтабыз. Кысаларга, тәртәләргә кертелмәгән чорына Тарихның. Әлбәттә, без дәреслекләрдән укып белгән кельтларны моңарчы башкачарак күз алдына китерә идек. Шуңа без бер мәлгә аптырап калабыз... Ә аннан экрандагы кыргыйлыкны, хаосны күреп шаккатабыз. Әмма тора-бара, күрәзәчел төшләр һәм өннәр арасында адашып бетә язгач, шуны ваемлап алабыз: чыннан да, бу – бөтенләй икенче, логик һәм рациональ сөрешне алга этәрмәгән, ә интуитив тоемлауга нигезләнеп яшәгән аң борылмалары. Чынлап та, мифик катлам безгә әнә шул заманнардан килеп ирешкән һәм сакланып кала алган...

«ДРУИДЛАР ҺӘМ БРИТАНИЯ ХАКИМНӘРЕ БЕЛӘН ОЧРАШКАННАН СОҢ, БӨЕК ИМПЕРАТОР, ГАСКӘРЕН БОРЫП, ӨЕНӘ – РИМГА ТАБА БОРЫЛГАН ИДЕ. БУ АНЫҢ ИҢ АКЫЛЛЫ АДЫМЫ БУЛДЫ. ӘММА 90 ЕЛ УЗГАЧ, РИМЛЫЛАР БРИТАНИЯГӘ ЯҢАДАН ӘЙЛӘНЕП КАЙТТЫ. БУ АЛАРНЫҢ ИҢ ЗУР АКЫЛСЫЗЛЫГЫ БУЛГАНДЫР, МӨГАЕН...»

«Британия» чәчләрне үрә торгызырга сәләтле күренешләре белән генә түгел, ә интригалы сюжет линиясе, аның четерекле чишелеше белән дә җәлеп итә. Без римлыларның бриттларны яулап алу тарихына мондый ноктадан карамаган идек бит әле, дип уйлыйсың һәр серия саен. Һәм нәкъ менә шул уй бар нәрсәне, ахыр чиктә, үз логик нигезенә утырта да. Дөньяны коткарыр өчен яратылган герой турындагы миф та; ул мифның үзен үк үзе җимерүе, алдавы, яңадан корылышы да; друидларның хакимнәргә язмышларын бары тик үлем алдыннан гына әйтеп, тарих тәгәрмәчен мөстәкыйль әйләндерүе, дедукция ысулы белән бөтен барышка нәтиҗә ясавы да; империяләрне акыл түгел, ә аң катламындагы төпкелләрдән калыккан хиссият нигезендә кыйблага алып бару алгоритмы да...

Сериал бик тә заманча укыла торган психоделикага корылган. Бу аның промо-постерларында да, башындагы заставкада да, аннан да бигрәк саундтрегында күренә, яңгырый. 1960 нчы елларга нисбәтле рок-клипны хәтерләтүче әлеге заставка вакыйгаларны бүген, шушы ноктадан торып кабул итәргә чакыра, диярсең. Шулай булгач, аңлашыла да, тарихи полотно дәгъвалауга юл тотмыйбыз, ә Тим Бертон рухындагы шомлы-хәвефле, сихри-тылсымлы, ымсындыргыч-комарлы әкият моделенә атлыйбыз. Сериал безгә Цезарь исеменнән икенче мәртәбә Британияне яуларга килгән легион составындагы негрлар – нубиялеләрнең ритуалларына күмелергә дә тәкъдим итә, панкларга яки готлар, эмоларга тартым друидларның Кастанеда рухындагы трансларына да пәрдә читен ача... Монда легионнарның, гаскәриләрнең кем булуы да мөһим түгел инде, алар – Тарих психоделикасының бер борылышындагы тәшвиш төш кенә. Күрдемме мин бу төшне чыннан да, әллә юкмы?! Шулай булса да, костюмнар, этник детальләр гаҗәеп нечкә, эстетик югарылыкта эшләнгән. «Британия»не бу җәһәттән белгечләр дә югары бәяли, мактый.

Сериал хатын-кыз героинялар галереясы белән хаклы рәвештә горурлана ала. Һәм без, баштарак бераз гына аптыраошта калып, аннары инде ияләшеп китеп, матриархат белән патриархат төшенчәләре бәндәләрнең башын борауламаган дәвергә кайтабыз. Феминизм, сексизм төшенчәләренең абсурд икәнлеге ваемлана, уйдырма фәлсәфәләр, концепцияләрнең бары тик идарә итү, манипуляция ысуллары гына булуына янә бер кат инанылa.

«Британия» ирония, юморга да искиткеч бай: аның каһарманнары тарих дәреслекләреннән сикереп төшмәгән, ә кайсыдыр ябык клубтагы рок-бәйрәмнән ургылып килеп чыккан кебек тоела. Мин үзем бу сериалны караганнан соң, тарихның без уйлаганнан якынрак торуын, җилкәгә түгел, ә маңгайга өрүен тойдым. Кайнар сулышы белән... ■

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!

МАХСУС ПРОЕКТ

— 50нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Илдар Мингалиев, ТР сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары, февраль аенда үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Игътибарыгыз һәм ярдәмегез өчен рәхмәт

– Хөрмәтле Илдар Равилевич!

Шәхсән үз исемемнән һәм «Казан Гипронииавиапромы» Компанияләр төркеме хезмәткәрләре коллективы исеменнән Сезне юбилеегыз белән ихлас котлыйм!

Сезгә Татарстан Республикасы сәнәгатен үстерү буенча башкарган зур эшләрегез өчен хөрмәт һәм ихтирам сүзләребезне җиткерәсем килә. Сезнең гадәттән тыш шәхси һәм эшлеклелек сыйфатларыгыз олы абруй казану һәм җитди уңышларга ирешү мөмкинлеге бирде. Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары вазыйфасында Сез республика сәнәгатен үстерү, төрле төбәкләр һәм илләр белән хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре урнаштыру һәм башка стратегик әһәмияткә ия булган бурычларны хәл итү белән шөгыльләнәсез. Сез дөрес карарлар кабул итә белүегез, олы эш тәҗрибәсе, эшкә сәләтлелек һәм һөнәри осталык, еракка карап эш итә белүегез һәм принципиальлегегез белән аерылып торасыз.

Сезнең сәнәгатьне оештыру буенча уникаль тәҗрибәгез, тирән белемегез һәм эрудициягез республика һәм предприятиеләр җитәкчеләре һәм белгечләрендә тирән ихтирам уятты. Предприятиеләрне үстерүгә керткән өлешегез һәм аларның инновацион һәм фәнни куәтен гамәлгә ашыруга ярдәмегез өчен рәхмәт белдерәсе килә!

Хөрмәтле Илдар Равилевич! Сезгә чын күңелдән һөнәри эшчәнлегегездә зур уңышлар, яңа очрашулар һәм күтәренке кәеф телим! Сезгә һәм якыннарыгызга рух ныклыгы, шатлыклар, бәхет һәм сәламәтлек насыйп булсын!

КАЗАНСКИЙ ГИПРОНИИАВИАПРОМ ГРУППА КОМПАНИЙ

Борис Тихомиров, «Казан Гипронииавиапромы» Компанияләр төркеме Акционерлык җәмгыятенең генераль директоры

Реклама

Алексей Слободинский, «КАПО-Композит» АҖнең генераль директоры

Тәҗрибәгез һәм белемегез кыйммәтле

– Хөрмәтле Илдар Равилевич, «КАПО-Композит» коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез!

Сез мәктәп эскәмиясеннән үк максатка омтылучан булгансыз, аннан соң инженерлык белгечлегенә укып кызыл диплом алгансыз. Еракка карап эш итә белүегез нәтиҗәсендә Сез турыдан-туры җитештерүдә тәҗрибә туплагансыз, аннан соң ныклы адымнар белән алга атлагансыз.

Менә инде дистә ел дәвамында Сез Татарстанның сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары кебек мөһим вазыйфаны башкарасыз. Әлеге еллар эчендә Сез республиканың җитештерү һәм эшкуарлык базарларында инновацион үзгәрешләр булдыруга зур көч куйдыгыз. Сез ару-талу белмичә сәнәгатьчеләр белән эшлисез, продукцияләрнең сыйфатын яхшыртуга йогынты ясыйсыз, башка төбәкләрнең һәм илләрнең уңай тәҗрибәсен өйрәнәсез. Сезгә алдынгы тәҗрибәләр һәм сәнәгать өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруга керткән өлешегез өчен олы рәхмәтебезне җиткерәбез.

Сезне белгән һәркем зыялы булуыгызга соклана, һөнәри яктан да, кеше буларак та мөнәсәбәтләр кора белүегезне билгели. Бәхеткә, Татарстанда икътисад алга киткән саен, үз эшенә тугрылык саклаган кешеләр артканнан арта бара.

Сезгә озын гомер һәм алдыгызга куйган максатларыгызга ышанычлы командагыз белән бергә ирешүегезне телим. Сезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек һәм бәхет телим, хөрмәтле Илдар Равилевич!

КАПО-Композит Акционерное Общество

Фото «КАПО-Композит» АҖннән алынды

Реклама

Фото «Кукмара Металл савыт-сабалар заводы» ААҖһнән алынды ТМ Kukmara

Азат Заһидуллин,
«Кукмара Металл савыт-сабалар заводы» ААҖнең генераль директоры
ТМ Kukmara

Реклама

Kukmara®
Сделано в России

Ихлас хөрмәткә лаек казанышлар

– Хөрмәтле Илдар Равилевич, ихлас күңелдән Сезне юбилей бәйрәмнәре белән котлыйм. «Кукмара Металл савыт-сабалар заводы» ААҖнең коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезгә кайнар теләкләремне җиткерергә рөхсәт итегез!

Сез – гадәти булмаган максатчанлыкка ия булган һәм креатив фикерле торган бүгенге көн кешесе. Яшь вакытта ук җитештерү процесслары белән танышып, Сезнең һөнәри үсеш юнәлешегезне билгеләвегез гаҗәп түгел. Сез бүген дә ирешелгәннәрдә туктап калмыйсыз, үз эшенең остасы буларак, һәрвакыт үсештә.

Менә дистә ел инде Сез республика өчен бик мөһим булган вазыйфада хезмәт итәсез. Җитештерүчеләрнең көн тәртибендә торган проблемаларын ачыклап, аларны хәл итүгә булышу, дәүләт системасы белән нәтиҗәле диалог коруга ярдәм күрсәтү, сәүдә элемтәләрен көйләү – болар барысы да Сезнең беренче чираттагы казанышларыгыз һәм аларны үтәү ихлас хөрмәт уята.

Сезне энергиягез һәм нәтиҗәле мөнәсәбәтләр кора белүегез өчен ихтирам итәләр. Алга таба да Сезнең актив тормыш позициясе республика файдасына инновацион проектларны гамәлгә ашыруга ярдәм итсен. Сезгә алга таба да перспективалы башлангычлар, сәламәтлек һәм уңышлар юлдаш булсын!

Азат Хәким, «Тулпар» Компанияләр төркеменең Директорлар советы рәисе, февраль аенда үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Фото «Тулпар Интерьер Төркем» ҖЧҖнннән алынды

Александр Калачёв,
«Тулпар ИнтерьерТөркем» ҖЧҖнең генераль директоры

Реклама

ТУЛПАР
ИНТЕРЬЕР ГРУПП

Күкләр үз фатыйхасын биргән

– Хөрмәтле Азат Мортазович, 65 яшегез тулган көнне «Тулпар Интерьер Төркем» коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезгә карата әйтелгән җылы сүзләргә һәм бәйрәм котлауларына кушылырга рөхсәт итегез.

Сез язмышыгыз итеп, авиацияне сайлагансыз, һәм сезнең максатларга ирешүчән һәм хезмәт сөючән кеше булуыгызга җавап итеп, күкләр фатыйхасын биргән. 40 елдан артыграк элек Сез Як-40 экипажының командиры һәм очучысы булгансыз. Җаваплылык һәм булдыклылык кебек сыйфатларыгыз Сезгә бу өлкәдә талантыгызны эшкә җигәргә һәм үстерергә мөмкинлек биргән. Сез очучы-сынаучы вазыйфасында менә дигән уңышларга ирешеп, «Тулпар» авиакомпанияләрен оештыргансыз һәм «Казан» халыкара аэропортының генераль директоры дигән дәрәҗәле вазыйфаны башкаргансыз.

Без Сезне эшлекле эшкуар һәм авиация өлкәсендә эксперт буларак беләбез. Авиация бизнесы даими рәвештә катлаулы бурычлар алдында калса да, Сез аны үстерүнең иң дөрес юлларын таба беләсез.

Мин үзем һәм командам Сезнең кебек үз эшенең остасы янәшәсендә эшләвебез белән ихлас күңелдән горурланабыз. Азат Мортазович, Сезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телибез. Эшләрегез алга таба да уңышлы булсын, иксез-чиксез мөмкинлекләр, шатлыклы көннәр, онытылмаслык тәэссоратлар насыйп булсын!

Фоат Вәлиев, ТР Дәүләт Советының алтынчы чакырылыш депутаты, «Алексеевскдорстрой» ААҖнең Директорлар советы рәисе, февральдә үзенең 65 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Ринат Мөхьянов,
«Мосты РТ» АҖнең
генераль директоры

Актив һәм максатчан кеше

– Хөрмәтле Фоат Вәлиевич! Сезне безнең компания хезмәткәрләре һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән ихлас котлыйм! Бүгенге бәйрәм күпсанлы казанышларыгызны һәм шәхси кешелеклелек сыйфатларыгызны искә төшерергә форсат бирә. Сез язмышыгызны транспорт тармагы белән бәйләгәнсез, машина йөртүчедән «Алексеевскдорстрой» ААҖнең Директорлар советы рәисе һәм ТР Дәүләт Советының алтынчы чакырылыш депутатына кадәр юл үтеп, эшче һөнәрләренең авыр хезмәтен үз җилкәгездә татыгансыз. Сезне актив һәм максатчан кеше, алга куелган планнарны үтәп бара һәм дәүләт дәрәҗәсендә әһәмияткә ия булган амбициоз бурычларны хәл итә ала торган тәҗрибәле һәм киләчәккә карап эш итүче җитәкче буларак беләләр. Һөнәри осталык, чыдамлык, оештыра белү, аналитик фикерләү сәләте Сезгә тормышта күп нәрсәләргә ирешү мөмкинлеге биргән. Тырыш хезмәтегез һәм уйлап ясалган адымнарыгыз белән югары нәтиҗәләргә ирешә ала торган җитәкче абруен казандыгыз, Татарстанның юл тармагында ихтирамга лаек эксперт буларак танылдыгыз. Ирешкән казанышларыгыз һәм мактаулы исемнәрегез дә Сезнең турыда күпне сөйли – ТРның атказанган төзүчесе, РФнең атказанган төзүчесе, Россиянең мактаулы юл төзүчесе. Без бер-беребезне күптәннән беләбез, һәм мин үзем өчен Сезнең һөнәри һәм кешелеклелек сыйфатларыгызны үрнәк итеп куям. Сезнең белән таныш булуыма шатмын һәм күп вакытта Сезнең тәҗрибәгезгә һәм принципларыгызга таянам. Хөрмәтле Фоат Вәлиевич, җаваплы эшегездә һәрвакыт уңай нәтиҗәләргә ирешергә язсын! Үзегезгә һәм якыннарыгызга иминлек, бәхет, уңышлар һәм ныклы сәламәтлек телим!

Фото «Мосты РТ» АҖннән алынды
Реклама

Айрат Миңнуллин,
«Волгадорстрой» ҖЧҖнең
генераль директоры

Яңа заман җитәкчесенең ачык үрнәге

– Хөрмәтле Фоат Вәлиевич! Сезне туган көнегез белән котлыйм һәм юбилей елы Сезнең өчен акланган өметләр елы булсын иде дип телим! Һичшиксез, «Алексеевскдорстрой» компаниясе белән озак еллар җитәкчелек иткән һөнәр остасы, ТР Дәүләт Советы депутаты һәм актив тормыш позициясендә торган кеше буларак, язмышыгызда горурланырлыгыгыз бар. Татарстанның алдынгы юл төзү оешмасында фидакарь хезмәтегез, һөнәри һәм идарә итүдәге тәҗрибәгез олы хөрмәткә лаек. Сезнең компания менә дигән юллар төзи, ә бу исә бигрәк тә авыл җирлегендә үтә дә мөһим, чөнки торак пунктларның үсеше еш кына юлларга бәйле. Без Сезнең белән бер тармакта эшлибез һәм юл технологияләренә карата таләпләрнең даими рәвештә артуын, техник регламент һәм стандартларның үзгәреп торуын бик яхшы беләбез. Юллар төзү беркайчан да җиңел эш булмаган. Шуңа да бу өлкәдә Сезнең кебек эш өчен янып торган һөнәр осталарының хезмәт куюы әһәмияткә ия. Сез – хәзерге заманда алга куелган бурычларны үтәү өчен команда туплый, эшлекле элемтәләр урнаштыра белгән җитәкчеләрнең уңай үрнәге. Без Сезнең белән хезмәттәшлек итеп, зур нәтиҗәләргә ирешәбез, шуңа да бәйрәм көнне Сезне котлап, башлаган һәр игелекле эшегезгә уңышлар теләргә рөхсәт итегез. Киләчәктә дә безнең үзара хезмәттәшлек республикабызга күп файда китерер, дип ышанам.

Фоат Вәлиевич! Сезгә һәм якыннарыгызга бәхет, сәламәтлек, гармония юлдаш булсын! Янәшәгездә һәрвакыт тугры дуслар, кадерле кешеләрегез булып торсын! Юбилеегыз белән Сезне!

Фото «Волгадорстрой» ҖЧҖннән алынды
Реклама

Проектларыгызга яшел ут кына юлдаш булсын!

Рөстәм Гарифуллин,
«Татнефтедор» ЖЧЖ директоры

Реклама Фото «Татнефтедор» ЖЧЖ-нән алынды

– Хөрмәтле Фоат Вәлиевич! «Татнефтедор» ЖЧЖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм! Сез җитәкләгән «Алексеевскдорстрой» ААҖнең Татарстан өчен әһәмиятле булган юл хуҗалыгы тармагындагы ролен бәһаләп бетерү мөмкин түгел.

Ерактa калган 1990 елда Алексеевскиның юл хуҗалыгы идарәсенә җитәкче булып килеп, Сез әлеге оешманы эре компаниягә кадәр үстерүгә ирештерегез, хәзер аның исеме юлларның сыйфат һәм ышаныч билгесенә әйләнде.

«Алексеевскдорстрой» ААҖ юл төзелеше базарында әйдәп баручы оешмаларның берсе булып тора, монда Сезнең бай тәҗрибәгез һәм бөтен тырышлыкны алга куелган бурычларны үтәүгә туплый белү сәләтегез зур роль уйный.

Республика зур максатлар белән яши, аларга халыкара стандартларга туры килә торган төбәк һәм федераль әһәмияттәге юллар челтәре булганда гына ирешү мөмкин.

«Алексеевскдорстрой» ААҖ озак еллар дәвамында теләсә кайсы катлаулылыктагы проектны үз вакытында һәм иң югары сыйфат дәрәҗәсендә гамәлгә ашыру гаранты булып тора.

Юбилей – йомгак ясау вакыты гына түгел, яңа планнар кору өчен дә менә дигән форсат. Фоат Вәлиевич, алга таба Сез башлаган һәр эш шундый ук нәтиҗәле булыр һәм республикабызга файда китерер, дип ышанам.

Сезгә бары тик уңышлар гына насыйп булсын, хезмәтегез лаеклы бәяләү тапсын, ә проектларыгызга бары тик яшел ут кына юлдаш булсын! Бәхет, сәламәтлек, иминлек Сезгә!

ТАГРАС
ТАТНЕФТЕДОР

Ышанычлы партнер, зирәк остаз

Рәшит Хәбибуллин,
Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе, «АгроТрансПроект Институты» ЖЧЖнең генераль директоры

Реклама Фото «ИнститутАгроТрансПроект» ЖЧЖ-нән алынды

– Хөрмәтле Фоат Вәлиевич!

Институт коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйбыз!

Шушы шатлыклы көндә Сезгә үземнең ихтирамымны һәм рәхмәтемне җиткерәсем килә. Сезнең биография – һөнәри осталык һәм фидакарьлек, дәүләт мәнфәгатьләренә тугрылыклы хезмәт итү һәм сайлаган юлның дөреслеге үрнәге. Сез Алексеевск муниципаль районының гына түгел, ә тулаем Татарстанның транспорт инфраструктурасы үсешенә зур өлеш керттегез. Тәҗрибәле һәм талантлы оештыручы буларак, Сез уртак максатларны тормышка ашыру өчен, фикердәшләр командасын туплый алдыгыз. Хезмәттәшләрегез өчен Сез һәрвакыт – ышанычлы партнер, кул астындагы кешеләрегез өчен – аксакал, дусларыгыз өчен игелекле һәм сизгер әңгәмәдәш. Сезнең республика масштабындагы җитәкче абруегыз бар, халык Сезне күп тапкырлар Татарстан Республикасының Дәүләт Советына депутат итеп сайлады. Безнең инженерлык-геологик, геодезия, автомобиль юлларына проектлар төзү белән шөгыльләнә торган оешма Сез җитәкләгән компаниянең ышанычлы абруен һәрвакыт югары бәяләп килде. Мин таныш булуыбызга һәм күп төрле мәсьәләләр буенча аралаша алуыбызга шатмын, Сезне үз эшенең остасы булуыгыз өчен хөрмәт итәм.

Хөрмәтле Фоат Вәлиевич, Сезгә эшегездә зур уңышлар телим! Гармония, бетмәс-төкәнмәс көч-дәрман һәм сәламәтлек насыйп булсын!

Чын һөнәр остасы һәм җитәкченең лаеклы үрнәге

Николай Леденцов,
«Инженерлык челтәрләре» ҖЧҖнең генераль директоры

– Хөрмәтле Фоат Вәлиевич, «Инженерлык челтәрләре» коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм!

Сезнең биография хезмәт сөючәнлек һәм туктаусыз үсешкә омтылыш турында сөйли. Һөнәри язмышыгыз итеп юл хуҗалыгы өлкәсен сайлап, Сез үзегезне тулаем шушы эшкә багышлагансыз һәм юбилеегызга олы тәҗрибә белән килеп җиткәнсез.

Эш принципларыгыз чиксез хөрмәт хисләре уята – төзелеш һәм ремонт эшләренең сыйфатлы башкарылуы, яңа технологияләр куллану, Сезнең компания хезмәткәрләре төзегән юлларның төзелеш чыгымнарын киметеп, кулланылу вакытын арттыру. Уңышлы үсеш кичерүче эре компаниянең җитәкчесе сыйфатында Сезнең лидерлык сыйфатларын һәм карашларыгызның алдынгы булуын билгеләп үтми мөмкин түгел. Сезнең кебек кешеләр артыннан, Фоат Вәли улы, һәрвакыт эшләргә ашкынып торучы профессионалларның бердәм командасы иярә. Эшчеләрегезгә карата сизгер игътибарыгызны да җитәкче урыннарда эшләүче кешеләргә үрнәк итеп куясы килә.

Сезгә ирешелгәннәрдә генә туктап калмыйча, яңа максатлар һәм бурычлар куеп, алга баруыгызны телим. Ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге, оптимизм һәм үз көчегезгә ышаныч Сезгә!

Фото «Инженерлык челтәрләре» ЖЧҖннән алынды

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:
тел: (843) 222-09-76,
8-9272-483-384
e-mail: 89272483384_pr@mail.ru

Реклама 16+

facebook.com/protatarstan

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

twitter.com/protatarstan

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

ТҮБӘН МАЙНА: ТАРИХЛЫ ХАЛЫК

Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк, диләр. Аксубай районының Түбән Майна авылына баргач, әлеге гыйбарәнең асылын тирәнрәк аңлый башладым. Күңелдә майналыларга карата ихтирам белән бергә ак көнләшү дә туды.

Автор:
Руфия Фазылова

МӘГАРӘ «ХУҖАСЫ»

Түбән Майнада 245 кеше яши, 76 хуҗалык бар. Авылга килгәч тә, Рафик Насыйров янына юнәлдек. Ни өчен дигәндә, беренчедән, ул туган авылы тарихын өйрәнгән, биредә яшәүче һәр нәселнең диярлек шәҗәрәләрен төзегән кеше. Икенчедән, Түбән Майна урта мәктәбе директоры, өченчедән, авыл мәчете имамы... Хәер, болай «беренчедән», «икенчедән» дип бүлеп карау дөрес тә түгелдер, чөнки Рафик Гомәрович үзе алай бүлми. Аның өчен һәр эше беренче урында.

– Бер эш белән шөгыльләнгәндә, икенчесеннән ял итеп торам, – диде Рафик Гомәрович. – Вакытны дөрес бүлә белсәң, алар бер-берсенә комачауламый.

Аның белән без мәчеттә күрештек, чөнки намаз вакыты җитеп килә иде. Түбән Майна мәчетенә егерме биш ел икән. Күптән түгел зурлап гыйбадәтханәнең юбилеен билгеләп узганнар.

– Бирегә килегез, бу минем мәгарәм. Әбугалисина кебек монда утырам, – дип, шаяртты Рафик Гомәрович.

Әңгәмәдәшемнең «мәгарәсе» мәчет эчендәге бер почмак икән. Анда шкаф тора, киштәләрдә – китаплар. Дини эчтәлектәге китаплар белән бергә, дөньявилары да бар. Монда шулай ук иске кулъязмаларны, бер-ике гасыр элек басылган китапларны да күрергә була. Аларның күбесе гарәп-фарсы телендә.

– Алар шушы җирләрдә яшәгән халык кулында булган китаплар, – диде Рафик Гомәрович. – Әле бу җыелган әдәбиятның барысы да түгел, бер өлешен Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә илттем.

– Халыкта шулкадәр борынгы китап булганмы? – дим гаҗәпләнеп.

– Әйе, бу бит бер безнең авылдан гына түгел, ә якын-тирә авыллардан да. Укып карагыз әле, дип кешеләр үзләре алып килә. Нигездә болар дини эчтәлектәге китаплар, араларында шәкерт дәфтәрләре дә җитәрлек. Безнең якта халык белемле,

– Авылда яшәүче дүрт гаиләнең шәҗәрәсе генә юк монда, – диде Рафик Насыйров.

Фото: Александр Ефремов

динле булган. Менә бу китаплар – шуның ачык мисалы.

Түбән Майнаның мәчете үзенчәлекле: биредә музей почмагы бар. Анда авылның тарихын чагылдырган картадан (1700 нче елларга караган) башлап, мәчет үткәненә кагылышлы документларга кадәр тупланган.

– Дин сабагына мәчеткә балалар килә, – дип сөйләде Рафик Гомәрович. – Алар әлеге документларны үз күзләре белән күрә, тотып карый ала. Шул рәвешле ата-бабаларының кем булуын, туган авылларының үткәнен беләләр.

Биредә тагын бик мөһим документка тап булдык – авылда яшәүче кешеләрнең нәсел шәҗәрәләре. Рафик Гомәрович, архивларда утырып, кайчандыр Түбән Майнада яшәгән кешеләрне барлап кына калмаган, ә шәҗәрәләрне зур китап-календарь форматында эшләткән дә.

– Авылда яшәүче дүрт гаиләнең генә шәҗәрәсе юк монда, – диде тарихчы. – Аларны эшләп бетерәсе бар.

– Архивларда утырырга ничек вакыт табасыз? – дим.

– Каникулда эшлим. Өйдәгеләргә: «Мин ялга киттем», – дип әйтәм. Чынлап та, тарихи документлар өйрәнү минем өчен ял. Хәзер бит күпләр нәселе белән кызыксына башлады. Шәҗәрә төзеп бирүемне сорап, күрше-тирә районнардан да киләләр. Бүген инде без туган якны өйрәнү үзеге кебек эшлибез.

Ул көнне хәтта рольләребезне дә алыштык – укучыларның сорауларына без, журналистлар, җавап бирдек.

ЗЫЯЛЫ НӘСЕЛ ДӘВАМЧЫЛАРЫ...

Түбән Майна мәчетеннән чыккач, урта мәктәпкә юнәлдек. Рафик Гомәрович кисәтеп куйды:

– Мәктәпкә кермичә китә күрмәгез. Анда сезне укучылар көтә...

Чынлап та, балалар безне көткән. Алай гына да түгел, хәтта рольләребезне дә алмаштык – укучыларның сорауларына без җавап бирдек. Мәктәп укучыларына бар да кызык: татар журналистикасыннан башлап, «Татарстан» журналының аерым сәхифәләренә кадәр. Әчкерсез балаларның акыллы күзләрен күрү, җылы сүзләрен ишетү, йөрәккә май булып ятты.

Түбән Майна урта мәктәбендә 55 укучы белем ала икән. Рафик Гомәрович үз мавыгуын балаларга да йоктырган – укучылар тарих белән чын-чынлап кызыксына. Мәктәп коридорында ук музей почмагы булдырганнар. Анда шушы җирләрдә табылган эш кораллары, кайчандыр халык кулланган көнкүреш кирәк-яраклары, шәкерт дәфтәрләре – барысы да хасиятләп урнаштырылган. Тагын шунысы игътибарга лаек: кайсы гына укучыдан сорасаң да, ата-бабасының нәсел шәҗәрәсен белә. Хәер,

Мәктәпнең коридорында ук музей почмагы булдырганнар.

мәктәптә укыган балалар гына түгел, өлкәннәр дә үз нәселе тарихыннан хәбәрдар икән. Үрнәк алырлык күркәм күренеш.

Авылның мөхтәрәм кешеләре белән дә таныштырдылар безне. Бүген инде лаеклы ялда булган укытучылар янына киттек. Асия һәм Рафыйк Исмәгыйлловлар күп еллар Түбән Майна урта мәктәбендә укыткан. Аларны шушы мәктәп таныштырган да, кавыштырган да.

– Түбән Майна мәктәбенә бер елга дип кенә дип килгән идем, – дип сүзен башлады Асия апа. – Ашыйсы ризыгым биредә булган икән. Рафыйк белән кавышуыбыз шактый тиз булды – август азагында таныштык, ноябрьдә өйләнешеп тә куйдык. Алла теләсә, гаилә корганыбызга быел илле ел була. Ике ул үстердек.

Яшь гаилә Түбән Майна мәктәбендә озак эшләми, бер елдан соң Чаллыга чыгып китәләр. Гаилә башлыгы шәһәрдәге фәнни-тикшеренү институтына эшкә урнаша, Асия апа исә бәби ялына китә.

– Яшь вакытта романтика, яхшырак тормыш эзлисең бит, – диде Рафыйк абый. – Без дә шулай яшьлек кайнарлыгы белән бәхет эзләп чыгып киттек. Шәһәр кешеләре буласыбыз килгәндер инде. Чаллыда озак яшәмәдек, туганнар янына – Ташкентка киттек. Бу 1971 ел иде. Баруга фатир бирделәр, эшкә урнаштык, мин – мәктәпкә, Асия балалар бакчасына. Без булмаган җирдә генә яхшы шул – Ташкентта тормыш мондагыдан начаррак булды. Гел төрле сынаулар үткәрәләр, җир тетри… Җитмәсә, Кытай белән ике арада низаг башланды. Кечкенә улыбызны алдык та кире туган якка кайтып киттек.

Исмәгыйлловлар менә шулай нужа шулпасы чөмереп, Аксубайга әйләнеп кайта. Тик Түбән Майна мәктәбендә инде урын булмый, дөресрәге, яшь гаиләне кире эшкә алырга теләмиләр.

– Мәктәп директоры безнең авылдан китүебезне бер дә теләмәгән иде, –

Асия һәм Рафыйк Исмәгыйлловларның гаилә корып яши башлауларына 50 ел була.

диде Асия апа. – Калыгыз дип, кат-кат үгетләде. Рафыйк белән хәтта сүзгә дә килделәр.

Менә шуның өчен яшь гаилә районның башка мәктәпләрендә эшли. Ә берничә елдан мөгаллимнәр яңадан төпкә эш урыннарына әйләнеп кайта. Дөрес, Асия апа мәктәпкә түгел, балалар бакчасына урнаша.

– Безнең әти белән әни авылның дәрәҗәле кешеләре иде, – дип сөйләде Рафыйк абый. – Икесе дә кырык ел Түбән Майна мәктәбендә укыттылар. Без җиде бала үстек, алтыбыз югары белемле, беребез техникум тәмамлады. Олы абый Роберт техник фәннәре кандидаты иде. Ни кызганыч, гомере кыска булды. Әти-әни исеменә тап төшермәдек, Аллага шөкер. Инде безнең балалар да шулай матур итеп яши белсеннәр. Бөтен теләк шул.

ИҢ ТЫРЫШ КЕШЕЛӘР

Түбән Майна авыл җирлеге башлыгы Энҗе Хөснуллина авыл өчен күп хезмәт куйган тагын бер гаилә белән таныштырасыбыз килә дип, кисәтеп куйган иде. Озакламый Исмәгыйлловлар йортына Алсу һәм Рәшит Сабировлар килеп җитте.

– Шушы кеше ун ел эчендә авылны аякка бастырды, газын да, суын да кертте, – диде Рафыйк абый, кунакның иңенә кагып.

– Республикада беренче булып полиэтилен торба белән газ керттек, – диде тыйнак кына Рәшит Салихович. – Газ торбаларын Биләрдән колхоз көче белән тарттык. Район авыллары арасында Түбән Майнага икенче булып газ җибәрелде. Бер җәй эчендә су керттек. Шуның өчен махсус трактор алдык. Сиксәненче еллар уртасы иде. Колхозыбыз әле яңа гына аерылып чыккан, техник базабыз да юк. Алланың рәхмәте белән менә шундый зур эшләр башкарылды.

– Мин шуны өстим әле: газ кергән вакытта колхоз хисабыннан һәр йортка газ мичләре тараттылар, – диде Энҗе Хөснуллина. – Ул заманда гади халык өчен бик зур ярдәм булды ул. Тагын әле дистәгә якын таш йорт салынды. Акчаның яртысын хуҗа үзе, яртысын колхоз бирде.

– Колхозның шуларны эшләргә матди мөмкинлеге бар идеме? – дим элеккеге рәискә.

– Булган инде. Санаулы вакыт эчендә алдынгы колхозлар рәтенә күтәрелдек. Түбән Майнада халык тырыш, бөтен сере шунда. Алар кебек кешеләр Аксубайда бүтән юк, минемчә. Ире-хатыны бөтен эшне җигелеп тарттылар. Бер генә мисал – сыер савучылар көтү көтәргә дә үзләре чыкты. Мине бу авылга колхоз-

– Түбән Майнадан киткәнгә егерме елдан артык вакыт узса да, атна саен диярлек монда без, – диде Рәшит Сабиров.

ны аякка бастырырга дип җибәрделәр. Хәтерлим, беренче тапкыр җыелыш җыйдык. Таныштык, сөйләштек. Җыелыш тәмамланганнан соң халык дәррәү: «Борчылмагыз, бергә эшлибез», – диде. Моны ишеткәч, күңелгә җылы керде. Авыл халкы белән килешеп эшләмәсәң, җитәкче үзе генә әллә ни майтара алмый. Хәер, колхоз эшендә генә түгел, бөтен җирдә шул ул.

Рәшит Сабиров Исмәгыйловларга еш килгән. Сәбәбе – гаилә башлыгының әтисе – авылның аксакалы Хәлиулла бабай белән мәчет салдырганнар.

– Безнең әти бик актив кеше иде, – дип сөйләде Рафыйк Исмәгыйлов. – Сүзе дә үтте. Лаеклы ялга чыгып, мәктәптән киткәч, муллалык эшен алып барды. Колхоз рәисе төзү кирәк-яракларын караса, әти, ярдәм сорап, төрле җитәкчеләрнең ишеген шакыды. Чаллы, Казан калмады...

– Мәчетне күмәк көч белән төзедек, – дип сүзгә кушылды Рәшит Салихович. – «КАМАЗ»лар белән кирпечне алып кайтуга, авыл халкы аны бушатырга чыкты, төн димәделәр, көн димәделәр...

Тик гөрләп торган колхоз акрынлап тарала. Сәбәбе – әлеге дә баягы, авылларга инвесторларның килүе. Ул вакытта инде Рәшит Салихович гаиләсе белән Түбән Майнадан киткән була. Тәҗрибәле җитәкчене 1997 елда районга «Сельхозтехника» директоры итеп күчерәләр.

– Түбән Майнадан киткәнгә егерме елдан артык вакыт узса да, атна саен диярлек монда без, – диде Рәшит Салихович. – Үзләре дә чакыра, үзебез дә киләбез. Гомернең бер матур чаклары монда узган бит, балалар да биредә үсте. Төпчек кызыбыз Түбән Майнада туды. Туган авылым булмаса да, гел телдә, күңелдә ул...

БҮЛӘККӘ – УМАРТА?!

– Авылда гел зыялылар гына яшиме әллә? Берәр җир кешесе белән дә танышасы килә, – дигәч, Энҗе Хөснуллина безне Туктамышевлар гаиләсенә алып китте. (Ни хикмәт, җир кешесе дигәнебез дә укытучы булып чыкты!) Роза һәм Рифкать Туктамышевлар икесе дә Түбән Майнанныкылар. Бик яшьли (18-20дә!) гаилә корганнар. «Армиядән кайтуга өйләндем», – ди гаилә башлыгы. Дүрт бала тәрбияләп үстергәннәр.

Рифкать Туктамышев Түбән Майна урта мәктәбендә химия, биология укыта. Моннан тыш умартачылык, терлекчелек, игенчелек белән дә шөгыльләнә.

– Илле баш умартам бар, – диде хуҗа кеше. – Корт оялары урманда тора. Җәен шунда яшим, дисәм дә була. Бал кортлары аерганда январында тормасаң, очып китәләр. Кортларны рәсми рәвештә теркәдем, паспортлары бар. Бу шөгыль нәселдән – бабайлардан килә. Башка чыккан балаларына әти-әни бер-ике оя умарта бирә торган булган, миңа да әти берничә

– Чын фермер булсаң, мәктәп эшен ташларга кирәк. Ә миңа үз һөнәрем – укучылар белән эшләве ошый, – ди Рифкать Туктамышев.

баш умарта бирде. Безнең бабай умартачыга укыган, ул документ әле дә саклана.

Илле оя корттан башка, Туктамышевларның 18 гектар җирләре дә бар: үзләренең пай җирләрен эшкәртәләр. Иген, печәнне урып-җыю өчен барлык төр техниканы да сатып алганнар. Ике савым сыеры, алты үгез – малларга дигән азыкны тулысынча үзләре үстерә, әзерли.

– Бер дәүләт программасында да катнашмадым, грант та алмадым, – диде Рифкать Туктамышев. – Чын фермер булсаң, мәктәп эшен ташларга кирәк. Ә миңа үз һөнәрем – укучылар белән эшләве ошый.

Әтисе янында йөргән Әминәгә күз салам, бик сөйкемле кыз. Түбән Майна урта мәктәбенең сигезенче сыйныфында укый. Иҗат белән кызыксына икән, шигырьләр, мәкаләләр яза. (Мәктәптә очрашу вакытында безнең белән иң актив аралашкан укучыларның берсе ул иде).

– Әминәне кырыкка җиткәндә алып кайттык, – диде Роза Туктамышева. – Төпчек бала тәмле була диләр, чынлап та шулай икән. Бик йомшак, «әти-әни» дип кенә тора. Яшебез илледә булса да, авылның яшь гаиләсе булып саналабыз әле, балигъ булмаган балабыз бар бит. (Көлә.) Дөресен әйткәндә, бик авыр күренеш – авылда яшьләр юк дәрәҗәсендә. Безнең чорда бер төркем яшьләр авылда калды. Мисал өчен, Рифкатьләр классыннан дүрт ир бала, безнең класстан ике кыз туган авылдан китмәдек. Бергәләп балалар үстердек, төрле бәйрәмнәр оештырдык. Безгә кадәр булган гаиләләр дә шулай бер төркем булып яшәгән. Ни кызганыч, дилбегәне калдырырга бездән соң андый яшь гаиләләр бик юк. Яшьләргә бергә-бергә яшәү кызык, балалар да үзара дус була, ата-аналар туганнар кебек яши. Кайгыда да, шатлыкта да дигәндәй... Һәрхәлдә без шулай яшәдек, яшибез.

...Түбән Майнаның ак әбие – Тәнзилә апа Нәҗметдинова белән дә күрештек. Тормыш иптәше белән дүрт кыз үстергән ул. Бүген ялгызы яши. Авылдашлары аны бер мәҗлестән дә калдырмый. Әбинең бер җөмләсе күңелгә кереп калды:

– Түбән Майнада яхшы күңелле кешеләр яши. Урам буйлап эзләп йөрсәң дә, бер начар кеше тапмассың, – диде ул.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Авылның тарихы борынгы. Җирле халык хәзерге урынга XVIII гасыр урталарында күчеп утыра.

Авылга «Майна» исеме кушылуны кайберәүләр, кешеләрнең Югары кырдан иңкү урыннарга күченүе белән бәйле булырга тиеш, диләр. Техник терминологиядә «майна» сүзе «түбәнгә» дигән мәгънәдә кулланылуын дәлил итеп китерәләр. Мондый фаразларның дөрес түгеллеге күптөрле чыганаклар белән раслана. Тарихи документлардан күренгәнчә, авылыбыз «Майна» исеме белән 1713 елда, ягъни Югары кырдан төшкәнче 35–40 еллар алдан ук та аталып йөртелгән. Күргәнебезчә, халык, яңа җиргә күчеп утыргач та, «Майна» исемен калдырмаган.

Майна – елга исеме. Археологик чыганаклардан күренгәнчә, безнең якларда бик борынгы заманнарда фин-угыр кабиләләре яшәгән. Димәк, елганың «Майна» дип аталуы да шул чорлардан калган булырга тиеш. Безнең телдә Майна елгасы «бәкеле елга», «кышын туңып бетми торган елга» дигән мәгънәне аңлата.

Рафик Насыйров, тарих фәннәре кандидаты.

«ЛЕЙТЕНАНТ ШМИДТ» ОНЫКЛАРЫ

«Салават күпере» балалар журналы редакциясен бу Яңа елда чып-чын Шүрәле оныклары басып алды – үзләре ямь-яшелләр, үзләре мөгезлеләр. Әлеге төснең һәм атаклы мөгезләрнең булуы – конкурсны оештыручылар куйган төп таләп иде. Алар үзләренең дусларына: «Сез Шүрәленең оныгы Шүркәне нинди итеп күрәсез?» – дип мөрәҗәгать иткәннәр. Шүркә исемле персонажны моннан 10 ел элек... нәкъ менә «Салават күпере» редакциясе уйлап тапты да инде. Һәм оныклар үзләрен әллә ни көттереп тормады – рәсемгә төшерелгәннәре, ябыштырып, бәйләп, тегеп ясалганнары, зурлары, бәләкәйләре һәм тагын төрледән-төрле яшел кечкенә кеше кебекләре (кайберләре дус кызлары белән үк) – редакциягә җыелды. Җыелдылар да, үзләренең күптөрлелекләре һәм ерак бабалары – хөрмәтле Габдулла «улы» Шүрәлегә охшашлыклары белән шаккатырып, тәрәзә төпләренә тезелешеп утырдылар.

Конкурс җюрие әлегәчә баш вата – «иңиң» Шүркәне һич сайлап ала алмыйлар, ә бит аның авторына саллы приз бирелергә тиеш! Алар уйланган арада «Татарстан» журналы редакциясе иң яхшы Шүркә-2020 өчен ярышкан яшь талантларның әти-әниләре арасында конкурс игълан итәргә уйлап тора әле, чөнки аларның ярдәменнән башка балалары Шүрәле сәнгатендә мондый гаҗәеп әсәрләр иҗат итә алыр идеме икән!

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ 2020 ЕЛНЫҢ ДЕКАБРЕНДӘ УЗАЧАК 100 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕ ХӨРМӘТЕНӘ #ТАТАРСТАННЫҢ100ҖӘҮҺӘРЕ ПРОЕКТЫН БАШЛАП ҖИБӘРӘ

«РОССИЯНЕ» КАЗАНДА АЧКАННАР

1844 елда Казан университеты профессоры Карл Клаус яңа химик элемент ача. Галим аны рутений (Ruthenia – латинча Россия) дип атый. «Мин бу юнәлештә бер елдан артык хезмәт куйдым, ниһаять, матдәне чиста халәтендә табуның җиңел һәм дөрес юлын ачтым. Бу яңа металлга мин Ватаныбыз хөрмәтенә рутений дигән атама бирдем», – дип язган Карл Клаус үзенең ачышы турында.

© «Татарстан» журналы

ТАТАРСТАН 100 ЛЕТ ЕЛ

Тулырак **www.100.tatarstan.ru** сайтында

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ 2020 ЕЛНЫҢ ДЕКАБРЕНДӘ УЗАЧАК 100 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕ ХӨРМӘТЕНӘ **#ТАТАРСТАННЫҢ100ҖӘҮҺӘРЕ** ПРОЕКТЫН БАШЛАП ҖИБӘРӘ

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

Тулырак
www.100.tatarstan.ru
сайтында